ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
"АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ МӘГАРИФ ИДАРӘСЕ"
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
"АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ ГИМНАЗИЯСЕ"

# Республикакүләм "Марсель Галиев укулары" фәнни-гамәли укучылар һәм укытучылар конференциясе материаллары

Азнакай шәһәре, 2022

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының

22 сентябрь 1217/21 номерлы карары нигезендә басыла

Төзүчеләр:

1. Рахманов А.М.- “Азнакай шәһәре гимназиясе” директоры
2. Ибраһимова Ч.Р.- директор урынбасары
3. Хөсәенова Ф.В.- уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары

Республикакүләм “Марсель Галиев укулары” фәнни-гамәли укучылар

һәм укытучылар конференция материаллары.

Азнакай шәһәре, 2022. – 103 бит.











**М.Галиев-безнең якташыбыз**
**(М.Галиев тормышы һәм иҗатына багышланган иҗади бәйге)**

*Абдрахимова Рушания Шакирҗановна,*
*Бөгелмә шәһәре 3нче урта мәктәбенең*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

Иҗади бәйге танылган татар язучысы М.Галиевнең иҗатына кызыксыну уяту, укучыларның сәнгатьле сөйләмнәрен, үз фикерләрен төгәл итеп әйтеп бирү күнекмәләрен, иҗади сәләтләрен үстерү максаты белән әзерләнде.

"М.Галиев-якташыбыз" класстан тыш чарасы иҗади бәйге формасында үткәрелә, ике команда катнашуын таләп итә. Әлбәттә, әлеге чара укытучыдан да, укучылардан да зур әзерлек сорый, чөнки рус мәктәпләрендә укучы татар балалары өчен төзелгән программада М.Галиев иҗатына каралган сәгатьләр саны аз, ә рус телле укучылар аның иҗаты белән әсәрләреннән өзекләр укып кына танышалар. Безнең мәктәптә һәр укытучы предмет буенча дәрестән тыш эшчәнлек алып бара. Мәсәлән, минем курс "Туган якны өйрәнүчеләр" дип атала. Курс кысаларында без якташ язучыларның иҗатын да өйрәнәбез. Бу уку елында укучылар Марсель Галиевның тормышын һәм иҗатын теләп өйрәнделәр, йомгаклау шөгыле шушындый бәйге формасында уздырылды. Уткәру вакыты – 45 минут.

Бәйгенең эчтәлеге:

1. Укытучының кереш сүзе.
2. Командалар белән танышу.
3. М.Галиевның тормышына һәм иҗатына багышланган биремнәр. М.Галиевның тормышына һәм иҗатына багышланган тест үтәү формасында уздырыла.

Командалар чиратлашып тест соруларына җавап бирәләр, җавап дөрес булмаса, сүз икенче командага күчә, һәр дөрес җавап 1 балл белән бәяләнә.

4. "Адашкан җөмләләр"

Язучының "Балачак әсирлегендә"дигән хикәясеннән өзегендә җөмләләр буталып бирелә. Өзектәге җөмләләрне дөрес итеп тизрәк җыйган команда 3 балл ала.

*1.Тау турында, без Мансур белән ясарга хыялланып йөргән очырткыч шикелле, нәни генә ак болыт туктап калган.*

*2.Кемдер җебеннән тартыр да, ул тагын кузгалып китәр, зәңгәр киңлектә талпынып йөзәр кебек...*

*3.Алда Мәкәтә тавы күренде.*

*4.Минем-уйчан-җитди карашымнан ятсынылмы, малайлар,өркетелгән күгәрченнәр кебек, як-якка сибелделәр дә аксыргаклар арасында юк булдылар.*

*5.Мин алар артыннан кызыгып карап калдым.*

5. Мин язучы булсам, бу әсәремне "______" дип атар идем.

Командаларга "Мин язучы булсам, бу әсәремне "___________" дип атар идем, ситуациясе тәкъдим ителә. Һәр команда үз җавабын дәлилиләп сөйли. Бәйге 3 балл белән бәяләнә.

6. М.Галиевның шигырьләрен яттан сөйләү.

Бу бәйге командаларга өй эше итеп бирелде. Һәр команда М.Галиевның 2 шигырен яттан сөйли, жюри командаларга билге куя

7. Иҗади эш

Компьютер программасы ярдәмендә М.Галиев китабы тышын бизәү конкурсы. Бу эш «MyPain» программасында башкарыла. Бәйге өчен җиңүче команда 3 балл ала.




8. “Бергә жырлыйбыз”

Командалар М.Галиев сүзләренә язылган жырларны тыңларга һәм аларның исемен атарга тиеш. Кайсы команда тизрәк җавап бирә, 1 балл ала.

Бәйге командалар алдан әзерләгән бер жырны башкару белән тәмамлана. Жюри баллар куя.

## Марсель Галиевның “Рух” китабында сүз сәнгатенең бирелеше

*Алекян Азалия, 5 нче сыйныф, “Азнакай шәһәре*
*2 нче муниципаль гомуми урта белем бирү мәктәбе”*
*Җитәкче: Мөхлисова Фәридә Фәрит кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Күңелемә бик нык үтеп кергән әсәрләрдән Марсель Галиевның “Рух” китабы. Укыганда күңелләрнең иң нечкә кылларын тибрәтеп ала торган әлеге сүз сәнгатен күзәтүне әлеге хезмәткә максат итеп алдым.

Хезмәтем хәзерге тормышта бик актуаль. Чөнки безнең тормышта сүзнең көче тел язмышы белән дә бәйле. Минем **фаразлавым** буенча, әлеге әсәрендә Марсель Галиев кеше күңеленең иң нечкә кылларын тибрәтеп сүзнең бөек көчен ача алган. Максаттан чыгып, без үз алдыбызга түбәндәге ***бурычлар***ны куйдым:

- Марсель Галиевның “Рух” әсәрен анализларга;
- Марсель Галиевның “Рух” китабына карата үз мөнәсәбәтемне белдерергә.

Сайлап алган теманың актуальлеге бәхәссез. Чөнки халыкның теле иң югары баскычка куелырга тиеш. Әгәр кешелек дөньясы шуны кулланып яшәсә, безнең телебез саф килеш сакланып буыннан-буынга күчәр, күңелебез тыныч булыр.

Сүз - пирамидаларга кадәр туган.

Сүз – пирамидалардан соң да калачак.

Халыкның холык-табигате, тарихы гореф-гадәте, омтылышы, уй-гаме сүзләргә сыйган.

Ни хикмәт бар Сүздә, ни серләр бар? Сүзләр, Күк гөмбәзендәге серләр кебек, күренә дә күренми дә, беленә дә беленми дә, сүнә дә сүнми дә, ерак та, якын да, үлә дә, үлми дә... Тел байлыгы-буыннан-буынга күчә барган ганимәтле мирас, халык бәгъренә язылган тере сүзләр йолдызлыгы.

Кулланылышта булса гына, әле хисләнеп, әле ямансулап, әле ярсынып, әле моңланып торганда гына тел хасияте тулы канлы яши: дулкынлана, кайный, карынында янар таулар дөрләтеп, яңа сүзләр хикмәте тудыра, үсә, ныгый, вакыт ияреңдә егәрләнә бара.

Өлкән буын телне салмак олыгайтып яшәсә, яшь буын телне санлап яшәтә. Шушы табигый бизмәннең ике яссылыгы да тигез тибрәнештә булганда гына телнең терек сулышы бөтен мөмкинлекләренә киерелеп ачыла.

Туган тел! Алла, ата,ана дигән иң изге сүзләрнең галәми түгәрәк, кояшлы балдак хасил иткән камил яңгырашы-ул синдәдер, синдә генә...

Газиз ана теле!

Бөек телләр арасында үз бөеклегеңне кылыч чыңы белән түгел, тыныч жырың беләнраслый алу инсафлыгы-ул синдәдер, синдә генә...

Газиз ана теле!

Уелып язылган борынгы таш китапларны, утлы гасырлар аша исән китереп җиткереп, дөнья хәтеренә китереп куша алу олпатлыгы-ул синдәдер, синдә генә...

Сүз болыны, Сүз урманы, Сүз таулары бар М.Галивның “Рух” китабында. Мин сезне дә менә шул Сүз болынында колын булып, уралырга, Сүз урманында туарылып ятарга, Сүз тауларында җилләр белән көрмәкләшеп мәтәлчек атарга чакырам. **Марсель Галиев** кайдан ала соң шушы кадәр сүзләргә бөеклекне? Офыклары зәңгәр таулар белән каймаланган туган ягыннан бит... Туган ягына ул сүзгә сусап, чит-ят сүзләрдән кагынырга, чистарынырга дип кайта. “Тәүге Сүз-әнкәм сүзе-зиһенемне иркәләп уяткан. Аннары берәм-берәм ачыла башлаган тел коелары! Мин шул коелардан Сүзне чүмечләп-чүмечләп чумырып алганмын.

Юа-кузгалаклардан-әчкелтем сүз, балтырган, шома көпшә, кымызлыклардан-сусыл сүз, шайтан таякларыннан-чәнечкеле сүз, җиләк-бөрлегәннәрдән-татлы сүз, шомырт-баланнардан-әчкелтем сүз җәсәдемә, аң-зиһенемә бәрәкәтле шифа булып таралган.

Марсель Галиевка Сүз белән идарә итү, илһамлы иҗат уты бирелгән. Язучы үзе бу халәтен Күкләр ихтыяры ди.Бисмилла әйтеп кулына каләмен алуга ак кәгазь түтәлендә берәм-берәм сүз уйдыклары шыта башлый. Нәзберек сүз кыяклары, тармаклана-куәтләнә барып, буйга сикерә...

Ни хикмәт бар Сүздә, ни серләр бар?

М.Галиевның “Рух” китабындагы Сүзләрнең серле дөньясы белән таныша барган саен гаҗәпләнүем, соклануым арта гына бара. Я, Илаһым, ничек яза бит?! Сүзләр үзләреннән үзләре хис дулкыннары белән тирән, мул сулы елгага алып кереп китә дә, рәхәт бер көйгә тибрәтә шикелле.

Яме, тәме, гаме нинди? Сулышы киңме, яңгырашы сулышына тиңме? Аң-зиһенеңдә сүтеп кара сүз йомгагын:

1. Үзеңнән акыллырак шәхесне тану өчен иң элек үзеңнән акыллырак булуыңны таныту кирәктер.
2. Гайбәт сүз телеңне кычыттырса, авызлык тимерен чәйнәгән атны күзалла.

Туган тел

Бөек тә син, боек та син,
И туган тел, туган тел,
Күп гамәлләр кылган тел!
Аргамаклар җилеп чапкан,
Былбыл сайрап кунган тел.

Сүзләр

Табып алдым юлдан ялгыз бер сүз –
Каерылган иде канаты;
Алып кайттым өйгә, дәваладым,
Минем өйне ул да яратты.

Сүзләренә генә игътибар итегез! Ул без әйтәргә теләгәнне оста әйтеп бирә.

М.Галиев халык тормышына, яшәешенә, тарихына, кешенең иң газиз эчке серләренә, кичерешләр дөньясына тирән үтеп керә белә.

Сүз-күп яклы һәм катлаулы тел берәмлеге ул. Һәр сүзгә төп һәм күчерелмә мәгънәләре, килеп чыгышы, атама тарихы, кулланылыш үзәнчелеге, төзелеше, кулланылыш сферасы һәм башка яклардан характеристика биреп була.

Нинди генә сүзләр юк! Нәфисләре бар! Күңелсезләре. Ачулылары.

Ачык күңелле сүзләр бик ишле. Моңлылар да аз түгел. Күңелсезләр, купшылар, шаяннар, ямьсезләр дә җитәрлек.

Бер уйласаң, сүз җанлы кебек. Хәтта кеше кебек алар, берсе ачык йөзле берсе шыксыз чырайлы. Төрле төс ала сүз. Ачу белән әйтелсә, “зифа” да зифа түгел.

Елмаеп туса, “юньсез” дә күркәм. Калын тавышлы “нәләт” каргыш икән, шаян “дөмеккере!” дә “яшә!”гә тиң.

Җир йөзендә тәүге учак тергезелгән чорлардан бирле гасырларны кичеп килә бит ул-кыялардан кубып, җил-су-ут эзәрлекләвеннән чыныгып чарланган, чакматашка әверелгән б а б а с ү з л ә р...

Шифалы канаты астына алып, изге нурында җылытып торучы, тудыручы кодрәте бирелгән ә н к ә с ү з л ә р..

Яу-дауларда сыналып исән чыккан, һәр даим уяу-сизгер, кырыс үткенлеге корыч ныклыгына тиң ә т к ә с ү з л ә р...

Безнең арабызда яңа туган “бала” сүзләр һәм меңьяшәр “карт” сүзләр дә яши. “Аксакал” сүзләр нарасый сүзләрне тәрбияли, дөнья белән таныштыра, кешеләр теленә кертеп сыный, утка-суга салып чыныктыра.

Сүзләр, Күк гөмбәзендәге йолдызлар мириадасы кебер, күренә дә, күренми дә, беленә дә, беленми дә, сүнә дә, сүнми дә, ерак та, якын да, үлә дә, үлми дә...

Хикмәти сорау килә. Уйдан алда сүз туамы? Әллә инде уй, алдан туып, сүзләргә әвереләме? Сүз һәм уй арасында аң-зиһенгә бирешмәгән упкын ята.

Борынгы кешеләр җирдә тәүге тапкыр атлап киткән чакта уй-тойгысын сүз белән белдерү өчен күңел упкыны аша гасырлар буена чыкканнардыр. Хәзер инде тел байлыгына ирешкән кеше өчен уй белән сүз икесе бер мизгелдә кабынадыр шикелле...

Ягымлымы сүзләр-талымлымы, сөннәтлеме сүзләр-өммәтлеме, тибелгәнме сүзләр-сибелгәнме, һавалымы сүзләр-дәвалымы, олтанлымы сүзләр-алтынлымы-һәммәсенең язмышы, гомер озынлыгы дәүләти тел тәхетенең югарылыгыннан тора.

Ерактан эзләмә, кеше биеклегеннән торып, тирән-юнеңә, аяк астыңа күз сал да соклануыңны сулышыңа күчер: сине тудырган халык-шагыйрь булган! Югыйсә кинәнеп үскән һәммә үсентегенә шундый да балкышлы атамалар бирә алыр идеме; үсемлекләрне кош-корт, җәнлекләр галәме белән бербөтен итнп карый алыр идеме, әгәр шагыйрьлек илһамы калҗбендә булмаса?

Дала үләннәренә, бакча гөлләренә, болын чәчәкләренә кушылган исемнәр – искиткеч матурык үрнәге. Аларга үссендереп үстерә торган сүз тылсымы салынган... *Укъяфрак, умырзая, кашкарый, гөлбадран, тамчы гөл, тайтояк, баллы баба, тузганак, раушан...*

Бу очракта ул үзе үскән тирәлектәге, үзе белгән-күргән үсемлекләрнең генә исемнәрен китергән. Югыйсә...

“Иң әүвәле Сүз булды...”-диелгән Тәүрат китабында. Барысы да сүздән башлана. Ә сүз ул-кешенең дөньяны танап-белү тәҗрибәсен башкаларга җиткерү, аралашу коралы. Кешенең акыл-зиһен матурлыгы аның сүзләрендә күренә. Халыкта: “Кеше күрке йөз булыр, йөзенең күрке күз булыр, телнең күрке сүз булыр” дигән шактый борынгы мәкаль бар. Сүз, телнең күрке буларак, тылсымлы көчкә ия. Тикмәгә генә халык: “Яхшы сүз-җан азыгы, яман сүз-баш кызыгы”, димәгән. Чыннан да яхшы сүз кешеләрнең күңелен күтәрә, авырлыкларны җиңәргә көч бирә, батырлыклар эшләргә рухландыра. Яман сүз изге хисләрне үтерә, кешенең кулыннан эше төшә, хәтта кешене упкыннар читенә китереп тери. Җылы, йомшак сүзләр бер-беребезгә булган мөнәсәбәттә уңай мохит тудыра: кешенең игътибары, ихтирамы арта.

Сүзләр бүген дә үзенең тылсымлы көчен югалтмый. Сүзләргә дөнья йөге йөкләнә. Алар-тере, алар яши. Аларның үз дөньясы, үз үлчәнеше, үз язмышлары бар. Серле

дә, хикмәтле дә, бизәкле дә ул сүзләр. Кайсылары бик тирәннән чишмә кебек саркып чыгалар, ә кайберләре, язгы ташкын кебек, ургып агалар.

Сүзләр... сүзләр!.. Бу якты дөньяда яши-яши мин сезне чын-чынлап аңлый башладым кебек. Минем туган телемдә нинди генә сүзләр юк! Ипле, ягымлы, матур, җыйнак сүзләр булган кебек, керпе кебек чәнечкәле, елан сыман чагып ала торган, күтәреп булмаслык авыр, шыксыз, иләмсез, ямьсез, тәмсез сүзләр дә күп. Соңгы вакытта безнең телебез тагы да чуарлана, чүпләнә бара.

Сүзләр! Мин сезне бик яратам. Мин сезгә бурычлы. Сез мине туган телемне яратырга, тормыш кадерен белергә өйрәттегез. Туган телемдәге бөтен матур сүзләр Җир шары буйлап кояш нурлары кебек таралсын иде дә, барлык кешеләрне бары тик Тынычлыкка, Изгелеккә, Гүзәллеккә, Мәхәббәткә, Дуслыкка, Татулыкка өндәп торсыннар дип, бөтен Җиһанга ишетерлек итеп аваз саласым килә.

Әби-бабалар оныкларын кечкенәдән тәмле телле, тәмле сүзле булырга өйрәттеләр. “Тәмсез телле булсагыз, сезне беркем дә яратмас”, - диләр алар.

Сүзләр гаҗәеп сыйфатларга ия. Алар авыздан чыпчык булып очып чыга да кире әйләнеп кайтмый... Нәкъ менә җәядән атылган ук шикелле. Аларның кайберләре – усал сүзләр, явызлык булып, ә изге яхшы сүзләр, игелек булып, кире кайтучан.

Сүзләр кешегә һава белән су, икмәк белән тоз, кояш белән мәхәббәт кебек кирәк. Сүздән башка тел дә, халык та юк. Сүзләр миңа әби-бабамларымнан мирас булып калган. Сүзләрдән сүзтезмәләр, җөмләләр төзеп, олуг әдипләр күңелдәгеләрен иҗат иткәнгән.

Сүзләр! Газизләрдән газиз әткәм-әнкәм телендәге-Бөек Татар телендәге сүзләр! Җир шары буйлап кояш нурлары кебек таралсын иде дә җиһандагы барлык кешеләрне бары тик гүзәллеккә һәм изгелеккә генә өндәп торсыннар иде!

Сүз-күңел көзгесе, ди халык. Йөрәктән чыккан сүз генә йөрәккә барып җитә. Шагыйрьнең күңеленнән очкын булып чыккан һәр сүзе йөрәкләргә үтеп керә, битараф җаннарны уята.

Чынлап та, сүз-искиткеч могҗизалар тудыра алучы, зур тәэссир итү көченә ия булган корал. Ә корал белән сак эш итәргә кирәк. Шуңа күрә соңгы вакытта сүз сафлыгын саклауга, сүзләргә сакчыл караш тәрбияләүгә зур әһәмият бирелә, төрле чаралар үткәрелә.

Сүз, мәгънәсе һәм эмоциясе буенча, дөньяда беренче туып яңгыраш алгандагыга якын булырга мөмкин. Сүз кадәр Сүз бит ул! Сүзгә сакчыл булу-ул Аңа инану, табыну. Аның кодрәте алдында баш ию, “рәнҗешеннән” курку-дип яза шагыйрь. Әлбәттә, бу сүзләрне шигъри җанлы кешеләр чыгарган заманында. Бу хикмәтле сүзләр халкыбызның фольклорында гасырлар буе яшәп килгән. Беренче карашка ифрат та җиңел тоелган кыска үткен сүз М.Галиевтан зирәклек, зур акыл, бай тормыш тәҗрибәсен таләп итә.

Бу дөньяда һәрбер адәм баласына рухи терәк кирәк кешенең бу тормышта үз кыйбласы булырга тиеш.

Элегрәк мин сезне ишетә, әйтә, уйлый һәм яза гына белә идем. Ә хәзәр мин сезне бөтен күзәнәкләрем белән тоям, күрәм, хәтта ки төсләрегез вә исләрегезне аера башладым шикелле. Сез-тере, сезнең үз дөньягыз, үз үлчәмегез, үз кагыйдәләрегез, үз холкыгыз һәм язмышыгыз да бар икән... Хәтта ки-үз дәүләтегез... “Авыз күрке-тел, тел күрке-сүз” дип юкка гына әйтми безнең халык. Без телне нәкъменә сүзләр аша күз алдына китнрәбез дә. Аларның төсе дә, исе дә, тәме дә, хәтта ки җаны да бар

бугай. Сүзләрнең кайберләре урамда, ә кайберләре өйләрдә генә яши. Дөресен әйткәндә, аларның яшәмәгән җире юк. Сүзләр Җиде кат җир астына да үтеп керә, җиде кат күкләргә дә барып җитә.

Керпе кебек чәнечкәле, песи кебек йомшак, елан сыман чагып ала торган сүзләр дә яши... Вакыты-вакыты белән бары тик һавада гына очып йөри торган канатлы сүзләрне дә эләктереп алу бәхетенә ирешәсең...

Дөньяда бернинди авызга да, бер генә каләмгә дә буйсынырга теләмәгән артык горур һәм бәйсез сүзләр дә очраштыргалый. Әлеге азат һәм хөр сүзләр нигәдер кешеләрдән дә ераграк торырга яраталар.

Сүз-җанның чагылышы. Җанның ни уйлый, телең шуны сөйли. Сүз-аткан ук. Агу очлы ук-кара күңелле җан, татлы очлы-ак күңелле җан. Сүзләр-күңел кайтавызы..

Сүз һәрчак сүз булып калыр, иң әһәмиятле: ул сүзгә синең җаның салынганмы, ул сүз йөрәктән чыгамы, ялган түгелме ул сүз. Сүз әйтелгәч югалмасын, үзен белдереп тавыш салсын, күҗелдә яңгырасын. Сүз тере булсын.

Эх, сүзләр! Белсәгез иде сез үзегезнең көчегезне, әһәмиятегезне! Сез безне бәхетле дә, бәхетсез дә итә аласыз.

## Марсель Галиевның “Догалы еллар” әсәренә анализ

*Вадигуллина Раушания Мехәмәтхәниф кызы, Шакирова Әлфия Рәфгать кызы, Азнакай муниципаль районы Чубар - Абдул авылы урта гомуми белем бирү мәктәбенең туган тел һәм әдәбияты укытучылары*

Эшемнең максаты: якташ язучыбыз Азнакай районының Балтач авылында 1946 елда туган, танылган язучыбыз Марсель Баян улы Галиевнең прозасын, аеруча “Догалы еллар” әсәре мисалында язучының иҗат йөзен киңрәк билгеләү.

Әлеге максатка ирешүдә дә безнең алга түбәндәге бурычлар куелды.

1. М.Галиевның тормыш юлын өйрәнү
2. Әдип иҗатына кагылышлы фикерләр, бәяләмәләр белән танышу.
3. М.Галиев прозасына хас гомуми үзенчәлекләрне билгеләү, язучы кулланган әдәби чараларын барлау.
4. “Догалы еллар” әсәренә өлешчә анализ ясау.

Әдәбият-тирән диңгез. Бу диңгездә чиксез күп сандагы елгалар, инешләр коя. Аларның һәркайсының үз үзенчәлеге, үзенә хас сыйфатлары белән аерылып тора. Әдәбият диңгезеннән башка булган яшәешне күз алдына китерүе дә кыен. Шөкер, аны һәр чорның үз туендыручы бар. Г.Тукай, Г.Исхакый, С.Рәмиев, Г.Камал, Дәрдмәндләрдән эстафетаны С.Хәким, Г.Бәширов, Х.Туфан, Ә.Еники, М.Мәһдиевләр һәм башкалар ала.

Туксанынчы еллар бу диңгезне мәйданы тагын да киңәя. Иҗатлары үзенә генә хас, язу стиль ләре белән хәзерге заман татар әдәбиятының йөзен билгеләүчеләр Ш.Галиев, Р.Фәйзуллин, Р.Гаташ, Ә.Баянов, Р.Миңнуллин һәм башкалар бар. Алар рәтенә Марсель Галиевны да карап кертеп була.

Т.Миңнуллин М.Галиевны М.Мәһдиев, Ә.Еникиләр белән чагыштырып: ” Марсель фикер тирәнлеге белән тел нечкәлекләрен тәңгәл китерә белгән язучы. Мондый осталык Ә.Еникидә бар. Менә алар икесе дә эчке хисләрен кирәкле сүз белән ябештереп куялар. Аннан килеп мин Марсельның холкы белән, дәүләт чикләрен санламыйча колачлап фикерләве, яшәеш рәвеше Мәһдигә охшатам. Язган

һәр җөмләсен күрсәтә, укучыны гаҗәпләндерә белү-һәр язучыга да тәтеми. Бу- тумыштан бирелә”.

Марсель Галиев әдәбият, иҗат өлкәсендә беренче адымнарын шагыйрь буларак башлый. Тик алга таба шигырьләр белән генә чикләнмичә, үзенең укучыларын матур хикәя, повестьләрен белән шатландыра. Әлегә кадәр күзәтү ясалган хезмәтләрендә каралган фикерләр башлыча Марсель Галиевның тормыш юлы һәм иҗатына гомуми планда бәя бирүгә кайтып кала, аның бай үзәнчәлекле иҗатын өйрәнелмәгән диярлек әле.Тирәннән өйрәнергә, тикшерелергә лаеклы булган, ләкин иҗатына тиешле игътибар ителмәгән М.Галиев иҗатына бездә зур кызыксыну уятты. Шуңа да эшебездә якташ язучыбыз Азнакай районының Балтач авылында 1946 елда туган, танылган язучыбыз Марсель Баян улы Галиевнең прозасын, аеруча “Догалы еллар” әсәре мисалында язучының иҗат йөзен киңрәк билгеләүне төп максат итеп куйдык.

Эшебезнең төп методологик чыганаклары булып Сафиуллина Флера Садриевна, әдәбият галимнәре, тәнкыйтьчеләре Заһидуллина Дания Фатиховна Ихсанова Илсөяр һәм якташ язучыбыз ветеран Самат Хәйдәргалевич Мирсәетов мәкальләре торды. Әлеге чыганаклар безгә эшнең юнәлешен билгеләргә ярдәм итте.

Тикшеру обьекты: „Югалтулар аша гына әрнү-хәтер уяна “ „ Безнең ачыш” „Аксакаллар сүзе” „ Карап була” , „ Су буеннан әнкәй кайтып килә” , „ Тонче күзләр ; « Көзге моң”, “ Ак абагалар”, “ Алтын тотка”, “ Сөйлә кил... юат мине”, “ Әрем исе әрнүле”, “ Догалы юллар”.

Шагыйрнең хәтере зур көчкә ия . Без моны җыентыкның “Еллар чагылышы” бүлегендә тупланган шигырьләрне укыганда ачык тоябыз. Бүлеккә шундый исем куеп , М.Галиев шигырләрендә чагылучы чор билгеләренә ишарәләгән. Китапта авыл, аның табигате, кешеләре турында сүз барса да,күренешләрнең төбенәрәк төшү, тирәнгәрәк керү кирәклеген искәртә шагыйрь. Чор чалымнарының тагын берсе – туган халкы тариыхына,үткән тормышына илтифатлылыгы. Һәр шигырендә рәссам кулы, күзе сизелә.

“Сабантуйда көрәш барган мәйданнардан,
Сугыш җиле әткәйләрне йолкып алган.
Сөлгеләре яшел чирәм өсләрендә,
Яраланган аккош кебек ятып калган”.

«Яралы аккош канатлары” җырга кереп китте һәм М.Галиевның шигъри ачышы булды, ягъни ул җыр поэзиясендә романс жанрын алып килгән шагыйрь. Аның “Су буеннан әнкәй кайтып килә”, “Таныр идең микән?”, ” Көзге моң” кебек романслары поэзиябезнең югары сәнгате булып, татар шигъриятенә яңа сәхифә булып язылдылар. Шигырьләре образлы, гади, халыкчан. Алар йөрәкне телеп үтә (һаваларда торна тавышлары...).Шагыйрьнең гомере буе татар тарихына мөкиббән яшәве, бүгенге татарны да, Алтын Урда Казан ханлыклары биеклекләренә күтәрәсе килү теләге шигырьләрендә кызыл җеп булып сузылган. Чатыр тауга мәхәббәте дә үзенең милләтеннән аерылмаган көе биеклеккә омтылудан килә.

Марсель Галиев-лиро-эпик жанрларны яңача тергезүчеләрнең берсе. Аның нәсер, эссе, эссема, очерк үрнәкләре бар. Романтик хикәяләүче яки лирик герой тудырылу бу әсәрләрне язучының романтик иҗаты белән якынайта.

Традицион нәсер таләпләренә туры китереп иҗат ителгән “Чатыр Тау җиле” нәсерендә туган җирне ярату хисе белдерелә: ”Идел-йортыбызның иң биек түбәсе

саналса да, иңенә ятып еларлык яшел мендәр дә ул, рухына дәрт өстәрлек мәгърүр биеклек тә ул, балачак иленә кайтара алган җил ияре дә ул,"-дип яза шагыйрь.

Шулай итеп, М.Галиевның "Догалы еллар" китабында төрле жанрлагы әсәрләр тупланган.Алар арасында күпчелек урынны эссе жанры алып тора.Аннан соң юлъязма, сәяхәтнамә, нәсер жанрындагы бүлекләр дә бар.Ул җәмгыятебездәге хәлләрнең асылын ачарга тели. Марсель Галиев татар әдәбиятының эссе жанры үсешенә үзенчәлекле өлеш кертүчеләрнең берсе булып тора.

"Догалы еллар" китабына барлыгы 22 әсәр тупланган.Без аларның кайберләренә тукталып киттек. Бу эсседа бүгенге көннең мөһим проблемалары яктыртыла.Колхозда дөрес сәясәт алып барылмау нәтиҗәсендә кешеләрнең күмәк хезмәттән читләшүе, хезмәт хаклары түбән бәялән,тормыш дәрәҗәсенең яхшырмавы-кешеләрдә бердәмлеккә карата ихтыяҗы кими кешеләрдә апатия, рухи торгынлыкка килү кебек җәмгыятьтәге проблемалар күрсәтелә.Халыктан килгән гореф-гадәтләрнең кешеләргә ясаган йогынтысы гыйбрәтле вакыйгаларда гәүдәләндерелә."Догалы еллар" әсәре татар әдәбиятында яңа сүз әйтүче әсәр дигән фикергә килдек без.

**Марсель Галиев иҗатында фәлсәфи уйланулар. Сүз көче**

*Габдуллина Динә, 9 нчы сыйныф, "Азнакай шәһәре*
*2 нче муниципаль гомуми урта белем бирү мәктәбе"*
*Җитәкче: Алтынбаева Светлана Сәгыйдулла кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, 1979 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы Марсель Галиев иҗаты-татар әдәбиятына яңалык алып килгән, үзенчәлекле, киң кырлы бай иҗат. Үзенең кыскалыкка һәм тирән фәлсәфи фикерләүгә нигезләнгән әсәрләре белән дә, чорның әдәби хәрәкәтен күз алдына китереп бастыра торган публицистик язмалары, мәкаләләре, әңгәмәләре белән дә Марсель Галиев әдәбиятыбызда аерым бер урын тота.

Тикшеренү эшенең **актуальлеге һәм фәнни кыйммәте** – якташыбыз иҗатында фәлсәфи уйлану үрнәкләрен тикшерүдә.

**Эшнең максаты** – Олпат язучы Марсель Галиевнең иҗатын өйрәнү. Аның иҗатына гына хас тел-сурәтләү чаралары аша фәлсәфәлелекне ачыклау.

Максаттан чыгып мин үз алдыма түбәндәге **бурычлар**ны куйдым:

- язучы иҗатындагы төрле темаларга багышланган әсәрләрне барлау;
- иҗатына кыскача күзәтү ясау;
- «Шәһри Казан» редакциясенең күргәзмәләр залында ачылган 50 эшне берләштергән «Тынлык дәшкәндә» дип аталган күргәзмәсе белән танышу.

Танылган әдип-шагыйрь, прозаик һәм драматург Марсель Баян улы Галиев 1946 елның 8 октябрендә Татарстан Республикасының Азнакай районы Балтач авылында игенче гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч мәктәпне туган авылында, сигез сыйныфны шул ук районадагы Туйкә авылы мәктәбендә, унберне исә 1964 елда Азнакайның 1 нче номерлы урта мәктәбендә укып тәмамлый.

Фәлсәфә-Грек теленнән кереп үзгәргән сүз (философия), "гакыллылыкны ярату" мәгънәсендә. Суфи сүзе философия сүзенең софия (гакыллылык) өлешенә барып

тоташа дигән фикер дә бар. Фәлсәфә,-кәлям һәм суфичылык белән беррәттән, ислам философиясенең бер юнәлеше ул.

"Марсельнең шигырьләрен аның үз биеклегенә күтәрелеп укырга кирәк. Аның төсләр белән уйнавын кабул итү дәрәҗәсендә әзерлегең булса, аның тел вә фикер сыгылмалылыгын аңласаң гына, Марсель Галиевның иҗатыннан тәм табасың". (Туфан Миңнуллин)

Марсель рәссам булмаганга язучы булган. Язучы булмаса, артист булыр иде. Ул югары сәнгать кешесе. Тик өчесен дә берьюлы бер дәрәҗәдә тарту өчен бер кеше гомере генә җитәрлек түгел. (Туфан Миңнуллин)

Олпат язучы Марсель Галиевнең «Шәһри Казан» редакциясенең күргәзмәләр залында ачылган 50 эшне берләштергән «Тынлык дәшкәндә» дип аталган күргәзмәсе нәкъ менә шушы максатны күздә тота кебек. Менә шулай һәр эше белән ул табигатьнең бик тә маһир иҗатчы булуын тәкрарлый бара. Биредә автор, чыннан да шулаймы соң бу, кебек икеле-микеле уйларга урын калдырмый. Барысы да ничек бар шулай, анадан тума, кем әйтмешли. Моңа кадәр хәтта ки күзгә-башка күренмәгән җилне дә («Чатыртау җиле») башкалар күрерлек, истә калдырырлык итеп тасвирлый белгән; кемдер тәгаен генә тәрҗемәсен таба алмый зар-интизар килгән бер заманда, «моң», «татар моңы»на сүздән «үз милизмнарын» өстәүче әдипнең сүз сурәтеннән күз сурәтенә күчү мәле бу. Искитмәле мөкәммәл эшләр!

"Марсель Галиев - татар халкының язмышы, тарихы, бүгенгесе, теле, әдәбияты, мәдәнияте, хәтта мәзәге турында фәлсәфи фикер йөртүче әдип. Аның җитди, катлаулы, телгә бай иҗаты күпләрне җәлеп итә. Безнең халык һәрчак белемгә, яктылыкка омтылган, киләчәк буынны да шул рухта тәрбияләгән. Тирә-ягыбызда милли рухлы кешеләр булганда, уңдырышлы Азнакай ягыннан әле байтак талант ияләре чыгар.

## Марсель Галиев иҗатында туган як темасы

*Гайнуллина Сөмбел, 7 нче сыйныф,*
*«Тау Иле урта гомуми белем мәктәбе»*
*Җитәкче: Шакирова Дилбәр Сәгыйть кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Бу эш Татарстанның халык язучысы, татар халкының горурлыгы булган прозаик һәм шагыйрь Марсель Галиев иҗатын тирәнтен өйрәнү һәм аның иҗатында туган як темасының чагылышын күзәтү максатыннан чыгып башкарылды. Сайлап алынган темам бүгенге көндә бик актуаль.

Бурычлары:

1. Марсель Галиев хезмәтләре белән танышу.
2. Әдип иҗатында туган як темасының чагылышын күзәтү.
3. Өйрәнелгән материалларны әдәбият дәресләрендә, класс сәгатьләрендә, дәрестән тыш чараларда куллану.

Марсель Галиев әсәрләре тема һәм жанр ягыннан бик бай. Аның шигъри тәлгәшләрендә, проза әсәрләрендә дөнья матурлыгы, якыннарына мәхәббәт, динебезгә һәм туган ягыбызга, тарихыбызга, телебезгә чиксез хөрмәт чагыла. Аның лирикасында туган як темасы әйдәп баручы темаларның берсе булып тора.

Марсель Галиевнең, **“**Туган як**”** шигыре матур Азнакай төбәгенә багышланган. Лирик герой өчен туган як яме тормыштагы һәрнәрсәдән өстен. Аның туып-үскән ягында гына , “йолдызлар тәлгәш-тәлгәш сибелә”, “таулары ап-ак яллы болытларны тышаулый”, “абагалары чәчәк ата”, “суларында кояш йөзә”, “күкеләре меңгә кадәр саный”. Гипербола-арттыру, сынландыру алымнары аша лирик геройның соклану хисе үстерелә. Шигырьнең беренче строфасы болай яңгырый:

Шундый як ул, карагыз сез
Минем туган җиремә,
Йолдызлар хәтта кызыгып
Тәлгәш- тәлгәш сибелә.

Автор соңгы строфада үзенең яшәгән урынын сер итеп кенә укучыларга җиткерә.

Ышанмыйча сез сорарсыз:
Чынлап, андый җир кайда?
Сер итеп әйтәм алайса:
Аз-на-кай-да!...

Шагыйрь шулкадәр җылы итеп, сокланып үз туган ягы турында гына яза ала.

Автор “Танышу нидән башлана?” шигырендә туган авылын мактый. Аның кешеләре дә гадирак, суы да тәмлерәк, таңы да матуррак, һавасы да сафрак.

Ни генә юк авылымда
Тәмле чишмә сулары,
Кәҗә сукмагыннан менсәң,
Җил сызгыра таулары.

Аның бу шигырен укыганда синең алдыңда чылтырап аккан чишмәләре, биек таулары белән бөтен бер дөнья ачыла.

“Шәһәрдә нәүмиз хәтер” шигыренә игътибар итик. Бу әсәрендә шагыйребез үзенең туган авылын, анда үткән бала һәм үсмер чагын сагынуын гап- гади генә, әмма бик үтемле итеп тасвирлый. Бу шигырьне без туган нигезен сагынуның югары дәрәҗәдәге үрнәге, дип әйтә алабыз. Аны, әлбәттә, хәтерендә калган авыл чишмәсе төбендәге чуерташлар, тегермән, тәмле алмалар сагындыра. Ул уендашларын, сугыш кичкән агайларны сагына. Аның хәтерендә ат җигәргә өйрәнүләр, аулак өйләр, кунак кызлары, ул чорның ярлылыгы һәм бай күңеле. “Туган ягын сурәтләгәндә ул хыялый бер үсмер, ялларын тузгытып далада чапкан кырыкмыш тай, беренче саф мәхәббәте кабынган гашыйк, туган җиренең газиз баласы сыман! Гаҗәеп эпитетлар, сынландырулар, ашкын хисләр тулып тора аның туган әсәрләрендә. Миңа калса, Марсель туган җирен, Азнакай буйларын, җир өстеннән генә түгел, кошлар очар биеклектән күзәтә”, - дип яза Гариф Ахунов.

“Китү” һәм “Кайту” шигырьләрендә автор геройның катлаулы рухи халәтен, каршылыклы күңел дөньясын бик тәэсирле итеп сурәтли. Туган җирдән киткәндә аның күңелендәге аерылу, үкенеч, чарасызлык хисләре, аңа кайткан вакытта рәхәтлек, шатлык, канәгатьләнү хисләре белән алышына.

“Актүбә чишмәләре” шигырендә сагышлы юлларның кабатлануы шигырьнең тәэсирлелеген арттыра, сагыну хисен тагын да көчәйтә. Шагыйрь туган ягына ашкына, аңа мәдхия җырлый.

“Әй туган җир” риторик эндәшүенең төрле урыннарда кабатланып килүе шигырьнең строфаларын үзара беркетә, үзәк фикерне эзлекле бирүгә ярдәм итә, авторыбызның үз иленең чын патриоты икәнен ассызыклый.

Әй туган җир,      җилләреңә
Серләрем сөйлим әле...
Әй туган җир, тауларыңа
таңнарда меним әле...
Әй туган җир, тугайларда
адашып калыйм әле.

“Туган як тургае” шигырендә ул туып- үскән җирендә генә бәхет тәмен белгәнен яза, аңа язу өчен илһамны туган ягы бирә. Туып- үскән нигез кеше күңеленә моң сала, аны канатлы, илаһи итә, яшәүгә көч өсти, онытылмас моң булып озатып йөри. Анда аны газиз әткәе белән әнкәе көтә.

Бәхет тәмен беләм
Туган җирдә генә,
Иген кырларына күмеләм.
Монда – гомер юлым,
Монда – туган моңым,
Тургай булып җырлый күңелем.

Бу нәфис яңгыраучы юлларда горурлану белән баетылган шатлык-сөенеч тасвирлана.

“Ераклыклар җиле” шигыренә игътибар итик:

Туган якның бүресе дә якын
Бөкресе дә гарип тоелмыйдыр,
Җыры тынмас салкын чишмәләрнең
Суын эчеп кенә туелмыйдыр.

Марсель Галиев үз шигырьләрендә балачактан күңелендә калган хатирәләрен яңартып, инде олыгайгач, уйландырган уйларын да язган. Аның әсәрләренә авторның йөрәге аша үтеп, шигырь юлларына әверелгән кичерешләр дәрьясы, уйланулар сыйган. Аның әсәрләре аша һәркем туган якның нindидер серле тарту көчен, сихри романтикасын тоя, шул хиснең чынлыгына, кеше өчен кадерле булуына ышана.

Марсель Галиевның иҗаты күпкырлы. Аның иҗатында туган як образы зур урын алып тора. Ватанына булган мәхәббәтен иҗат җимешләре аша укучыларына җиткерә ала. Үзенең иҗаты белән туган илне яратырга, аны сакларга, күңел белән тоемлый белергә өнди. Чыннан да, заманалар нинди генә үзгәрмәсен, ил тарихында нинди генә вакыйгалар булмасын, туган илне ярату тойгысы, аңа файда китерү теләге һич кенә кимергә тиеш түгел. Марсель Галиевның  туып-үскән ягы матурлыгын сурәтләп язган шигырьләре татар поэзиясенең иң уңышлы әсәрләре арасыннан урын алып тора. Аның иҗади мирасын ныклап өйрәнергә кирәк. Аның шигърияте әле күп кенә алдагы буыннарны уйландырачак, үзе белән хыял дөньясына, рухи кичерешләр дәрьясына алып керәчәк.

## "Укучыларның сәнгатьле сөйләменә ничек ирешергә?" темасы буенча мастер-класстан тезислар (Марсель Галиев иҗаты үрнәгендә)

*Галиева Айгөл Рашат кызы,“Азнакай шәһәре*
*8 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең*
*татар теле һәм әдәбият укытучысы*

Белем бирүдә федераль дәүләт стандартларын гамәлгә ашыру чорында, гомуми белем бирү оешмаларында татар әдәбиятын укыту мәсьәләләре тынгылык бирми.

Язучының биографиясен өйрәнү,әдәби әсәрне анализлау, шигырьләрне яттан өйрәнү генә затлы әдәби мирасыбызны киләчәк буынга җиткерергә ярдәм итәрме? Дөрес итеп, сәнгатьле уку бу очракта нинди урын тота? Бүгенге көн укучыларыбыз сәнгатьле итеп сөйләшә беләме? кебек сораулар барыбызны да эзләнергә мәҗбүр итә.

Сәнгатьле сөйләм дигән төшенчә бик киң тармаклы. Ул үз эченә дикция, темп, интонация һәм алар белән бәйләнешле мимика, ишарә, шулай ук аралашу культурасы элементларын ала.Тикшеренүләр шуны күрсәтә: кайбер балаларның сөйләме тиз һәм аңлаешсыз була. Сөйләм вакытында кабер бала авызын тиешенчә ачмый, аның авазлар артикуляциясе көчсез була. Мондый сыйфатлар тора-бара формалаша һәм камилләшә.

Кешенең шәхси интонациясе-бәяләп бетергесез көчле корал, хәзинә ул. Якын кешеңнең тавышы әллә ни гомерләр үтсә дә хәтердә тора, аны йөз кеше тавышыннан шундук аерып аласың, бер аваз, бер тавышның тирбәнеше әллә ни чаклы хәтирә уята.

Түбәндәге эш юнәлешләре укучыларда сәнгатьле укуга омтылыш уятуда зур урын алып тора:

1. Сәнгатьле сөйләмгә өйрәнгәндә, сөйләм тактларын таба белү мөһим. Моның өчен мәгънәле сүзтезмәләрне аерып алырга кирәк. Сүзтезмәләр арасына горизонталь сызыклар кую.
2. Мәгънәви басым билгеләү. Сезнеңчә, иң мөһим сүз кайсы? Шул сүзнең асларына сызып чыгу.
3. Башкару темпын билгеләү.

Сәнгатьле сөйләмгә өйрәткәндә, түбәндәге алымнар мөһим булып тора:

-балаларда сөйләм тавышын урнаштыру.

-сөйләм һәм яңгырау аппаратын күнектерү.

-текстны күзаллый белү.

-сөйләм тактларын табу.

-мәгънәви басым һәм башкару темпын билгеләү.

Югарыда санап киткән сөйләмгә өйрәтү алымнарыннан тыш, тавышның яңгырашы да әһәмиятле урын алып тора. Тавышның көчәюе, куәтләнүе яки кимү дәрәҗәсе сөйләмне матурлый һәм җанландырып җибәрә. Дәреслекләрдә тавышны төрлечә үзгәртеп укуга нигезләнгән күп кенә әсәрләр бирелгән. Бу максатны тормышка ашыруда якташыбыз Марсель Галиевның иҗаты ярдәмгә килә. Аның кыска шигырьләре дә, этюдлары да, кыска хикәяләре дә, шул ук вакытта повестьларыннан өзекләрне укыганда да, төрле интонация куелышын искәрәсең. Әлбәттә, моңа укучыларның да игътибарын җәлеп итәргә кирәк дип саныйм. Нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә, балаларны сәнгатьле сөйләмгә өйрәтү, сөйләмне аңлап кабул итү сәләтләрен үстерү, авазларны,сүзләрне дөрес әйтүне камилләштерү-бүгенге көннең әһәмиятле мәсьәләләреннән берсе булырга тиеш. Һәм, без-татар теле һәм әдәбияты укытучылары-бу максатыбызга туган як язучыларыбызның иҗатына мәхәббәт, кызыксыну тәрбияләү белән бергә алып барырга тиеш.

## “Хыялымда,качып кына, Туган як, сиңа кайтам “
## (Марсель Галиев иҗатында туган як темасы)

*Гарифуллина Ясминә, Дема Карина, 10 нчы сыйныф,*
*Азнакай шәһәре 2 нче муниципаль гомуми урта белем бирү мәктәбе*
*Җитәкче: Семенова Рәмилә Хәсән кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Азнакай төбәге күренекле шәхесләргә бик бай. Шуларның берсе-Марсель Галиев. Якташ язучы буларак Марсель Галиев иҗатын тирәнрәк өйрәнү максатыннан эзләнү эшебезнең темасы “Хыялымда качып кына, туган як сиңа кайтам “ ( Марсель Галиев иҗатында туган як темасы) дип билгеләнде.

Тикшеренү эшенең актуальлеге-2021 нче ел Татарстанда туган телләр елы буларак билгеләнүдә, ә туган тел туган як, туган төбәк ул. М. Галиевнең, беренче чиратта, кеше буларак табигатькә, туган төбәгенә карашы нинди? Үз укучысына ул бу юнәлештә нәрсә әйтергә тели?

Эшебнең максаты-шагыйрьнең туган якка багышлап язган шигырьләрен өйрәнү, барлау һәм анализлау.

Эзләнү обьекты-М. Галиевнең иҗаты, ә эзләнү предметы-туган як турында язылган шигырьләре.

Эзләнүләрдән күренгәнчә, Марсель Галиев иҗатында туган як темасы мөһим бер тема булып тора. Язучы туган ягы, аның табигате белән чиксез горурлана.

Һәркемнең беренче кат дөньяга күзе ачылган, тирә-якның чиксез матурлыгын тоеп куанган туган ягы, шул туган якның күңелгә якын бер үзенчәлекле җире, урыны була... Марсель Галиев өчен ул-Чатыр тавы. М. Галиев үзенең иҗатында Чатыр тауга бик күп мәртәбәләр әйләнеп кайта. Юк, гади бер географик атама итеп кенә түгел, ә җанлы итеп, ак сакаллы зирәк картка мөрәҗәгать иткән кебек ул аңа эчке горурлык, ихтирам, үз итеп-яратып, сөеп эндәшә.

Туган җирен, туган авылын даими сагынып, үткәннәрне һәрвакыт барлап, аларны хәтердә яңартып тору туган ягын сагынып яшәүче һәрбер кеше өчен ят нәрсә түгел. М. Галиев тә үзенең поэзиясендә эчкерсез бер сагыну белән, шул вакытларны шигырь юлларына сала.

Табигатьтәге гади генә үзгәрешләрне күреп, аларны йөрәк түреннән үткәреп, шигырь юлларына энҗе бөртеге тезгән кебек тезеп язылган шигырьләрен укып гаҗәпкә каласың. Кабатланмас тирән фикерләр, шул ук вакытта гади, матур, үзәкне өзгеч якын, самими дә алар.

Марсель Галиев шигъриятен күзәтеп чыкканнан соң, аерым нәтиҗәләр ясарга мөмкин. Әлеге эзләнү эшендә, барыннан да элек, М.Галиев поэзиясендә туган як темасын ачыклау бурычы куелган иде. Эзләнү эшендә тикшерелгән мисаллар нигезендә, барыннан да элек, шуны күрсәтеп үтәргә кирәк: аның иҗаты күпкырлы. Билгеле булганча, һәрбер шагыйрь өчен актуаль һәм газиз булган уртак темалар байтак: туган ил, туган як һәм туган туфракны сагыну; туган җирнең гүзәл табигате, аның урман-кырлары, инеш-чишмә-елгалары, урманнары... Әнә шуларга багышланган шигырьләр һәрбер шагыйрьдә, шул исәптән М.Галиевтә дә бар. Биредә М.Галиев шигъриятенә генә хас аерым үзенчәлекләрне тагын бер тапкыр күрсәтеп үтәргә кирәк. Барыннан да элек, М.Галиев шигърияте аның тормыш юлы белән тыгыз бәйләнгән, шагыйрьнең бик күп иҗат җимешләре үз автобиографиясенең турыдан-туры чагылышы булып тора. Бәлки нәкъ әнә шуңа күрәдер, аның шигъриятендә иркен болыннары, туган як каеннары, чишмәләре-таулары ярдәмендә

гәүдәләнеш тапкан җирсү темасы; башка бер генә шагыйрьдә дә бу кадәр тирән һәм киң чагылыш тапмаган туган як темасы урын ала.

Аның иҗаты кешеләргә, туган якка, гомумән, безне чолгап алган һәрнәрсәгә тирән мәхәббәт нәтиҗәсендә тугандыр кебек. Ул үзенең иҗаты белән безне туган җиребезне яратырга, аның табигатен сакларга, баетырга чакыра. Үзе дә ул туган ягының, туган табигатенең көчле бер патриоты булып күңелдә кала.

## “Чатыр тау-зәңгәр пирамида. М.Галиев иҗатында туган як темасы һәм аны ачуда кулланылган кайбер алымнар”

*Гатиятуллина Алия, 10 нчы сыйныф,*
*“Азнакай шәһәре 3 нче урта гомуми белем мәктәбе”*
*Җитәкче: Тинбакова Римма Варисовна,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Марсель Галиев-Татарстанның халык язучысы, прозаик һәм шагыйрь. Алай гына да түгел, ул-безнең горурлыгыбыз да. Аның иҗатына күз салсак, барыбызга да якын булган туган-үскән ил, туган як темасы аерым бер югарылыкта торуын күрербез. Әлеге теманы ачуда язучы төрле алымнардан бик оста файдалана. Шуңа күрә әлеге эзләнү эшенең темасын да шул форсаттан чыгып сайладым. Ул гына да түгел, бу тема һәрвакыт актуаль һәм шулай булып калачак та.

Алда торган бурычлар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. Марсель Галиев иҗатын өйрәнү, хезмәтләрен барлау;
2. Әдип иҗатында туган як темасының бирелешен күзәтү, кулланылган алымнарны ачыклау.

Әлеге материалны әдәбият дәресләрендә, дәрестән тыш чараларда, класс сәгатьләрендә кулланырга була. Шулай ук, каләм тибрәтүчеләр өчен дә әлеге хезмәт файдалы булыр.

Марсель Галиев, язучы буларак, төрле жанрларга һәм темаларга мөрәҗәгать итеп яза. Кайсы жанр яки темага гына кагылмасын, әсәрләре югары дәрәҗәдә зәвыклы һәм яңгырашлы килеп чыга. Шигырьләрендә, проза әсәрләрендә туган илнең, туган якның матурлыгын данлау, дөньяны ярату, якыннарына, җир кешесенә хөрмәт һәм мәхәббәт, дингә, тарихыбызга, телебезгә чиксез ихтирамы ярылып ята. Ә туган як темасы-аның лирикасында төп темаларның берсе.

Әйтеп китәргә кирәк: Марсель Галиев чыгышы белән Азнакай ягы кешесе. Язучы булып китүенә дә нәкъ менә шушы якның матур табигате, тырыш һәм күңеле белән матур кешеләре, данлыклы Чатыр тауның өлеше бардыр. Әлбәттә, иҗатында да язучы бу якка дан җырламый калмый. Әлеге темага кагылышлы әсәрләренең күбесе дә шушы якның елгаларына, урманнарына, басуларына, хәтта атар таңнарына кадәр багышланган. Туган ягын яратучы һәр укучы күңеленә ул шушы әсәрләре белән үтеп керә дә инде. Чөнки туган ягын чын күңелдән яратучы, аңа омтылучы гына башкалар йөрәгенә үтәрлек әсәрләр иҗат итә ала. Әсәрләрендә туган як образын ул нинди алымнар белән генә сурәтләми.

Менә “Туган як” шигырен генә алыйк. Ул турыдын-туры Азнакай ягына багышланган. Лирик герой өчен туган ягының яме тормыштагы һәрнәрсәдән өстен. Аның туып-үскән ягында гына “йолдызлар тәлгәш-тәлгәш сибелә”, “таулары ап-ак яллы болытларны тышаулый”, “абагалары чәчәк ата”, “суларында кояш йөзә”, “күкеләре меңгә кадәр саный”. Әлбәттә, һәркемнең туган ягы үзе өчен шулай.

Шунлыктан шагыйрь әйтергә теләгән хисләр-һәркемнең хисләре белән туры килә. Ә әсәрләредә кулланылган гипербола-арттыру, сынландыру алымнары аша лирик геройның соклану хисе үстерелә. Шигырьнең беренче юллары түбәндәгечә яңгырый:

Шундый як ул, карагыз сез минем туган җиремә,
йолдызлар хәтта кызыгып тәлгәш- тәлгәш сибелә.

Ә соңгы строфада исә шушындый туган якның "адресын" "сер итеп" кенә укучыга җиткерә.

Ышанмыйча сез сорарсыз:
Чынлап, андый җир кайда?
Сер итеп әйтәм алайса:
Аз-на-кай-да!...

Язучы "Танышу нидән башлана?" шигырендә туган авылына дан җырлый. Аның кешеләре дә матуррак, суы да тәмлерәк, таңы да матуррак, һавасы да сафрак.

Ни генә юк авылымда
Тәмле чишмә сулары,
Кәҗә сукмагыннан менсәң
Җил **сызгыра** таулары.

Аның бу юллары һәркемнең шундый ук туган ягы күренешләре белән аваздаш. Шуңа күрә һәркемнең күз алдына үз туган ягы килеп баса. Бу-осталык түгелме?

"Шәһәрдә нәүмиз хәтер" шигыре. Бу әсәрендә шагыйрь үзенең туган авылын, анда үткәргән бала вакытларын, үсмерлек елларын сагынуын гап-гади генә, әмма бик үтемле итеп тасвирлый. Туган ягын сагынган кешенең хисләре бу әсәрендә югары дәрәҗәдә бирелгән. Аны нәрсәләр сагындыра соң? Авыл чишмәсе төбендәге чуерташлар, тәмле алмалар, тегермән сагындыра. Ул уйнап үскән яшьтәшләрен, сугыш кичкән агайларны сагына. Хәтерендә-ат җигәргә өйрәнүләр, аулагыйлар, кунак кызлары, ул чорның ярлылыгы һәм бай күңеле.

"Туган як тургае" әсәрендә ул бәхетне бары тик туган ягында, туган җирендә генә татый алуын яза. Язар өчен илһамны да, яшәр өчен көчне дә ул шушыннан ала. Монда аны иң кадерле кешеләре-әтисе белән әнисе көтә. Түбәндәге юлларда туган ягы белән горурлануы да, шатлыклы хисләре дә тасвирлана:

Бәхет тәмен беләм
туган җирдә генә,
иген кырларына күмеләм.
Монда-гомер юлым,
Монда-туган моңым,
тургай булып **җырлый** күңелем.

"Ераклыклар җиле" шигыре аерым көчле яңгырый:

Туган якның бүресе дә якын
Бөкресе дә гарип тоелмыйдыр,
Җыры тынмас салкын чишмәләрнең
Суын эчеп кенә туелмыйдыр.

Бу юлларда язучы, образлар һәм аларга хас булырга тиеш билгеләрнең капма-каршысын кулланып, туган якның бөтен барлыгы белән идеаль булуы күрсәтә.

Туган ягын сурәтләгәндә, язучы төрле ел фасылларына еш мөрәҗәгать итә. Ел фасылларына бәйле рәвештә, хис-тойгыларын, күңел кичерешләрен ачып бирә, фәлсәфи уйланулар да кичерә. Мәсәлән "Көз һәм без", "Көзне бүлеп", "Пейзаж",

“Җәй хозурында”, “Яз сулышы”, “Зиратта яз”, “Беренче кар”. Табигать күренешләре дә аерым игътибарда: “Иртәнге кояш”, “Яңгыр”.  Алар аша да туган якның бердәнберлеген, матурлыгын, кешегә бирелгән байлык булуын аңлап була.

Сурәтләү чараларына килсәк, туган якның гүзәллеген, аны яратуын Марсель Галиев аларның  һәртөрлесе аша чагылдыра, югары дәрәҗәдә осталык белән куллана. “Булсын иде” шигырендә ул авылын ни өчен сагынып кайтуын антитеза сурәтләү чарасы ярдәмендә аңлата. “Зур шәһәрдә яшел болыннар, киң кырлар, көтүдән юашланып кайткан сыерлар, балыклы инешләр булса, мин авылны сагынып кайтмас идем” -, дип яза. М.Галиевның лирик герое-шәһәрләшеп килүче кичәге авыл кешесе. Ул-каршылыклы хисләр, уйлар иясе, авылны оныта алмау-аның үзенчәлекле сыйфаты. Лирик герой шәһәрдә яши, ләкин авылын, туганнарын, урманнарны, чишмәләрне, тауларны сагынып яши. Һәм шул ук минутта ул авылга кайтмаячак инде. “Китү” һәм “Кайту” шигырьләрендә автор геройның катлаулы рухи халәтен, каршылыклы күңел дөньясын бик тәэсирле итеп сурәтли. Туган җирдән киткәндә аның күңелендәге аерылу, үкенеч, чарасызлык хисләре аңа кайткан вакыттагы рәхәтлек, шатлык, канәгатьләнү хисләре белән алышына.

“Актүбә чишмәләре” шигырендә сагышлы юлларның кабатлануы шигырьнең тәэсирлелеген арттыра, сагыну хисен тагын да көчәйтә. Шагыйрь туган ягына ашкына, аңа мәдхия җырлый. “Әй туган җир” риторик эндәшүенең төрле урыннарда кабатланып килүе шигырьнең строфаларын үзара беркетә, үзәк фикерне эзлекле бирүгә ярдәм итә, авторыбызның үз иленең чын патриоты икәнен ассызыклый.

Әй туган җир, җилләреңә
Серләрем сөйлим әле...
Әй туган җир,тауларыңа
таңнарда меним әле...
Әй туган җир, тугайларда
адашып калыйм әле.

Сынландырулар, чагыштырулар Марсель Галиев әсәрләрендә аерым бер осталык белән кулланыла. Алар туган яктагы һәрнәрсәне тоярга, аңларга ярдәм итә. “Туган якның карашы” шигырен алыйк:

Елга ярына таянган
Күпне күргән таллары.

Бу юлларда таллар күпне күргән, күп яшәгән акыллы картлар белән чагыштырыла, гүя таякка таянып, карашын каядыр төбәгән аксакаллар. Алар күпне беләләр, ләкин сөйләмиләр генә.

Ниһаять, “Чатыр тау” шигыре. Әлеге мәгрур тау ерак пирамидалар белән чагыштырыла.

Ерактан ук-зәңгәр пирамида.
Чал Уралның соңгы дулкыны.

Гомумән, Марсель Галиев әсәрләрендә үзе яратып сурәтли торган һәр табигать күренеше җанлы, алар һәрвакыт хәрәкәттә, һәм бу хәрәкәт сынландырулар, чагыштырулар аша бирелә, сурәтләнә:

Җил йомгагы булып, кылганнары
Үзәннәргә таба йөгерә.
Кайнап аккан ак болытлар аша
Тау кояшка гүя үрелә.

Ә төннәрен чума офыкларга,
Син ерактан карап тор гына
Куакларда әле төн кунаклый,
Тау башында инде яңа тау.
“Чатыр тау”

Гомумән, Марсель Галиев әсәрләре аша һәркем туган якның ниндидер серле тарту көчен, сихри романтикасын тоя, шул хиснең чынлыгына, кеше өчен кадерле булуына ышана. Аның әсәрләре һәркемнең йөрәгендә йөргән, туган якка карата булган хисләрне ача, тартып чыгара, уйландыра, тәрбияли.

Марсель Галиевның иҗаты киң һәм күпкырлы. Аның иҗатында туган як образы, чыннан да, гаять зур урын алып тора. Ул туган ягына, җиренә булган олы мәхәббәтен үзенең иҗат җимешләре, анда төрле әдәби алымнардан гаять оста куллануы аша укучыларына җиткерә алган. Шигырьләрендә туган илне яратырга, аны сакларга, күңел белән тоемлый белергә өнди. Туган яктан китмәскә, шунда төпләнеп яшәргә чакыра, аерылуның авыр булуына басым ясый. Вакытлар ага торыр, заманалар үзгәрер, илләр тарихында башка да сыймаслык вакыйгалар булыр, ләкин туган як, туган җир төшенчәсе калыр, туган илне ярату тойгысы, аңа файда китерү теләге һич кенә кимергә дә тиеш түгел.

Марсель Галиевның туган якның матурлыгын сурәтләп язган шигырьләре татар поэзиясенең иң уңышлы әсәрләре арасыннан урын алган. Аның иҗади мирасын тирәнтен өйрәнергә кирәк. Шигърияте күп кенә алдагы буыннарны уйландырачак әле, үзе белән хыял дөньясына, рухи кичерешләр дәрьясына алып керәчәк.

## Марсель Галиевның балалар өчен язган әсәрләрендә әхлак темасының бирелеше

*Җиһангиров Риназ, 5 сыйныф, “Азнакай шәһәре*
*6 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе”*
*Җитәкче: Газизова Зөлфия Рәис кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Әдәби китапларны яратып, чын күңелдән бирелеп укыган баланың белеме тирәнрәк, күңеле баерак була. Аның кешеләргә игътибары арта, күркәм эшләр башкарырга омтылышы көчәя. Шуңа күрә мин үземнең фәнни эшемдә дә нәкъ менә шул актуаль мәсьәләне күтәреп чыгарга булдым.

Фәнни эшемнең темасы – Марсель Галиевның балалар өчен язган әсәрләрендә әхлак темасының бирелеше”. Әлеге фәнни эшне язарга алынганда, мин үземнең алдыма түбәндәге максатларны һәм бурычларны куйдым:

1.Шагыйрь, язучы иҗатына күзәтү ясау һәм әхлак үзенчәлекләрен билгеләү. Шулар ярдәмендә укучыларда югары әхлак сыйфатлары булдыру.

2.М.Галиевның  балалар әдәбиятында тоткан әһәмиятле урынын күрсәтү.

3.М.Галиев иҗатын уку, өйрәнү.

Фәнни-тикшеренү эшемнең төп объекты- якташыбыз Марсель Галиев иҗаты; предметы- әхлак темасын күтәреп чыккан әсәрләре.Әлеге эшне башкарганда түбәндәге метод-алымнар кулланылды: күзәтү, гомумиләштерү, тикшеренү, эзләнү, анализлау, нәтиҗә ясау. Фәнни эшемнең структурасы түбәндәгечә: Кереш өлештә мин максатларны,бурычларны билгеләдем, максатка ирешү өчен башкарган эшләремне, фәнни эшемнең структурасын күрсәттем. Төп өлеш М.Галиевның

иҗатында әхлак темасын ачуга багышланды. Аның балалар өчен язган әсәрләренә күзәтү ясалды. Йомгаклау өлешендә эшемнең төп нәтиҗәләрен чыгардым: фәнни-тикшеренү эшем алдына куйган максатларга ирештем. Марсель Галиевның балалар өчен язган әсәрләрендә әхлак темасын күтәреп чыккан тәрбия мәсьәләләренә тукталдым,үз фикерләремне нигезләдем.

## “**Бәхетле очрак**” **уены**

(Марсель Галиевнең тормыш юлына багышланган класстан тыш эшчәнлек)

*Загитова Зинфера Ильяс кызы, Закирова Фәридә Марат кызы,*
*Мәлбагыш авылы урта белем бирү мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбиятыукытучылары*

Максатлар:Марсель Галиевнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне камилләштерү; укучыларның фикерләү сәләтләрен, сөйләм телләрен һәм җитезлекләрен үстерү; патриотизм хисе тәрбияләү; туган (татар) телен укытучы коллегалар белән тәҗрибә уртаклашу.

Шәхескә кагылышлы УУГ: уку эшчәнлеге һәм аның мотивлары арасында элемтә урнаштыру.

Регулятив УУГ: укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү; кагыйдәләрне истә тотып гамәлләр кылу.

Танып белү УУГ: логик фикерләүне үстерү гамәлләре башкару (анализ, синтез); тиешле мәгълүматны сайлап алу; төп мәгълүматны аеру;

Коммуникатив УУГ: үз фикерләрен төгәл, ачык, аңлаешлы итеп әйтергә өйрәтү.

Җиһазлау: Марсель Галиевнең портреты, китаплар күргәзмәсе, ноутбук, диск (Марсель Галиевнең сүзләренә иҗат ителгән җырларның аудиоязмалары), тур атамалары язылган слайдлар (презентация).

Дәрес барышы.

Оештыру өлеше.

<u>Укытучы.</u> Исәнмесез, укучылар! Хәерле көннәр сезгә. Зиһен һәм тел ачкычлары телимен һәммәгезгә. Утырыгыз. Үзебезнең чираттагы класстан тыш эшчәнлегебезне башлыйбыз. Бүгенге класстан тыш эшчәнлегенә сез якташыбыз Марсель абый Галиев турында әзерләнеп килдегез. Без шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәребезне камилләштерербез.

Төп өлеш.

<u>Укытучы.</u> Бүгенге класстан тыш эшчәнлеген «Бәхетле очрак» уены рәвешендә уздырырбыз. Уенда ике команда катнаша. Хәзер командаларга бүленәбез, һәр команда үзенә исем, девиз, капитаннарны билгели. 1 нче команда-«Чатыр- тау». Девиз: «Чатыр тау белән-мактаулы без». Капитан-Лилия. 2нче команда-«Җилкәннәр». Девиз: «Җилкәннәр җилдә сынала». Капитан-Ильяс.

<u>Укытучы.</u> Димәк, безнең уенда «Дуслык» һәм «Җилкәннәр» командасы ярыша.

I тур «Кем тизрәк?» дип атала. Әлеге турда мин сезгә сораулар бирәм, ә сез тиз итеп дөрес җавапны бирергә тиеш буласыз. Кайсы команда җавап бирә алмый, сорау көндәш командага күчә. Бирем аңлашылдымы?

<u>Балалар</u>. Аңлашылды.

<u>Укытучы.</u> Уенны башлыйбыз.

1. Марсель Галиевнең туган көне, ае, елын атагыз. (8 октябрь 1946)
2. Әтисенең исеме ничек? (Баян абзый)

3.Марсель Галиевнең туган җире кайда? (Азнакай районы Балтач авылы)

4.Әти-әнисе кем булып эшлиләр? (Колхозчылар)

5.Шагыйрь  кайда укый? (Азнакайдагы 1 нче номерлы урта мәктәбен тәмамлый)

6.Аттестат алгач, шагыйрь нишли? (Төзүче-монтаж идарәсендә эшли)

7.Тормыш юлын кайда дәвам итә? (1969 елда Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга керә)

8.Кулына диплом алгач, кайда эшкә урнаша? (Татарстан Язучылар союзының әдәбиятны пропагандалау бюросында әдәби хезмәткәр, "Казан утлары" журналы редакциясендә проза бүлеге редакторы булып эшли)

9.Өстәмә югары белеме бармы? (1983 нче елда Мәскәүдәге Югары әдәби курсларда укый)

10.Марсель Галиев нинди жанрларда иҗат итә? (Проза, поэзия)

11.Марсель Галиевнең әсәрләре нинди телләргә тәрҗемә ителгән? (Марсель Галиевнең аерым әсәрләре рус, поляк, украин,үзбәк, казакъ, каракалпак, осетин, чуваш телләренә тәрҗемә ителгән.)

12. Бу нинди өзек?

"Исәнме, мәгърур тау!

Туган як тәхете – Чатыр тау, исәнме!..

Бакый заманнарда, дәһшәтле бозлык чорында, мамонтларның күз карашын хәтереңә сеңдереп калыккансың да, бүген инде, туган ягымның йөзек кашы булып, күпме күңелләрне әсир иткәнсең.

Янәшәңдәге дулкын-дулкын таулар иңенә басып меник әле синең ияреңә.

И бу җиһанның гадел минутлары…

И бу җанның убылыр упкыннары…"( Чатыр тау җиле)

13.Нинди әсәрләрен beләсез? ("Ул чакта","Ерак  урман авазы" романы,"Ак абагалар" лирик повесте,һ.б)

14.Казан университетының журналистика бүлегендә ул ничәнче елларда укый? (1969-1974)

15.1970 нче елда шагыйрьнең тормышында нинди вакыйга була? ( бер төркем шигъри әсәрләре яшь шагыйрьләрнең күмәк «Беренче карлыгачлар»  дигән шигырьләр җыентыгына  керә)

16.Нинди шигырьләренә  көй язылган? ("Су буеннан әнкәй кайтып килә", "Көзге моң", "Кайту")

17.Марсель Галиевнең  әдәбиятның нинди өлкәләрендә каләмен сыный (Юмор-сатира жанрында "Кәефең шәпме?", балалар әдәбияты "Ак рәсем", драматургия, әдәби тәрҗемә)

18.Марсель Галиевнең нинди бүләкләре бар? (1998 ел "Догалы еллар" "Татнефть"нең "Рухият" яңарыш фонды оештырган әдәби конкурста беренче дәрәҗә дипломга лаек, 1993 елдан "Татарстанның атказанган сәнгать эшлексе" исемен йөртә, 1996 ел ТР Мактау грамотасы белән бүләкләнә, 2006 нчы елда  ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.)

Укытучы. Шушының белән сораулар бетте. Ә без алдагы турга күчәбез.

II.тур «Капитаннар – алга!» дип атала.

Укытучы.  Капитаннарга 3 минут вакыт бирелә. Чатыр тавым сүзендәге хәрефләрдән кем күпме яңа сүз төзи. Вакыт җиткәч, эшләрегезне жюрига тапшырасыз.

Җанатарлар чыгышы. *(Марсель Галиев сүзләре, Луиза Батыр-Болгари көе «Су буеннан әнкәй кайтып килә» җыры башкарыла)*

III. турга күчәбез. Ул «Син-миңа, мин-сиңа» дип атала. Бу турда командалар бер-берсенә Марсель Галиевнең тормыш юлы һәм иҗатына караган сораулар бирәләр. Сораулар һәр командага да икешәр. Әгәр команда сорауга җавап бирә алмый икән, команда үз соравына үзе җавап бирә.

Балалар.

1.Язучы кайсы әсәрен кабат-кабат укып ләззәт ала? (“Рух” әсәре)

2.Туган якка мәхәббәт гомерлек була аламы? (Якыннар, дуслар китә бара, алар белән хисләр дә сүрелә икән шул. Чатыр тауга менәрлек дуслар сирәгәя бара. Авылда безнең нигез юк инде. Кайтып, галуш киеп, иске чалбардан, сүсәргән күлмәк киеп йөреп булмый.)

3.Шагыйрьнең шигырьләренә нинди композиторлар көй язган? (Луиза Батыр-Болгари, Ганс Сәйфуллин һ.б.).

4.Шагыйрь ничәнче елдан язучылар берлеге әгъзасы? (1979 елдан).

Укытучы. Хәзер IV турны башлар вакыт җитте. Әлеге турда без командаларның башваткычларны чишүдә җитезлекләрен карыйбыз, һәр командага да «Сүзне эзләп тап» биремен бирәм. Әлеге биремне эшләгәндә өстән аска һәм сулдан уңга йөреп сүзләрне дөрес тапсагыз «Шушы яктан, шушы туфрактан без» дигән алтын сүзләр килеп чыгарга тиеш.

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| я | м | я | к | т | а | н | е | ш | Т |
| а | е | ң | ф | х | е | ф | п | р | У |
| ш | п | җ | ш | у | ш | ы | н | я | Ф |
| у | п | э | а | п | г | ш | ф | с | Р |
| ш | г | ж | җ | о | е | д | т | и | А |
| ы | л | ъ | ч | л | ш | ң | х | һ | К |
| я | ч | ю | б | в | п | л | һ | ң | Т |
| с | с | у | е | э | п | о | н | у | А |
| т | л | й | з | ш | г | ң | к | ф | Н |
| ь | г | з | р | в | и | ж | ю | н | З |

Укытучы. Шушы тур белән безнең уеныбыз тәмамлана. (Уенга нәтиҗә ясала).

**Йомгаклау өлеше.**

Укытучы. Марсель Галиевнең тумышы белән җырларда җырланган, бик күп мәшһүр затларны, биргән атаклы Азнакай ягыннан, татар теленең, халык моңының табигый төбәгеннән. Марсель Галиев сүз сәнгатенең бөтен нечкәлекләрен белеп, тел дәрьясында судагы балык кебек эш итә икән, монда, әлбәттә, Азнакай ягының да роле зур. Туган төбәк, аны сагыну хисләре, әдипнең иҗатында да калку гәүдәләнеш тапкан.

# Марсель Галиевның “Нигез” повестенда фразеологизмнар

*Зарипова Зәлинә,10 нчы сыйныф*
*“2 нче санлы Урыссу гомуми белем бирү мәктәбе”*
*Җитәкче: Йосыпова Руфина Рим кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Фәнни хезмәтебез Марсель Галиевның “Нигез” повестендәге фразеологик әйтелмәләрне куллануның әһәмиятен билгеләүгә багышлана.

Максатыбыз: Марсель Галиевның “Нигез”әсәрендә фразеологик әйтелмәләрне куллануның әһәмиятен билгеләү.

Шушы максаттан чыгып түбәндәге бурычлар билгеләнде:

-Фразеология һәм идиоматик ага караган фәнни әдәбият белән танышу;

-М.Галиевның тормыш юлына һәм иҗатына күзәтү ясау;

-М.Галиев повестенда кулланылган фразеологизмнарны табып төрләрен ачыклау,аңлатма бирү.

Без исбатларга теләгән гипотеза: Марсель Галиев фразеологизмнар кулланып, әсәрдәге геройларның эчке кичерешләрен ныграк ачуга ирешкән.

Марсель Галиевның иҗаты XX гасырның туксанынчы елларында киң җәмәгатьчелек алдында танылу таба. Иҗатын төрле юнәлешләрдә үстереп, ул җәмгыятебезне борчыган проблемаларны колачлый ала.

Драматург Т. Миңнуллин сүзләренә генә игътибар итик: «Марсель Галиев фикер тирәнлеге белән тел нечкәлеген тәңгәл китерә белгән язучы. Аның күңеленнән чыккан, кулыннан төшкән һәр әсәр кояш нуры кебек ялтырап китә».

«Марсель Галиев-интеллектуаль поэзия вәкиле... Ул дөнья поэзиясенең яхшы үрнәкләренә йөз тотып иҗат итәргә омтыла»,-дип яза Равил Фәйзуллин.

Кояш Тимбикова: “Әсәрләренең ифрат затлылыгы язучының күңел хөрлегеннән дә киләдер. Күңелендәге хөрлек тәэсиреннән туган горурлыкны Марсель Галиев әсәрләренең теләсә кайсыннан тоярга мөмкин,- дип яза.

Фәрит Мөхәммәтшин язучы Марсель Галиев турында:Марсель Галиевны бик хөрмәт итәм. Ул үткен телле, йөрәккә барып җитә торган итеп яза. Бу егетебезне сакларга кирәк!”,- дип әйткән.

М. Галиев поэзия һәм проза жанрларында иҗат итә. Аның кеше җаны-рухындагы тирән уй-хис тирбәлешләрен заман, туган җир, туган табигать һәм тарихи хәтер белән бәйләп, тормыш вакыйгаларын югары сәнгать дәрәҗәсендә гәүдәләндергән «Нигез», «Алтын тотка» кебек лирик повестьлары прозаның яңа бер казанышы итеп бәяләнергә хаклы. Нигез» повестендә, Марсель Галиев, сүз остасы буларак, тормыш күренешләрен үзенчә сайлый, үзенчә эшкәртә,

«Нигез»-иҗатының йөзек кашы. Үзәктә-Өянке образы. Бу-самими хисләр, садә хыяллар символы. Машиналы заманны Өянке инде аңлап бетерә алмый, кешеләр дә инде бик аңлашылмый аңа. Патриархаль авыл юк инде. Әсәр ахырында Өянкенең җиргә авып төшүе дә шуңа ишарәдер. «Юлга аркылы ауган карт агач без белгән өянке түгел иде инде. Өянкенең асылы бу мәлдә кояш нурлары буйлап чиксез биеклеккә күтәрелә, дөнья хәтеренә кушылырга ашыга иде”

Марсель Галиев әсәрләрен укыганда, образларның төрлелегенә, сөйләмнәренең җанлылыгына хәйран каласың. Бу җанлылыкны бирүдә, әсәрдә кулланылган фразеологик әйтелмәләрнең роле зур.

Татар фразеологиясе өлкәсендә 1950-1990 нчы елларда шактый күп эшләр эшләнгән: 50 нче елларда Л.Җәләй, Л.Т.Мәхмүтова, Н.Б.Борһанова ике сүзлек бастырып чыгара. В.Виноградов өйрәтүе буенча, компонентларның берләшү дәрәҗәсенә карап, фразеологизмнарны өч төркемгә аерырга мөмкин: фразеологик ныгымалар, фразеологик бердәмлекләр, фразеологик тезмәләр.

Фразеологик ныгымаларны әсәрдәге мисаллардан карап үтик:

Кое янында мәш килгән хатын-кызларның,читән буеннан сөйләшеп узган ирләрнең,капка төбенлә гәп корган картларның сүзләрен дикъкать белән тыңлый торгач,тал-тирәк әкренләп кешеләр телен аңларга өйрәнде.(154)Районнан берәр вәкил килеп төшкәндер дә,фатирга миңа керткәннәрдер дип,котым очты.(200) -Әллә кем түгел икән...-дигән булып,кияүгә мөһер дә сугып куйдылар.(237)һ.б.

Фразеологик ныгымаларның мәгънәләрен ачыклыйк:

Мәш килгән-ыгы-зыгы килү,нәрсә беләндер бик мәшгуль булу;суматоха

Кот очу-бик нык курку;душа в пятки ушла

Мөһер сугу-ставить печать(клеймо)һ.б

Фразеологик бердәмлекләрне әсәрнең үзеннән табыйк:

Алар да искә аладыр,мин дә хәтергә төшерәм.(162)Аның усал итеп әйтүеннән Солтания таралып төште.(165)Сафуан абый килүгә,тын гына сөйләшеп утырган очташларга җан керә.(173)Аның йомышын үтәргә әзер сөенеч белән кереп әйткәч,Мәдинә апа бот чабып,тыела алмыйча көлде.(175)Арада бер Зәбирнең генә моңа исе китми,аның җылавын күтәргә түземе җитми Корычбайның.(188) Тын урамнан үземнең аяк тавышыма колак салып кайтып барам.(214)Стенага фотолардан кала бернинди сурәт элдермәгән әнигә нидер булды,күңеле тулуы тавышына ук чыккан иде.(225) һ.б

Мәгънәләренә килгәндә, бу җөмләләрдә файдаланылган фразеологик бердәмлекләр түбәндәгеләрне белдерәләр:

Хәтергә төшерү-воскресить в памяти

Таралып төшү-потерять дар речи

Җан керү-күңел тынычлану,придти в себя

Бот чабу-шаккату,гаҗәпләнү

Ис китү-кызыгу,гаҗәпләнү;приходить в изумление һ.б слайдта күрәсез.

Әсәргә мөрәҗәгать итсәк,бу фразеологик тезмәләрне шундый җөмләләрдә күрә алабыз:

Көн белән төн алынышкан минуттагы шушы манзара уртасында мин күпмедер вакыттан соң гына исемә киләм.(150)Аның йокыга киткәнен күз алдына китергәч,үзебезнең дә бер-бер артлы авызлар ачыла башлый(157)Атлар кешнәве,җылашу,эш белән изелгән ир-атларның беренче мәртәбә ачылып,үз хатыннарына җылы сүз әйтеп калырга ашыгуы,яшерен гыйшык тотып йөргән кыз-кыркын.(164)Җир тулы мәет арасыннан йөреп бәгырем катты минем.(165)

Байтирәк тә кинәт,үзен гаепле сизеп,сүздән калды.(166) һ.б.

Бу мисаллардагы фразеологик тезмәләр түбәндәге мәгънәләрне бирәләр:

Искә килү-аңга килү,хәтергә төшерү

Күз алдына китерү-уйлану,искә төшерү, хәтергә алу; представить себе

Җылы сүз-өметләндерә,рухландыра торган сүз;обнадеживающее слово

Бәгырь кату-бик каты рәнҗү,үпкәләү катыш ачу килү;душа зачерствела

Сүздән калу-потерять дар речи һ.б слайдта күрәсез.

Гомумән, М.Галиевның фразеологик тезмәләрне әсәрдә чагылдыруы әсәрне тагын да ныграк баета, тулыландыра. әдәби әсәр телен үзенчәлекле һәм яңгырашлы итә.

“Нигез”повестендә фразеологизмнар геройларның эчке кичерешләрен күрергә, тоярга, күңелебез аша үткәрергә ярдәм итә.

Төп геройның авылдашлары өчен кайгыруын түбәндәге фразеологизмнарда күрәбез.

Алар да искә аладыр,мин дә хәтергә төшерәм.(162)Тын кысыла.(170)Мин,өмет белән,аның гадәти кеше икәнен башка да китермәслек ниндидер өстен,илаһи көчкә ия булып күңелгә сеңгән рәсеменә карыйм.(170)Башланмас,илне күз карасы кебек саклагыз дигән бит.(170)

Без,малайлар,аңардан күзне ала алмыйбыз.(172)Мин алдынудан комачтай кызарсам да,Сафуан абый,буасы ерылган инеш кебек,көлә башлагач,җиңел булып китте.(175)

Тын урамнан үземнең аяк тавышыма колак салып кайтып барам.(214)Хәзерге хәрефләр белән язылган исемнәрне күздән кичерәм.(223)Байтирәк абзыйлар тыкрыгына борылыр алдыннан күңелемә сеңеп калган күренеш тагы мине тукталырга мәҗбүр итә.(232)Инде ачылыр мәле җиткән бөре биләүләрен кая яшерим,ничек җылытыйм дип,төннәрен ут йотып чыгам.(233)һ.б

“Авылдашлар”ы авырлык килсә дә, шатлыклары булса да, Өянке янына киләләр. Кайтканны каршылаучы да, киткәнне озатучы да – Өянке.Түбәндәге фразеологизмнар авылдашларының эчке кичерешләрен ачарга ярдәм итәләр:Ә монда... туган авылына кайтып җиткәч... сыгылды да төште.(198)Тоташ аклыкка әйләнеп тулышкан күз яшьләре тәгәрәп сукмакка төште дә челпәрәмә килде.(199) һ.б

Безнең максатыбыз –әсәрдәге фразеологизмнарны куллануның әһәмиятен билгеләү иде.Без үзебезнең хезмәтебез белән бу максатка ирештек.

Марсель Галиев иҗаты татар әдәбиятында үзенең лаеклы урынын алды. Күренекле язучыбыз киләчәктә дә яңадан-яңа әсәрләре белән безне куандырыр, дип, ышанабыз.

## Марсель Галиев иҗатын өйрәнгәндә диаманта алымын куллану

Мастер- класс.

*Ибатова Сөмбел Рашат кызы, Сәхбиева Рәмилә Рәис кызы*
*Азнакай шәһәре 4нче лицееның туган тел һәм әдәбияты укытучылары*

Исәнмесез, әдәбият яратучылар!

Исәнмесез, М.Галиев һәм аның иҗаты белән кызыксынучылар!!

Исәнмесез, туган тел дип җан атучылар!

Бүгенге чыгышыбыз “Марсель Галиев иҗатын өйрәнгәндә диаманта алымын куллану”.

Марсель ГАЛИЕВ шигырьләре... Алар әллә ничекләр итеп җанны актара, рәхәт бер халәттә тибрәтә. Күз алдында төсләр, матур сурәт-картина. Хисләр бии... Аның теле, стиле, аһәңнәре үзенә бертөрле, беркемнекенә охшамаган: затлы, нәзберек, нәфис. Шагыйрьлек җене, хыялый алдану бәхете... Иҗатына бәяләмәне дә шагыйрьнең үз сүзләре белән кабатлыйсы килә.

«Шигырь-мәңгелек упкынында тирбәлгән күңел бишеге...»

«Шагыйрь-Күк белән Җир арадашчысы!»

Болар Марсель Галиев фикерләре. Сүзләре, шигыре күңел тәлгәшеннән өзелгән.

Марсель Галиев әсәрләре тема һәм жанр ягыннан бик бай. Аның шигъри тәлгәшләрендә, проза әсәрләрендә дөнья матурлыгы, якыннарына мәхәббәт, динебезгә һәм туган ягыбызга, тарихыбызга, телебезгә чиксез хөрмәт чагыла.

Иҗатында каршылыкны белдергән төшенчәләрнең бик күп икәнен күззәттек: тел-телсезлек, дус-дошман, ахмак-акыллы, мәхәббәт-нәфрәт, ялган-дөреслек. Гомере буе ул тискәре күренешләр белән көрәшә, үз фикерен укучыга үтемле итеп җиткерә. ,,Китү'' һәм ,,Кайту'' шигырьләрендә автор геройның катлаулы рухи халәтен, каршылыклы күңел дөньясын бик тәэсирле итеп сурәтли.

Без сезне бүген каршылыкка нигезләнгән диаманта алымы белән таныштырып китәбез. Диаманта француз теленнән “бриллиант” дигәнне аңлата. Ягъни иң кыйммәтле, затлы асылташ.Төгәл геометрик формалы. Диаманта-рифмалашмаган 7 юллык шигырь, беренче һәм соңгы юлы капма-каршы мәгънәле сүзләр.

1,7нче юллар-капма-каршы 1 сүз язылa

2,6нчы юлларга - 2сыйфат (нинди?)

3,5 нче юлларда-3 фигыль (формасын укытучы ? белән юнәлеш бирә. Нишли? Нишлисең? Ягъни заманы, зат-саны)

4нче юл иң соңыннан языла. Монда 4сүз (яки 2сүзтезмә,4сүзле җөмлә)

Хөрмәтле укытучылар! Әйтегез әле, Марсель Галиев кем ул? (шагыйрь, язучы)

Шигырьләре нинди темага язылган? (туган як)

Туган ягын, аның гүзәллеген нәрсә белән чагыштырып тасвирлый? (чит ил белән)

Туган як – чит ил сүзләренә диаманта язып карыйк әле.

Туган як нинди? (кадерле, якын)

Чит ил нинди? (ерак, кояшлы)

-Менә язып куйдык.

Туган якта нишлисең?( туасың,яшисең,эшлисең)

Ә чит илдә нишлисең?( сокланасың, ял итәсең, кызынасың) Яхшы.

-Менә язып куйдык.

4нче юлга ике сүзгә дә туры килгән, аларның охшаш, уртак сыйфатлары .Нәрсә әйтеп була? 4сүз, 2сүзтезмә, 4сүзле җөмлә.Яхшы.

(Һәр мизгелнең кадерен бел)

Менә килеп тә чыкты.

Менә минем укучыларымның иҗаты.

Камалетдинова Кәмилә рус төркемендә укучы кыз.Авыл-шәһәр темасына төзегән диаманта.

*Татар төркемнәрендә әдәбият дәресендә Чатыр тау-Һималай сүзләренә . Вәлиев Әдел төзегән диаманта.*

Әдәбият дәресләрендә М.Галиев иҗатындагы каршылыклар белән диаманталар төзибез. Тел-телсезлек, дус-дошман, әни-әти, Ай-Кояш, ак-кара, ахмак-акыллы.

Сез дә бик яхшы, игътибарлы шагыйрьләр булдыгыз әле. Шагыйрь һәм укучы сүзләренә диаманта языйк әле.

Шагыйрь нинди? 2 сыйфаты

Укучы нинди? 2 сыйфаты

Шагыйрь нишли? (...) Яхшы.

Укучы нишли? (...) Яхшы.

Ә аларны нәрсә берләштерә? (...)

Бик яхшы. Ә хәзер эш нәтиҗәбез итеп шагыйрь һәм укучы турында диаманта язып карагыз әле. 3мин.вакыт.

( чыгышлар тыңлана)

-Диаманта язу сезгә ошадымы?(..)

- Ә менә үзегезнең дәресләрдә ничек кулланыр идегез?(...)

-Кайсы дәресләрдә , ничек кулланырга уйлыйсыз?

-Булдыргансыз. Бик яхшы! Димәк, диаманта алымының өстен якларын әйтеп китегез әле

Марсель Галиевның туып- үскән ягы матурлыгын сурәтләп язган шигырьләре татар поэзиясенең иң уңышлы әсәрләре арасыннан урын алып тора. Аның иҗади мирасын ныклап өйрәнергә кирәк. Аның шигърияте әле күп кенә алдагы буыннарны уйландырачак, үзе белән хыял дөньясына, рухи кичерешләр дәрьясына алып керәчәк.

,,Шагыйрьнең иҗатын аңлар өчен аның туган ягын күрергә кирәк”- дип язган Иоганн Гете. Менә без дә бүген шагыйребезнең туган төбәгендә булуыбыз белән бик бәхетле.

-Шулай итеп, диаманта үз фикереңне төгәл, ачык итеп әйтә белергә өйрәтә.Уку мәсьәләсен, сорауны стандарт булмаган күзаллау, анализлау,төркемдә килешеп эшләү. Укучылар кызыксынып, теләп. курыкмыйча эшлиләр. Укучылар бик теләп иҗат итәләр.

## Ат язмышы-халык язмышы
## (“Рух” әсәрендә ат образының бирелеше)

*Ибраһимова Ләйлә, 8 нче сыйныф,*
*«Азнакай шәһәре гимназиясе »*
*Җитәкче: Ибраһимова Чулпан Рәфәт кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

“Марсель Галиев-башкалардан бик нык аерылып торган язучы. Ул бөтен яктан аерылып тора: теле белән дә, стиле белән дә. Ул берәүне дә кабатламый, берәүгә дә иярми. Аның һәрнәрсәгә үз карашы, үз мөнәсәбәте. Бу дөньяның, тормышның яңа якларын ача белүе һәм шул күргәненә карата үзенең мөнәсәбәте, саф фикере булуы белән ул башкалардан нык аерыла һәм шуңа күрә ул кызыксыну уята. Әсәрләре белән кызыксыну уята алган Марсель Галиев безнең әдәбиятта үзенә аерым бер урын тота”, - дип яза Әмирхан Еники.

Марсель Галиев фикер тирәнлеге белән тел нечкәлеген тәңгәл китерә белгән язучы. Язган һәр җөмләсе укучыны гаҗәпләндерә. Аның күңеленнән чыккан, кулыннан төшкән һәр әсәр кояш нуры кебек ялтырап китә. Марсель Галиев һәр әсәрендә үзе булып кала.

Аның әсәрләре, кагыйдә буларак, интеллектуаль укучыны күздә тотып языла һәм ассоциатив чагыштыруларга, яңача көтелмәгән образлы тәгъбирләргә бай булуы белән аерылып тора. Шуңа күрә дә аның әсәрләрен кат-кат укырга кирәк. Шунда гына ул сиңа ачыла, күңел кылларына үтеп кереп сине тирән уйларга сала, аңны сискәндереп җибәрә.

“Әгәр күк катларыннан шундый фәрман килсә: "Бүтән планетага күченәсез, үзегез белән мең төрле җәнлек арасыннан тик берсен генә сайлый аласыз!" – дисә, кеше

һич икеләнмичә атның җылы муенына килеп сыенып иде,”- дип яза Марсель Галиев үзенең “Рух” әсәрендә. Шушы кызыклы фикер мине эзләнү-тикшерену эшенә этәрде. Әдәби әсәрдә язылган матур сүзләр генәме болар, әллә чынлап та ат кеше өчен, татар кешесе өчен шулай кадерлеме? Гомумән, язучы иҗатында ат образы ничек бирелә? Нигә автор ат турында шундый зур фикердә тора? Бу тема миңа бик кызыклы тоелды. Марсель Галиевнең “Рух” әсәрендә ат образы бирелгән өлешләрне барлау, әлеге образның сурәтләнешен ачыклау һәм, шулардан чыгып, язучының атларны никадәр яратуын, сагынуын, зурлавын билгеләп карау *максаты* куелды.

Әдәбиятта үз сукмагын һәркем үзенчә эзли һәм үзенчә таба. М. Галиев 2005 елда “Рух” дип аталган затлы китабын бастырып чыгара. Аның титул битендә “Фәлсәфи язмалар, әдәби портретлар” дигән өстәмә аңлатмасы да бар.“ Сүз рухы”, “Милләт рухы”, “Китап рухы”, Җир рухы”, “Дала рухы” кебек бүлекләр белән бергә ат язмышына багышланган аерым бер язма да бар. Әлеге “Ат рухы” дип аталган чәчмә-шигъри әсәре-үзе бер гүзәл симфония. Әдип ат рухы аша татар милләтенең дөньядагы урыны, бай тарихлы үткәне һәм бүгенгесе, гыйбрәтле язмышы хакында уйлана.

Борынгылар “Ир-егетнең йөрәгендә иярләмәгән ат ятар” дигән. Бу әйтем турыдан-туры М. Галиев иҗатына кагыла: әдипнең күңелендә дә иярләнмәгән ат ята. “Кайсы дәвердә сыктап калды соң әле авылның җәяүле, атлы шигърияте?” дигән сорау белән башланып китә әсәр. Һәм автор шушы сорауга җавап эзли. XX гасыр атны рәнҗетү гасыры булды дип, чын күңелдән борчыла. Гасырлар буе кеше белән янәшә килгән атның бетүе, югалуы, онытылуы өчен йөрәге әрни. Ат белән бергә татарларның да хәтере, тарихы, киләчәге юкка чыга дип гасабилана.

Татар әдәбиятында кешенең атка мәхәббәте, гомумән, ат образы киң таралган

Әдәби әсәрләрдә табигатьнең җанлы бер кисәге булган атлар һәрчак кеше белән янәшә тасвирланганнар. Соңгы биш мең ел эчендә кешелекнең җәмгыять үсешендә атның тоткан урынын бәяләп бетергесез. Кулга ияләштерелгән барлык төр йорт хайваннары белән чагыштырганда, аның башкарган роле мөһимрәк.

Ат элек-электән үк татар халкының гомерлек юлдашы, иптәше, туйдыручысы булган. Әлеге йорт хайваннары кешегә һәрвакыт тугры хезмәт иткән. Шуңа күрә дә язучылар ат образына зур урын биргәннәр. Марсель Галиев та үзенең әсәрендә атка мәдхия җырлый, аны күкләргә чөя, бөтен җаны тәне белән аны юксына. “Ат рухы” әсәрендә атка бәйле өлешләрне берничә юнәлешкә бүлеп була. Алар һәрберсе ат образын төрле яклап ачалар. Бөтенесен бергә кушсаң, авторның ат рухына дога кылуын күрербез. Без дә ат рухына дога кыла башлыйбыз.

Ат. Атны сурәтләгәндә автор аның һәр деталенә, һәр хәрәкәтенә, һәр мизгеленә игътибар итә “Юртакларның борын канатлары чатнап киңәйгән. Күзләрендә – кыргый ут. Үз тыныннан кайнарланган һаваны гүя умырып тешләп, ярсу күкрәк белән алга ыргылалар. Тояклар астыннан туфрак кантарлары түгел, ә очкыннар атылып кала сыман,”- дип яза ул. Бу матурлыктан автор хәтта үзе куркып куя, “дәһшәтле матурлык” ди ул аны.

“Гаҗәп бит, бу күркәм-батыр малкай нинди генә генә рәвештә басып тормасын, кайсы ягыннан гына чыгып карама-барыбер ыспай, килешле, антик һәйкәл шикелле искиткеч мөкәммәл, нәзакат иясе, илаһи сәнгатьнең гәүдәләнеше!” “Чапканда-ярсу

матур, үрә басканда-текә матур. Аның хәтта тезләнгән чагы да горур,” - дип тасвирлый атларны Марсель Галиев.

Ат һәм әдәбият. Язучы атлы дастаннар, атлы җырлар, атлы әйтемнәр еллар тузаны астында күмелеп калды ди. Атларның юкка чыгуы кешенең яшәү рәвешенә, сүз сөрешенә нык тәэсир итүен, кешенең атлы телдән машина теленә күчә баруына йөрәге әрни. Чөнки бездә атка гына эндәшә торган сүз байлыгы бар иде ди, аңа ышану, таяну теле.

“Ат белән бергә туган гореф-гадәтләр, аралашу, бәйге, эш-яу коралларын аңлаткан күпме хикмәтле сүзләр иярдән төшеп калды” дигән фикер белән килешми мөмкин түгел. Ә бит җуелган сүзләр аһәңе белән бергә моң китә, тел ярлылана. Халык атларга нинди ягымлы, мәгънәле атамалар биргән: бахбай, малкай, җылкы, чаптар, чабышкы, юрга, тулпар, аргамак, байтал, тай, кырыкмаш тай, алаша, колын, бия, юртак, дөлдел...

Борынгы бабаларыбыз Тын океан ярларынан башлап Карпатка кадәрге җир-суларга, чул-далаларга, тау-урманнарга ат исеме кушып калдырган: Тарбагатай, Алтай, Бабатай, Юрга, Арарат, Алашан, Турыайгыр, Атбара, Акбайтал, Атбасар, Күкайгыр, Атбашы, Атаркан, Атлас, Айгыртау, Колынсары, Бия, Талтай, Акъял, Тояккүл, Кашкадәрья, Бүребайтал, Җегетай, Карабаир, Текәбас, Тайсуган, Биябаш, Нурлат... һәм тагын күпме атамалар... Бу шигъри исемнәр халкыбыз теленнән Җир шары маңгаена мәңгегә уеп калдырылган.

Ат һәм балачак. Тамырлары авыл белән бәйле кешеләрнең Атка үзенчәлекле мөнәсәбәттә торулары аңлашыла. Кайсы авыл малае үз колынын булдыру, аны башкалар белән көтүләү, су коендыру, Сабан туенда беренче килү турында хыялланмый икән? Марсель абый Галиев та авыл малае. Ул ат кадерен, атлы булу горурлыгын, атта йөрү шатлыгын бик яхшы белә.

Элек-электән кешеләргә ат җәнлеген сөю-иркәләү, аны юату, аңа күңеленнне бушату, эч сереңне сөйләү хас булган. Бәләкәйдән үк атның шатланганда кешнәп көлүен, кайгырганда яшь чыгарып елавын, зур күзләрендә чагылган мәгънәле моңны күреп үскән кеше. Бәхетле балачак кичергән, чын ир-егет булып үскән.

Ат һәм ир-ат. Ир-ат... Ат-ир... Безнең телебезгә генә хас нинди бөек мәгънә. Рухи һәм җисми бергәлек. Аерылгысыз ике җан тибеше.

Ат образын ул кешедән аерылгысыз итеп күрә. “Бакый заман кешесе, әле көзге булмаган дәвердә, үзенең йөз-кыяфәтен тәүге тапкыр ат күзендә күргәндер.... Ат күзендә үзеңне күрү, тәүге тапкыр күрү, ир-атның тугач ук ат белән дуслыгын чагылдыра. Ләкин бүгенге ир-атларны ул “иярсез ирләр” дип атый. Ат сүзен алар белән янәшә куймый. Алар атсыз, алар ятим, аларда көч юк.

“Өзәңгегә басып, җилгә каршы бөгелеп, тезгенне тоткан җайдак егетләр үзләре дә ат ялыннан яратылган шикелле; нинди бу бербөтен тәңгәллек!” бу сүзләр ат белән ир һәрвакыт янәшә булырга тиеш дигән фикерне дәлилли.

“Ат рухы” бүлегендә атларның мифологик җан ияләре икәнлекләрен дә күрә алабыз. Алар кешеләр кебек үк уйлый, фикерли белә, хуҗасының кайгысына кайгыра, шатлыгына сөенә. “Күндәм, чыдам, тугры ат-малкай кеше өчен җанын да, тәнен дә, канын да биргән. Ат кешенең сердәше, аркадашы”. Автор төгәл әйтә: “Ат кешенең бәхете дә, тәхете дә”. “Аты шәп хуҗаның атлавы да шәп”.

Ат һәм сүз. Халыкның холык-табигате, тарихы, гореф-гадәте, омтылышы, уй-гаме сүзләргә сыйган. “Ат рухы” әсәрендә дә атлар турында әйтелгән афоризмнар,

мәкальләр, тапкыр сүзләр бик күп очрый. Автор әсәрнең буеннан буена “ияр” сүзен куллана. “Иярсез ирләр”, “атлы дәверләрне иярләгән төрки халык”, “дәверләр ияреннән егылып калган халык” хикмәтле сүзләр иярдән төшеп калды”. Чөнки иярсез ат хуҗасыз була, иярдән егылып төшү хурлык, атны иярли алмау булдыксызлык санала. Әсәрдә “Дөньяны тетрәтеп ат йөрәге тибә”, “Татар ат өстендә туа, ат өстендә үлә”, “Аты шәп хуҗаның атлавы да шәп”, “Таң атканны алдан күрер атка атланган ир-егет”. Ат образының кешелек белән янәшә, бергә баруы аша автор без үзебез ияләштергән, үзебезгә якын китергән җан ияләре өчен җаваплы булуыбызга ишарә ясый. “Ат чыраена кизәнү атаңа кизәнү белән бер саналган”.

Ат һәм хыял. Язучы бик еш кына хыялында атларны күрә, сөйләшә, шатлана, курка. “Әнә бит тау борылышыннан, яшел тугайларны иңләп атлар көтүе килә. Тояклар тупырдавы йөрәкне рәхәт кытыклый. Шул минутта ул “Башын чөеп, күкне тешләп, атлар кешнәвен ишетә, күңелендә ямансу дәрт ургый башлый”. Өметенә канатлар куеп, ул дастаннардан, әкиятләрдән ат образы кайтуга, атка бәйле онытылган сүзләрнең хәтер упкыныннан чыгуына чын күңелдән ышана башлый.

Ат һәм Сабантуй. Сабантуй тавышын ишетә беләсезме сез? Сөлгеләр чытырдап тартыла, көрәшче ирләрнең ухылдап җиргә төшүе, җыр-музыка, чәчәк бәйләме кебек балаларның көр тавышы, алкышлар шарлавыгы һәм тояклар тупырдавы.

Бу көнне “һавада-хәтере уянган җир исе, тиргә баткан тән исе, кытыкланган җил исе” килә.

Сабантуйда атлар чабышы-бәйгенең бөек мизгеле белән тиңләнә. Шул минутта “күңел тула”, “сокланудан яшь килә”, “тын-сулыш юлы рәхәт кысыла”.

Ат һәм тарих. Атлы дәверләр, шанлы дәверләр... “Атлы дәверләрне иярләгән төрки халкымның бөеклегенә, көч-дәрманына, чыдам-гаярьлегенә шаклар катып гаҗиз калам. Атлы ташкын Кояш чыгышы илләреннән башлап Кояш батышы илләренә кадәрге күпме кыйтгаларны тетрәткән. Бер мизгелгә генә үзеңне шул дәвергә куеп кара: акыл көчсез кала, хыял җитми. Уйласаң, исең китәрлек: җил-яңгырларда, кар-бураннарда, тау-кыялар, чүл-далалар, урман-кырлар, елга-күлләр кичеп, меңнәрчә чакрым араны ут-яулар аша үтәр өчен нинди чыдамлык, ихтыяр көче, батырлык кирәк булган. Бу атлы гаскәр диңгезе белән идарә итәр өчен сәрдар-командарлык, бер максатка буйсындыра алу тәвәккәллеге, сүз осталыгы кирәк булган. Дастан-легендаларда гына ул атлар-канатлы, кылычлар-елдырдым, һәр яугир-баһадир. Ә кырыс тормышта бөтенләй башка...”- дип тарихка алып кереп китә автор.

“Дөньяда иң шәп нәселле атлар гарәп аргамаклары,”- дип, дәвам итә Марсель Галиев. Монда без атларның токымнары, аларның әйтеп тә булмый торган кыйммәтле исемнәре белән танышабыз: сиглавн, һадбан, брабансон, першерон, клейдесаль һ.б.

Бүгенге көндә җир йөзендә нәселле атларның төре ике йөз иллегә җитә. Инглиз чаптарлары, ахалтәкә аргамаклары, Орлов чабышкылары, Дон чаптарлары һ.б.

Ат һәм әдәбият. Ат һәм сүз. Ат һәм тарих. Ат һәм ир-ат. Ат һәм балачак. Ат һәм хыял. Ат һәм Сабантуй. Болар барысы да бер бөҗрага тезелә дә, Ат рухына дога булып яңгырый кебек. “Тына бара инде тояк тупырдаулары. Биеккә аша Ат рухы...” дип тәмамлый үзенең догасын язучы. Ат рухы ул безнең язмыш, ул безнең тарих, ул безнең хәтер, ул безнең тел, ул безнең моң.

Автор үзен “дәверләр ияреннән егылып калган халык улы мин” ди. Димәк, дилбегәне кысып тота белмәгәнбез, ат өстендә ышанычлы утырмаганбыз. Табигатьнең гаҗәп җан ияләрендә әдип үз язмышын, халык язмышын күрә.

“Бәйгедә соңлап килгән ат язмышы-ул безнең уртак язмышыбыз”.

“Татар язмышы” н - ат ияреннән туган поэмага тиңли. Ягъни аттан башка татар, татардан башка ат ятим. “Ат елавына кушылып, син дә бер ела” дип эндәшә автор. Атның моңсу күзләрендә-мөлдерәмә тулган яшәү догасы.

Әсәр ахырында “Атлы дәверләргә-салават” дип, үзенең фикерен белдерә.

Һәм бер генә теләктә кала. Югалмасын юргалар, армасын аргамаклар, чалыкмасын чаптарлар, елкылдасын елкылар, айгылдасын айгырлар... Ягъни ат рухы һәрвакыт исән һәм исән булачак.

Ләкин шул ук вакытта атка һәйкәл куярга кирәклеген искәртә. “Бу дөньяда яшәвенә рәхмәтен милләт (сансыз булмаса), атка һәйкәл куеп, үз-үзен санлавын раслый.”

Язучыларның атларны саклап калырга, кайтарырга кирәк дигән фикере бүгенге көндә сәер тоелырга мөмкин. Әмма берничә сәгать эчендә бер кыйтгадан икенчесенә барып җитә торган реактив самолетларның да, машина-тракторларның да егәрлеге әле бүген дә ат көче белән исәпләнүен онытмыйк.

Гомумән, Марсель Галиевның беркемне дә кабатламый торган иҗат йөзе бар. Проза телен дә җырлатып торырлык иткән “Халык язучысы” дигән мактаулы исем, халкыбызның иң югары бүләге - Тукай премиясенә лаек булган танылган шагыйрь, язучы-прозаик, үткен телле публицист, тәнкыйтьче, драматург ат образын сурәтләгәндә төсләр уенына, күзгә бәрелеп торган бизәкләргә өстенлек бирә, шулар аша кеше кичерешләре дәрьясына юл ала, сиздермичә генә фәлсәфи фикер дөньясына алып керә.

Күзәтүләргә таянып, Марсель Галиев “Рух” әсәрендә ат образын бөтен яклап ача дисәк тә хата булмас, шулардан чыгып, язучының атларны никадәр яратуын, сагынуын, зурлавын билгеләп карадык. М. Галиевның атлар яратуы аның авыл егете булуында, атларны зурлавы аның җаны -тәне белән татар кешесе булуында, атларны юксынуы аның тарихны тирән аңлавында. Башкача булуы мөмкин дә түгелдер.

Эшемне М. Галиев сүзләре белән тәмамлыйсы килә: “Рух - милләтнең фидаи җаны, максатлы омтылышы, үзеннән югарырак сикерә алу мөмкинлеге. Рухи кодрәт ул-бөгелгәндә бөгелмәү, егылганда егылмау, чигенгәндә чигенмичә яшәү тантанасы”.

## Шигъърият һәм моң

*(Марсель Галиевның “Кайту” китабына күзәтү)*

*Илһамова Эльзира, 10 нчы сыйныф,*
*Азнакай шәһәре 7нче урта гомуми белем мәктәбе*

“Марсель рәссам булмаганга язучы булган, язучы булмаса, артист булыр иде. Ул югары сәнгать кешесе”,– дип әйткән Туфан абый Миңнуллин безнең якташыбыз, язучы, шагыйрь, драматург һәм публицист Марсель абый Галиев турында.

Матбугатта Марсель Галиевның беренче шигырьләре үткән гасырның җитмешенче елларында күренә башлый, бер төркем шигъри әсәрләре 1970 нче елда яшь шагыйрьләрнең күмәк җыентыгына («Беренче карлыгачлар») кертелә,

ә 1979 нчы елда «Еллар чалымы» исеме белән шигырьләре тупланган мөстәкыйль җыентыгы дөнья күрә. Бу җыентык әдәби тәнкыйть һәм укучылар тарафыннан уңай бәяләнә. 1984 нче елда “Ак рәсем”, 1990 нчы елда “Шүрәле һәм җил”, 1992 нче елда “Су буеннан әнкәй кайтып килә”, 1998 нче елда “Сайланма әсәрләр, 1том”, 2004 нче елда “Гомер бизмәне”, 2008 нче елда “Учымда-тургай шәүләсе” исемендә шигырьләр җыентыгы басыла.

М. Галиевның җыр текстлары иҗат итү өлкәсендә дә үзенчәлекле уңышлары бар. Шагыйрьнең төрле елларда иҗат иткән 98 җыры кергән “Кайту” дигән китабы 2000 нче елда Татарстан газета һәм журналлар нәшриятында басылган. Бу китапка кергән җырлар төрле композиторлар белән төрле елларда язылган. Язмыш Марсель абый Галиевны Рөстәм Яхин, Сара Садыйкова кебек олуг композиторлар белән дә очраштырган. Сәләтле яшь композиторлар да аның шигырьләренә заман рухындагы көйләр язганнар. Шагыйрьнең «Су буеннан әнкәй кайтып килә», «Көзге моң», «Кайту» кебек җырлары, халыкның күңел моңына әверелеп, бөтен татар галәменә таралган. Аларны бүгенге көндә дә Хельсинки, Сан-Франциско, Истанбул, Токиода яшәүче милләттәшләребез яратып җырлый һәм елап тыңлый икән-шагыйрь өчен бәхет шул инде!

“Кайту” китабына кергән җырларны төрле темаларга бүлеп карыйк әле.

- *Әниләр темасы:* “Су буеннан әнкәй кайтып килә”, “Ак шәл бәйли әнием”;
- *Әтиләр темасы:* “Кичке шәфәкъ”;
- *Мәхәббәт темасы:* “Кил минем дөньяма”,”Елмай син”, “Көнләшмә”, “Тимә төнбоекка”, “Нинди моң бар төнге күзләреңдә”, “Ашыгамын сиңа”;
- *Язмыш темасы:* “Кайту”,”Айлы сагыш”, “Миләшле көз”, “Төн исе”, ”Көзге моң”, “Син каршыла”, “Ак көймәләр”, “Син дә кайт мәхәббәт ярына”, “Соңгы теләк”;
- *Туган як темасы:* ”Урсай җыры”, “Тымытык җыры”, “Актүбә чишмәләре”, “Чатыр тау”, ”Туган як тургае”;
- *Яшьлек темасы:* “Күрше кызы”, “Миләүшә”;
- *Тарих темасы:* “Казанымның җиде капкасы”, “Без туганбыз”.

“Шигырь ул-күңел кылларыннан Раббы сулышына көйләнеп үрелгән аһәңле читлек. Шул читлеккә канатка-канат килгән сүзләр кәрваны савылып керә дә... тынга-тын, ымга-ым, моңга-моң килеп, куначага тезелә”, - дип язган Марсель абый Галиев үзенең “Учымда-тургай шәүләсе” дигән китабында. [2:10]. Шагыйрь бикләгән читлек ачкычын табып, күңелләрегезгә үтеп керү өчен, мин чыгышымны Марсель абыйның “Кайту” җыры белән төгәллим.

## “Әй туган җир”. Марсель Галиев иҗатында туган як темасы

*Исмагилова Карина, 8 нче сыйныф Казан шәһәре,*
*«Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган*
*85 нче урта гомуми белем мәктәбе”*
*Житәкче: Зарипова Дания Фирдус кызы,*
*татар теле һәм әдәбиятыукытучысы*

Республикабызның кайсы гына төбәгендә яшәсәк тә, туган төбәк, аның гүзәл табигате безне үзенә җәлеп итеп тора. Әйе, һәр кешегә үзенең туган җире газиз. Нинди генә матур якларга барсаң да, бераз торуга, үзәкне өзеп кайтасы килә. Туган якка аяк басуга, күңелне рәхәт хис биләп ала. Туган ил-ул син яшәгән җир, авыл,

төбәк , син яраткан табигать, син хөрмәт иткән кешеләр. Торган саен син туган якның гүзәллеген ныграк аңлыйсың, байлыкларын күз алдына ачыграк китерәсең. Бу сүзләр мәгънәсенә шулай ук әти, әни, әби, бабай, безнең якын кешеләребез, гомумән, барлык тереклек дөньясы керә. Туган якның бай тарихы һәм мәдәнияте, табигате һәм көнкүреше - болар барысы да кече яшьтән үк балалар тормышының бер кисәгенә әверелә. Туган җиргә, туган телгә мәхәббәт, кешенең үз-үзен аңлавы, кичерешләр хәрәкәтен ачарга ярдәм иткән табигать күренешләре, тормышны киная белән, үзгәртеп сурәтләү, акыл һәм физик хезмәтләр белән рухлану, балачакны сагыну, мәхәббәт сагышлары – барысы газиз илһам чыганаклары. Тулаем алганда, чынбарлыкны, рухи дөньяны үзләренчә күрү сәләтенә ия, бай фикерле, гүзәллекне тоя, сәяси хәрәкәтләрне аңлый торган сәләтле сүз осталары иҗат итә. Шигърият, бу төргә хас даими, тотрыклы билгеләрен, гасырлар сынавын үткән жанр өлгеләрен, сурәтләү чараларын саклаган хәлдә, туктаусыз хәрәкәттә, үсештә, үзгәрештә яши. Халык, туган тел язмышы, чор сулышы, кешенең мәхәббәт кичерешләре, эчке дөньясы поэзияне алга әйдәүче юнәлешләр булып калалар. Һәр язучының, һәр шагыйрьнең әсәрендә туган җире, якты образ булып, иҗатының буеннан буена сузылып бара. Язучыларыбыз иҗатында туган якның матурлыгын, кешеләренең күркәм сыйфатларын, гореф-гадәтләрен, табигатенең байлыгын-муллыгын күрсәтеп язган шигырьләр һәм чәчмә әсәрләр күп.

Туган як, туган авыл, туган ил, туган җир кешелек дөньясы өчен ни дәрәҗәдә мөһим? Туып үскән җиренә кешенең мөнәсәбәте нинди гамәлләрдә, хис кичерешләрдә чагыла? Язучылар иҗатында туган җир темасы нинди урын алып тора?

Әлеге сорауга җавапны мин шигърияткә, туган җиргә гашыйк татар шагыйре, язучы Марсель Галиев иҗатында эзләдем. Фәнни эшебезнең тикшерену объекты итеп туган җир темасының бирелеше, предметы итеп, Марсель Галиевның туган якка багышланган шигырьләрен алдым.

Сайлап алынган эзләнү эшебезнең бүгенге көндә әһәмияте: эзләнү эше барышында туган тел һәм әдәбият дәресләрендә, дәресләрдән тыш чараларда укучыларга патриотик тәрбия бирүдә файдалануга ирешү. Туган якны ярату хисе кеше үскән саен, Ватан белән горурлану хисенә әверелә бара. Әлеге укучыны чын патриот итеп тәрбияләү өчен җәмгыять, мәгариф системасы һәм гаилә шушы уңдырышлы туфракка тәрбия орлыкларын вакытында салырга тиеш. Бу бик әһәмиятле, чөнки укучыларыбызның бүген алган тәрбиясе-иртәгә дәүләтебезнең киләчәге.

Фәнни эшебезнең төп максаты булып, Марсель Галиев иҗатында туган як, туган җир темасының чагылышын (бирелешен) күзәтү. Куелган максатка ирешү өчен, түбәндәге бурычлар билгеләнде:

1. Марсель Галиевның тормышы, туган якка багышлап язылган шигырьләре белән танышу;

2. Әдип иҗатында туган як темасының чагылышын күзәтү һәм ачыклау;

3. Туган як табигатенә күзәтүчәнлек, аның гүзәллегенә соклану, җаваплылык, мәхәббәт хисләре тәрбияләү.

Марсель Галиев 1946 елның 8 октябрь көнендә Азнакай районы Балтач авылында туган. Үз районындагы татар урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, берникадәр вакыт төзү–монтаж идарәсендә эшли. 1969 елда Марсель Галиев Казан дәүләт

университетының журналистика бүлегенә укырга керә; 1974 елдан 1983 елга кадәр Татарстан Язучылар берләшмәсендә әдәби хезмәткәр һәм «Казан утлары» журналы редакциясендә проза бүлеге редакторы булып эшли.

Марсель Галиев шигърият һәм проза жанрында иҗат итә. Матбугатта аның әсәрләре 70нче еллар башында күренә башлый. 1979 елда «Еллар чалымы» исеме белән мөстәкыйль шигырьләр җыентыгы, ә 1980 елда ике повестен эченә алган «Ул чакта» исемле проза китабы дөнья күрә. 2011 нче елда, күпъеллык иҗат эшчәнлегенең нәтиҗәсе булган , 6 томнан торган “Әсәрләр” тупланмасы басылып чыга.Әдипнең аерым әсәрләре рус, поляк, украин, үзбәк, казах, осетин, чуваш телләренә тәрҗемә ителгән.

Марсель Галиев-татар шагыйре, язучы, Г. Тукай исемендәге Татарстан дәүләт премиясе лауреаты. Татарстанның халык язучысы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

Фәлсәфи рухтагы әсәрләрендә үзенә генә хас язу стиле белән сокландырган Марсель Галиев ике гасыр чигендәге татар интеллектуаль әдәбиятының күренекле вәкиле булып тора. Катлаулы эчтәлекле, яңача яңгырашлы шигырьләре һәм тирән психологизм белән характерланган романтик кичерешләр сурәтләнгән чәчмә әсәрләре янәшәсендә юмор-сатира үрнәкләре, әдәби тәрҗемәләре авторның киңкырлы эзләнүләрен чагылдыра. Әдипнең күңел лирикасы үрнәкләрендә хәтер мотивы туган як темасы һәм шушы тема яктылыгында ачылган туган җир, авыл, нигез, әти-әни образлары белән үрелеп бара. Кая гына барса да, лирик геройның күңелен биләгән җирсү хисе, вакыт агышында туган як образының да үзгәрә баруын аңлау лирик геройның балачак һәм яшьлек сафлыгын сагынуы белән тыгыз бәйләнештә укыла

Марсель Галиев әсәрләре тема һәм жанр ягыннан бик бай. Аның шигъри тәлгәшләрендә, проза әсәрләрендә дөнья матурлыгы, якыннарына мәхәббәт, динебезгә һәм туган ягыбызга, тарихыбызга, телебезгә чиксез хөрмәт чагыла. Аның лирикасында туган як темасы әйдәп баручы темаларның берсе булып тора. Туган якны сагыну, аның матурлыгына соклану, аның белән горурлану Марсель Галиев әсәрләрендә кызыл җеп булып сузылган. Туган як-ул балачакның һәрбер мизгелен үзендә саклый торган гаҗәеп кадерле урын. Язучы моны безгә үзенең әсәрләре аша җиткерә.

Марсель Галиевнең **„Туган як”** шигыре матур Азнакай төбәгенә багышланган. Лирик герой өчен туган як яме тормыштагы һәрнәрсәдән өстен. Аның туып- үскән ягында гына „йолдызлар тәлгәш- тәлгәш сибелә”, „таулары ап- ак яллы болытларны тышаулый”, „абагалары чәчәк ата”, „суларында кояш йөзә”,. „күкеләре меңгә кадәр саный” . Гипербола-арттыру , сынландыру алымнары аша лирик геройның соклану хисе үстерелә. Шигырьнең беренче строфасы болай яңгырый:

Шундый як ул, карагыз сез
минем туган җиремә,
йолдызлар хәтта кызыгып
тәлгәш- тәлгәш сибелә.

Автор соңгы строфада үзенең яшәгән урынын сер итеп кенә укучыларга җиткерә.

Ышанмыйча сез сорарсыз:
Чынлап, андый җир кайда?
Сер итеп әйтәм алайса:

Аз-на-кай-да!...

Шагыйрь шулкадәр җылы итеп, сокланып үз туган ягы турында гына яза ала.

**„Танышу нидән башлана?”** шигырендә туган авылын мактый. Аның кешеләре дә гадирак, суы да тәмлерәк, таңы да матуррак, һавасы да сафрак.

Ни генә юк авылымда
тәмле чишмә сулары,
кәҗә сукмагыннан менсәң
җил сызгыра таулары.

Аның бу шигырен укыганда синең алдыңда чылтырап аккан чишмәләре, биек таулары белән бөтен бер дөнья ачыла.

**„Шәһәрдә нәүмиз хәтер”** шигыренә игътибар итсәк, бу әсәрендә шагыйребез үзенең туган авылын, анда үткән бала һәм үсмер чагын сагынуын гап- гади генә, әмма бик үтемле итеп тасвирлый. Бу шигырьне без туган нигезен сагынуның югары дәрәҗәдәге үрнәге, дип әйтә алабыз. Аны, әлбәттә, хәтерендә калган авыл чишмәсе төбендәге чуерташлар , тегермән, тәмле алмалар сагындыра. Ул уендашларын, сугыш кичкән агайларны сагына. Аның хәтерендә ат җигәргә өйрәнүләр, кунак кызлары, ул чорның ярлылыгы һәм бай күңеле. „Туган ягын сурәтләгәндә ул хыялый бер үсмер, ялларын тузгытып далада чапкан кырыкмыш тай, беренче саф мәхәббәте кабынган гашыйк, туган җиренең газиз баласы сыман!

**„Булсин иде”** шигырендә ул авылын ни өчен сагынып кайтуын антитеза сурәтләү чарасы ярдәмендә аңлата. „Зур шәһәрдә яшел болыннар, киң кырлар, көтүдән юашланып кайткан сыерлар, балыклы инешләр булса, мин авылны сагынып кайтмас идем”-, дип яза. М.Галиевның лирик герое-шәһәрләшеп килүче кичәге авыл кешесе.Ул каршылыклы хисләр, уйлар иясе, авылны оныта алмау-аның үзенчәлекле сыйфаты. Лирик герой шәһәрдә яши, ләкин авылын, туганнарын, урманнар, чишмәләр, тауларны сагынып яши. Һәм шул ук минутта ул авылга бөтенләй кайтмаячак инде.

**„Китү”** һәм **„Кайту”** шигырьләрендә автор геройның катлаулы рухи халәтен, каршылыклы күңел дөньясын бик тәэсирле итеп сурәтли. Туган җирдән киткәндә аның күңелендәге аерылу, үкенеч, чарасызлык хисләре, аңа кайткан вакытта рәхәтлек, шатлык, канәгатьләнү хисләре белән алышына.

**„Актүбә чишмәләре”** шигырендә сагышлы юлларның кабатлануы шигырьнең тәэсирлелеген арттыра, сагыну хисен тагын да көчәйтә. Шагыйрь туган ягына ашкына, аңа мәдхия җырлый.

**„Әй туган җир”** риторик эндәшүенең төрле урыннарда кабатланып килүе шигырьнең строфаларын үзара беркетә, үзәк фикерне эзлекле бирүгә ярдәм итә, авторыбызның үз иленең чын патриоты икәнен ассызыклый.

Әй туган җир,
Җилләреңә
Серләрем сөйлим әле...
Әй туган җир,
тауларыңа
таңнарда меним әле...
Әй туган җир,
Тугайларда
адашып калыйм әле.

**„Туган як тургае”** шигырендә ул туып- үскән җирендә генә бәхет тәмен белгәнен яза, аңа язу өчен илһамны туган ягы бирә. Туып- үскән нигез кеше күңеленә моң сала, аны канатлы, илаһи итә, яшәүгә көч өсти, онытылмас моң булып озатып йөри. Анда аны газиз әткәе белән әнкәе көтә.

Бәхет тәмен беләм
туган җирдә генә,
иген кырларына күмеләм.
Монда – гомер юлым,
монда – туган моңым,
тургай булып җырлый күңелем.

Бу нәфис яңгыраучы юлларда горурлану белән баетылган шатлык-сөенеч тасвирлана.

**„Ераклыклар җиле”** шигыренә игътибар итек:

Туган якның бүресе дә якын
бөкресе дә гарип тоелмыйдыр,
Җыры тынмас салкын чишмәләрнең
Суын эчеп кенә туелмыйдыр.

Шагыйрь туган ягын җаны-тәне белән яратмаса, мондый юлларны яза алыр идеме?

М.Галиев үз шигырьләрендә балачактан күңелендә калган хатирәләрен яңартып, инде олыгайгач, уйландырган уйларын да язган. Аның әсәрләренә авторның йөрәге аша үтеп, шигырь юлларына әверелгән кичерешләр дәрьясы, уйланулар сыйган.Аның әсәрләре аша һәркем туган якның ниндидер серле тарту көчен, сихри романтикасын тоя, шул хиснең чынлыгына, кеше өчен кадерле булуына ышана. Һәр иҗат кешесе үзенең туган җире, туган нигезе, суын эчеп үскән чишмәләренә мәдхия җырламый калмый. Марсель Галиевкә да хас бу күренеш. Ул үзенең иҗаты аша безне туган телебезне, туган туфрагыбызны, үз нәселебезне, халкыбызның мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, күркәм йолаларын, тарихын хөрмәт итәргә, яратырга һәм беркайчан да онытмаска чакыра.

Гомумән алганда, әдипнең шигъриятен тикшергәннән соң шуны әйтергә мөмкин: Марсель Галиевның иҗатында туган як образы зур урын алып тора. Ватанына булган мәхәббәтен иҗат җимешләре аша укучыларына җиткерә ала. Үзенең иҗаты белән туган илне яратырга, аны сакларга, күңел белән тоемлый белергә өнди. Чыннан да, заманалар ничек генә үзгәрмәсен, ил тарихында нинди генә вакыйгалар булмасын, туган илне ярату тойгысы, аңа файда китерү теләге һич кенә кимергә тиеш түгел.

Күргәнебезчә, әдәби туган якны өйрәнү зур әһәмияткә ия. Туган якны өйрәнү укучыларның әдәбият өлкәсендә, төрле фәннәрдән алган белемнәрен баетып, тирәнәйтеп кенә калмый, аларга бу белемнәрне җәмгыятьтә файдалы эшләрдә кулланырга да юнәлеш бирә.Туган җир, нигез, хәтер, нәсел-тамыр, туган тел төшенчәләре Марсель Галиев иҗатын иңләп бара.

**БиС технологиясе элементларын кулланып, сыйныфтан тыш уку дәресе**
**“Туган як тәхете - Чатыр тау”**

*Кашапова Фирүзә Фәнил кызы, «Азнакай шәһәре*
*7 нче урта гомуми белем мәктәбе»нең*
*туган тел (татар теле) һәм әдәбияты укытучысы*

**Максат:**

1.Бәйләнешле сөйләм аша логик фикерләү сәләтен, иҗадилыкны үстерү өчен шартлар тудыру. Укучыларның эшләү тизлеген, логик һәм критик фикер йөртүләрен, мәгълүмати компетентлыгын, сүз байлыкларын үстерү.

2. Туган ягыбыз Азнакай, аның горурлыгы булган мәгърур Чатыр тавыбызны ярату хисләрен-патриотик тәрбия бирүне дәвам итү, гражданлык позициясен ныгыту, укучы шәхесен милли һәм рухи кыйммәтләрнең асылына төшендерү.

3.Туган якның танылган шәхесләрен барлау, иҗатларына нигезләнеп, белем-күнекмәләр формалаштыру, алар турында күбрәк белергә омтылыш уяту;

Дәрестә уку материалының укучылар тарафыннан үзләштерелү дәрәҗәсен норматив таләплрдән чыгып 63%ка җиткерү.

**Җиһазлау:** компьютер, проектор, туган ягыбыз Азнакай һәм аның әдәбият-сәнгать әһелләренә багышланган стенд “Азнакаем-илһам чишмәсе”, пазллар, презентация, карточкалар.

Илдус Гыйләҗев, Резедә Гыйләҗева “Азнакаем, Азнакай” җыентыгы.

“Тел-халыкның күңел кыңгыравы” газетасы.

Буклет “Чатыр таудан илһам алып...”

Трио "Азнакай гүзәлләре", "Шушы яктан", Квартет төркеме "Туган ягым, Азнакаем" аудиоязмалары.

**Дәрес барышы**

**1 нче этап. Мотивлаштыру - ориентлашу**

**Максат:** *дәрестә укучылар белән уңай психологик халәт тудыру.*

**-** Хәерле көн, хөрмәтле кунаклар , яраткан укучыларым! Безнең бүгенге дәресебез "Туган ягым, Азнакаем" җырыннан өзек белән_башланып китте һәм ул тиккә генә түгел!

Татарстаныбызның кояш чыгышы тарафында, чал Уралның соңгы дулкыннары кучкар-кучкар таулар хасил иткән манзаралы ягы бар. Экранга игътибар итегез әле һәм уйлагыз:

Аз да түгел, күп тә түгел,
90 ел аңа бары.
Я, әйтегез, нинди як бу
Гүзәл

**Бергә** : АЗНАКАЙ ягы.

Һәр авазы табигый чиратлашып килгән А-з-н-а-к-а-й дигән тылсымлы аһәңгә тугайлар киңлеге дә, тутлы каенлыкларның тымызык ак төннәре дә, бөгелә-бөгелә аккан елгалары да, Чатыр тавы да, шушында гомер сөргән кешеләрнең тулган ай кебек карашлары да сыйган.

Әйе, кешене гомер буе туган ягы, газиз Ватаны озата бара, укучыларым. Дәресебездә дә шул турыда сүз барыр.

Без бүген төркемнәргә бүленеп эшләрбез.

**Укытучы.** Сезнең өстәлләрегездә тулы бер рәсемнең аерым кисәкләре - пазллар ята. Пазл ул - инглиз теленнән алынган сүз, төрле формадагы кечкенә рәсемнәрдән тулы бер картина төзү. Пазллардан шулай ук төрле мультимедиа рәсемнәр ясап була. Һәр төркемгә, пазлларны җыеп, килеп чыккан рәсем турында мәгълүмат бирергә кирәк. *(Җаваплар тыңлана:* Азнакай, Чатыр тау, Туган тел ("Туган телләрне саклау, үстерү һәм халыклар бердәмлеге елы" эмблемасы).

**Укытучы.** Ә ни өчен нәкъ шушы рәсемнәр икән? (*Җаваплар тыңлана*: туган төбәгебез Азнакай районына 90 ел, Азнакаем горурлыгы – мәгърур Чатыр тавы, 2021 нче ел("Туган телләрне саклау, үстерү һәм халыклар бердәмлеге елы").

**2 нче этап. Уку мәсьәләсен билгеләү, дәрескә бергәләп максат кую**

- Укучылар, сез терәк сүзләрне таптыгыз, димәк сыйныфтан тыш уку дәресебездә нәрсәләр турында сөйләшәчәкбез? Уку максатын үзебез билгелик әле *(җаваплар тыңлана)*

- Әйе, дәресебез туган ягыбыз Азнакайга, аның иң күренекле урыны- җөмһүриятебезенең иң биек ноктасының берсе Чатыр тавыбызга багышланыр. Шулай ук туган якның танылган шәхесләре иҗатына нигезләнеп, белемнәрне арттырырбыз, алар турында күбрәк белергә тырышырбыз.

Һәр төркемнең исеме пазллардан төзелгән рәсемдәгечә булачак. Димәк, **1 нче төркем –** "Азнакай", **2 нче төркем – "**Чатыр тау", **3 нче төркем –** "Туган тел".

**3 нче этап. Белемнәрне актуальләштерү. Өй эшен тыңлау Үзбәя.**

Өй эшенә якташ язучы-шагыйрьләребезнең туган төбәгебезгә багышланган шигырьләрен табарга, аларны сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә бирелгән иде. Һәр төркемнән бер укучыны тыңлап узарга тәкъдим итәм. Төркемнәрдә, үзара киңәшләшеп, кем икәнен билгеләгез (*шигырьләр тыңлана)*

**4 нче этап. Укуның максатын адымлап чишү.**
**Укучыларның сөйләмен үстерү өстендә эшләү**

Һәр төркемгә 2021 нче ел-"Туган телләрне саклау, үстерү һәм халыклар бердәмлеге елы" уңаеннан үзем чыгарган *"Тел-халыкның күңел кыңгыравы" газетасын* таратам. Бу газетада телебезнең матурлыгы һәм кыйммәте, төбәгебезнең юбиляр шәхесләре турында эчтәлекле язмалар, укучылар иҗаты һ.б.урын алган. Сезгә танышып чыгарга 1-2 минут вакыт бирелә.

4-5 нче битләргә игътибарыгызны юнәлтәсем килә. Кемнәргә багышлана бу битләр? (*җаваплар тыңлана:* төбәгебезнең генә түгел, республикабызның танылган шагыйрьләре **Марсель Галиев**, **Нур Әхмәдиев, Илдус Гыйләҗевка)**

Әйе, укучылар, бу битләрдә аларның тормыш юлы, иҗаты турында тулы мәгълүмат бирелә. Шулай ук туган телебезгә, туган ягыбызга багышланган шигырьләре басылган. Кызганыч, Илдус Гыйләҗев һәм Нур Әхмәдиев, безнең арада юк инде.

5 нче биттә Илдус Гыйләҗевның Марсель Галиев һәм Нур Әхмәдиевкә багышланган "ӨЧ ТЕРӘҮ" шигырен укырбыз хәзер *(ТЕРӘҮ сүзе аңлатыла. Аумаслык, ишелмәслек итеп сөяү. Подпорка)*. Шигырьне укыганда, исеме турында уйланыгыз әле, укучылар: ни өчен "Өч терәү"?

Бер үк елда туган малайлар без,
Бер үк яктан, бер үк төбәктән.
Гамәлләребез дә шундый охшаш-
Хис дулкыны кайный йөрәктә.

Чатыртауга карап өч ягыннан,
Өч хыялый өскә үрләдек;
Шуңа микән, җиңел яуландылар
Яшәешнең башка үрләре.

Хис кимесә, имеш, куәт кайта,
Өч каләмне тауга сөядек.
Туган якны Чатыр тавы белән
Горурланып һәрчак сөйләдек.

Өч терәүле җисем аумый, диләр.
Ул каләмнәр әле торамы?
Тау ишелер аның берсенә дә

Кагылмагыз... миннән сорамый... *(укучыларның җаваплары тыңлана)*

Без бу 3 шагыйрьне "Чатыртау мәҗнүннәре" дибез.

Өстәп шуны да әйтәсем килә: туган ягыбыз Азнакайга 90 ел булса, бу шәхесләребез дә – юбилярлар. Аларга 75 әр яшь.

Чатыртауны "үзләштерде"
Нур Әхмәди, Ирек Бәдри.
Имештер лә тауны тери
Илдус Гыйлаж, Марсель Гали.

Бүгенге дәрестә дә аларның шигъри хәзинәсендә булган Чатыр тавыбызга, Азнакаебызга багышланган шигырьләренә тукталырбыз. Шигырьләрне укыганчы, экранга күз салыйк!

**5 нче этап. Яңа теманы кабул итүгә әзерлек**

Анда терәк сүзләр бирелә:

**1. Тәхет**
**2. Аргамак**
**3. Тугай**
**4. Гашыйк**
**5-6. Күз сирпү**
**7. Офык**
**8. Байбак**
**9. Оҗмах**
**10. Тургай**

- Балалар, эчтән генә укып чыгыгыз әле, бу сүзләр арасында аңлашылмаган сүзләр бармы? *(булса, аңлатыла!)*

**1. Тәхет -** патша утыра торган, зиннәтләп бизәлгән урын. **Трон.**
**2. Аргамак –** чабыш аты. **Скакун, скаковая лошадь.**
**3. Тугай -** елга ташыганда, су баса торган болын. **Пойма реки**.
**4. Гашыйк –** яратучы. **Влюблённый.**
**5-6. Күз сирпү -** җиңелчә кагу, селкү - җилпү. **Метнуть взгляд**
**7. Офык - горизонт**
**8. Байбак –** кимерүче дала җәнлеге. **Сурок.**
**9. Оҗмах – рай.**
**10. Тургай - жаворонок.**

Хәзер сез 45 секунд эчендә бу сүзләрне укып хәтердә калдырырга тиеш буласыз. Аннары шул тәртиптә 1 минут эчендә язабыз.

- Вакыт бетте. Эшләребезне алмаштырабыз, тикшерәбез.

- Кемнәрнең 7 һәм аннан күбрәк сүзләр дөрес, басыгыз әле **(***Әгәр укучы 7-8 сүз язса, матрицага + куябыз )*

**( БиС технологиясе буенча, б**алаларга истә калдыру өчен, сүз санына карап, вакыт бирелә.

7 сүз – 30 секунд
**10 сүз – 45** секунд
12 сүз – 1 мин.
14 сүз – 1 мин 15 секунд
16 сүз – 1мин 50 секунд
18 сүз – 2 мин 15 секунд

Шуннан соң, терәк сүзләр ябыла. Укучылар истә калдырганча дәфтәрләренә язалар. Вакыт чыккач, укучылар дәфтәрләрен бер – берсе белән алмашалар һәм

сүзләрне саныйлар.( ручка кулда булса,  ялгыш тамгасы алалар.) Укытучы нәтиҗәне матрица таблицасына язып бара).
*( Тактада алдан ук әзерләнгән Матрица таблицасы. Җавап бирүчеләргә  матрицага + куябыз .  Тактада уң якта бонуслар бирелгән: “****5” – 8-10 б.  “4” –  6-8 б. “3” – 4-5 б.)***

| A | | B | | C | |
|---|---|---|---|---|---|
| A1 | A2 | B1 | B2 | C1 | C2 |
| A3 | A4 | B3 | B4 | C3 | C4 |
| A5 | A6 | B5 | B6 | C5 | C6 |

**6 нчы этап. Текстлар белән практик эш. Теманы үзләштерү.**

- Терәк сүзләрне истә калдырдык. Шигырьләргә күчәбез. Сезгә эшне җиңеләйтеп, бу шигырьләр тупланган менә шундый буклетлар эшләдем *(буклетларны күрсәтү).* Хәзер мин сезгә аларны таратам. Һәр төркем слайдта күрсәтелгән шигырьләрне укырга әзерләнә, андагы төп фикерне билгели. Калган төркем укучылары буклеттагы шигырьләрне  игътибар белән карап бара, чөнки алдагы биремне үтәү өчен 3 шигырьнең дә эчтәлеген белергә кирәк.

**1 нче төркем** “Азнакай” -  Нур Әхмәдиев “АЗНАКАЕМ – АК БИШЕГЕМ”
**2 нче төркем “**Чатыр тау” -  Марсель  Галиев “ЧАТЫР ТАУ”
**3 нче төркем** “Туган тел” -  Илдус Гыйләҗев “ЧАТЫРТАУГА МЕНСӘМ”

**Нур Әхмәдиев.  “АЗНАКАЕМ – АК БИШЕГЕМ”**

Чатыр тауга менсәм, серләремне
Сөйләр идем ялгыз каенга.
Сөйгәнемнең туй күлмәге төсле
Ап-ак минем Азнакаем да.
Азнакаем – ак калам,

Җиреңнән җылы алам.
Мин бит синең кырларыңнан
Нефть чыгарган балаң.
Мин бит синең гашыйк балаң,
Бәхетемне синдә табам.

Чагыла да утлар күзләреңдә
Нуры   арта тулган айның да.
Яшьлегебез, якты һәйкәл булып,
Җырга күчте Азнакаемда.

Ятимләнеп калам, Азнакайдан
Азга гына киткән саен да.
Җаннарымның әллә бер яртысы
Кала микән Азнакаемда?

*(1 нче төркемнең фикерләре тыңлана)*

**Марсель  Галиев. ЧАТЫР ТАУ**

Тургай булып,
Тургай булып оча күңел
Менсәң биек тауларга.
Йолдызлар да,
Йолдызлар да күзен кыса
Без яраткан ярларга.
Синдәдер хыялы күпләрнең,
Туган як тәхете-Чатыр тау,

Син безне биеккә күтәрдең,
Туган як бәхете-Чатыр тау.
Тауларның да,
Тауларның да маңгаена
Язылады, язылады язмышлар.
Без ялгышсак,
Без ялгышсак,тауларга да
Кагыладыр ялгышлар.

Аргамаклар,
Аргамаклар таудан чаба,
Тугайларда,тугайларда - томаннар.
Бу дөньяны,бу дөньяны без шушылай
Яратырга туганнар. *(2 нче төркемнең фикерләре тыңлана)*

**Илдус Гыйләҗев. ЧАТЫРТАУГА МЕНСӘМ**

Чатыртауга менеп күз сирпесәм,
Офыкларым йөз кат киңәйде.
Гомер буе йөртәм күңелемдә
Шул ноктадан карап күргәнне.
Чатыртауга менеп бер җырласам,
Ак каеннар калды шаулашып.
Киталмадым ташлап мин аларны,
Яшәгәнгә хисләр аңлашып.
Чатыртауга менеп бер сызгырсам,
Байбаклары җавап кайтарды.
Чит җирләрнең оҗмах, җәннәтенә
Алыштырмам туган якларны!

*(3 нче төркемнең фикерләре тыңлана.)*

**Укытучы.** Нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә: чыннан да,гүзәл Азнакаебыз, изге Чатыр тавыбыз шагыйрьләрне йөрәкләргә үтәрлек юллар язарга илһамландырган, шушы якларда туып-үскән шәхесләрне кулына каләм алырга мәҗбүр иткән.

Менә шундый ул безнең төбәкнең тәхете-Чатыр тау!

Экранга игътибар итегез әле: Татарстан Республикасының халык язучысы, драматург, күренекле җәмәгать эшлеклесе Рабит Батулла да әсәрләнгән аның сыртына менгәч. "Чыннан да, Азнакайның Чатыр тау башыннан дөнья башкача күренә икән. Тау башында сулыш та, офык та киңәя", - дип бәян итә ул тәэсирләрен. Югыйсә, кайда гына булмаган да, тауларның ниндиләренә генә күтәрелмәгән әдип!

**7 нче этап. Теманы үзләштерү дәрәҗәсен беренчел тикшерү**

Укучылар, ә хәзер сезнең белән **"Кем игътибарлырак?"** дигән уен-ярыш оештырабыз. Сезгә тексттан **терәк сүзләр кергән җөмләләрне табарга** кирәк була. 5+30 системасы белән эшләрбез. Кемнәр тапты, кул күтәрегез.

**(*5+30 системасы – биремне үтәү нормативы***

Вакытны төгәл исәпләмәү аның сарыф ителүенә китерә. Ә менә **5+30 системасы** укучыларга вакытны чамаларга өйрәтә. Монда тизлек тә бар, балл аласы да килә, үзара ярыш, конкурентлык сәләте дә үстерелә.

Укытучы алдан ук кисәтеп куя: беренче эшләп бетергән 5 кешедән соң сыйныфтагы калган балаларга эшләү өчен барлыгы 30 секунд вакыт бирелә).

| **укучылар саны** | **норматив** |
|---|---|
| 14-30 | 5+30 |
| 11-13 | 4+30 |
| 8-10 | 3+30 |
| 6-7 | 2+30 |
| 2-5 | 1+30 |

*(җавап бирүчеләргә матрицага + куябыз )*

Марсель Галиев "ЧАТЫР ТАУ" :

1.Туган як **тәхете**-Чатыр тау
2. **Аргамаклар** таудан чаба.
3.**Тугайларда,тугайларда** - томаннар

10. **Тургай** булып оча күңел

Нур Әхмәдиев “АЗНАКАЕМ – АК БИШЕГЕМ”

4. Мин бит синең **гашыйк** балаң...

Илдус Гыйләҗев “ЧАТЫРТАУГА МЕНСӘМ”

5-6. Чатыртауга менеп **күз сирпесәм**

**7. Офык**ларым йөз кат киңәйде.

8. **Байбак**лары җавап кайтарды.

9. Чит җирләрнең **оҗмах**, җәннәтенә
Алыштырмам туган якларны!

Шигырьләрне ни дәрәҗәдә игътибарлы укуыгызны **Матрица таблицасы** ярдәмендә тикшерүебезне дәвам итәбез *(таблица дәрес башланганчы тактага сызып куела).* Сорауларга җавап кыска һәм төгәл булырга тиеш. Сорауларга бирелгән җавапларны таблицага плюс яки минус куеп бару юлы белән эшлибез. (Укытучы Матрица таблицасы буенча **,** укучыларга сораулар бирә. Сораулар Матрица таблицасыдагы тәртип буенча булмаска да мөмкин. Әгәр дә укучы җавап бирә алмаса, сорауга минус тамгасы торган укучы җавап бирә Ул укучы да җавап бирә алмаса, җавапны калган укучылар бирә . Алар да башкара алмаса, укытучы үзе аңлата)

1. Кайсы шагыйрь Чатыр тавыбызны – туган як бәхете, аның тәхете, дип атый?*( Марсель Галиев)*

2. Татарстанның иң уникаль табигать һәйкәле булган Чатыр тавының биеклеге күпме? *(334, 5 м)*

3. “Чатыртауга менсәм” шигырендә Илдус Гыйләҗев нинди җәнлекләрне “сызгырып эндәштеләр” ди? *(байбаклар)*

4. Аргамак – нәрсә ул? *(чабыш аты)*

5. Нур Әхмәдиев “Азнакаем – ак бишегем” шигырендә нинди казылма байлык турында искә ала? *(нефть)*

6. Марсель Галиевнең “Чатыр тау” шигырендә “күңел нинди кош булып оча”? *(тургай)*

7. “Азнакаем – ак калам,
Җиреңнән җылы алам”, - дип кайсы шагыйрь язган? *(Нур Әхмәдиев)*

8. Бу 3 шагыйрьне ни өчен “Чатыртау мәҗнүннәре” дибез? *(Чатыр тау белән илһамланып иҗат итәләр. Туган якка дан җырлыйлар)*

9. Аларны нәрсә берләштерә? *(туган төбәгебез, Чатыр тау, аларга 75 яшь, юбиляр шагыйрьләр)*

10. Үз туган ягында яшәп калган “җир шагыйре”, “Чит җирләрнең оҗмах, җәннәтенә Алыштырмам туган якларны!” дип язган шагыйрь кайсысы? *(Илдус Гыйләҗев)*

- Әйе, укучылар, Илдус Гыйләҗев гомер буе туган төбәгебездә яшәде, шунда иҗат итте. Аның кызы - Гыйләҗева Резедә Илдус кызы - үзешчән композитор, Мәхмүт Хәсәнов премиясе лауреаты. Ул – безнең мәктәпнең алыштыргысыз музыка укытучысы да. Әтисе белән берлектә “Азнакаем, Азнакай” җыентыгын иҗат итте *(җыентыкны күрсәтү).* Алар -“АЗНАКАЙ ГИМНЫ”ның да авторлары (газетабызның 5 нче битенә игътибар итегез!)

Г.Тукай премиясе лауреаты, төбәгебезнең данын еракларга яңгыраткан яраткан язучыбыз Марсель Галиев Казанда яши.

**8 нче этап. Икенчел тикшерү- ныгыту.**

Якташ шагыйрьләребезнең шигырьләренә, аларның шигъри теленә сокланмый мөмкин түгел. Әйдәгез, шигырьләрдән шуларны эзләп карыйк әле. Сезгә *карточкалар* таратам. Карточкалар буенча **парларда** эшләрсез. Андагы троплар - сурәтләү чараларын түбәндәгечә + тамгасы белән билгеләргә кирәк. 2 минут вакыт бирелә. **5+30 системасы** белән эшләрбез *(укучылар билгелиләр, вакыт чыккач,слайдта бирелгән дөрес вариант белән тикшерәләр)*

| **Троплар** | Эпитет | Сынландыру | Метафора |
|---|---|---|---|
| Байбаклары җавап кайтарды | | + | |
| Чатыртауга менеп күз сирпесәм | | | + |
| Җаннарымның әллә бер яртысы<br>Кала микән Азнакаемда? | | | + |
| Азнакаем – ак калам,<br>Җиреңнән җылы алам. | + | | |
| Тургай булып оча күңел | | + | |
| Йолдызлар да күзен кыса | | | + |
| Тауларның да маңгаена<br>Языладыр, язылыдыр язмышлар. | | | + |
| Туган як тәхете-Чатыр тау<br>Туган як бәхете-Чатыр тау. | | | + |
| Без ялгышсак,тауларга да<br>Кагыладыр ялгышлар. | | | + |
| Офыкларым йөз кат киңәйде | | + | |

**Нәтиҗә*:*** Әгәр дә 3 баганага да җавап биргәнсез икән 3 балл, 2 баганадагы җаваплар өчен 2 балл, 1 се генә булса 1 балл куела.

**9 нчы этап.Рефлексия**

***Максат: дәрестә эшләгән эшләргә нәтиҗә ясау***

**Укытучы.** Бүгенге сыйныфтан тыш уку дәресебездә нинди максатка ирештек? Туган якның танылган шәхесләреннән кемнәрнең иҗатын, шигырьләрен өйрәндек? Ни өчен дәресебез *“Туган як тәхете - Чатыр тау”* дип аталды? *(җаваплар тыңлана)*

**Укытучы.**

Әйе, шушы якларда туып - үскән күпләрне кулына каләм алырга мәҗбүр иткән туган ягыбыз тәхете булган Чатыр тауның данын еракларга яңгыраткан шагыйрьләр иҗатына тукталдык.

Сулар өчен һава, эчәр өчен су, азыкланыр өчен икмәк кирәк булган кебек үк, кеше җаны һәрчак туган җиренә омтыла. Шуңа да аңа дан җырлаучы сәләт ияләре – без бүген телгә алган шагыйрьләребез зур хөрмәткә лаек.

Без алар белән горурланыйк, алар сыман туган җиребезне яратыйк, Азнакаебыздан, Чатыр тавыбыздан илһам алыйк!

Буклетыбызның соңгы битендә минем дә мәгъруур Чатыр тавыбызга карата хисләрем чагылган шигырь бар! *(өзек уку)*

**ЧАТЫР ТАУГА КИЛ ӘЛЕ...**

Туган як симфониясен суза Чатыр тау моңы
Бер килсәң, оныта алмассың безнең як матурлыгын.
Әгәр, дустым, килеп күрсәң, хәйран калып китәрсең.

Чатыр таулы Азнакайны бик тә якын итәрсең.
Мәгърур тау ул – туган якның алтын бишек, тәхете.
Чатыр таулы Азнакайда мин дә таптым бәхетем.

Шулай, күп җырларда җырланган, шигырьләрдә тасвирланган Чатыр таулы, гүзәл табигатьле, 90 еллык бай тарихы булган сихри төбәк-Азнакайда яшәвебез белән без бик бәхетле, укучылар!

**11 нче этап. Өй эше бирү** (1-2 мин.)

Һәр төркемнең өстәлендә конвертлар бар. Аларда төрле төстәге карточкалар тупланган. Сез үзегезгә ошаганын сайлап алыгыз!

**1 нче төркем** “Азнакай”:

**Кызыл карточка** - Азнакай турында шигырь язып карарга.

**Зәңгәр карточка –** Үз төркемегезнең шигырен ятларга.

**Яшел карточка** – Азнакай турында бүтән шагыйрьнең шигырен сәнгатьле укырга өйрәнергә.

**Сары карточка** - Азнакай турында рәсем ясарга.

**2 нче төркем “**Чатыр тау” :

**Кызыл карточка** - Чатыр тау турында шигырь язып карарга.

**Зәңгәр карточка** – Үз төркемегезнең шигырен ятларга.

**Яшел карточка** – Чатыр тау турында бүтән шагыйрьнең шигырен сәнгатьле укырга өйрәнергә.

**Сары карточка** - Чатыр тау турында рәсем ясарга.

**3 нче төркем** “Туган тел”:

**Кызыл карточка** - Туган тел турында шигырь язып карарга.

**Зәңгәр карточка** – Үз төркемегезнең шигырен ятларга.

**Яшел карточка** – Туган тел турында бүтән шагыйрьнең шигырен сәнгатьле укырга өйрәнергә.

**Сары карточка** - Туган телебезне саклау турында рәсем ясарга.

## Сыйныфтан тыш чара. Марсель Галиев иҗатында туган як темасы

*Махиянова Рүзилә Миргазиян кызы,*
*Әлмәт шәһәренең“17нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”*
*нең татар теле һәм әдәбият укытучысы*

Туган җирем тургай булып
Сыйган күңел читлегенә

Укытучы:

Хәерле кон укучыларым! Без сезнең белән Татарстанның халык язучысы, татар халкының горурлыгы булган прозаик һәм шагыйрь Марсель Галиев иҗатында туган як темасы буенча эзләнү һәм өйрәнү эшләре үткәрдек. Белгәнегезчә, Марсел Галиев күпкырлы талант иясе. Марсель Галиев әсәрләре тема һәм жанр ягыннан бик бай. Аның шигъри тәлгәшләрендә, проза әсәрләрендә дөнья матурлыгы, якыннарына мәхәббәт, динебезгә һәм туган ягыбызга, тарихыбызга, телебезгә чиксез хөрмәт чагыла. Аның әсәрләрендә туган як темасы әйдәп баручы темаларның берсе булып тора. Адәм баласы кай тарафларда йөрсә дә, кайда гына яшәсә дә, аның уенда газиз туган җире.

Безнең алга куйган бурычлар:

1) Марсель Галиев хезмәтләре белән танышу.

2) Әдип иҗатында туган як темасының чагылышын күзәтү.

1нче укучы:

Марсель Галиевнең **„Туган як”** шигыре матур Азнакай төбәгенә багышланган. Лирик герой өчен туган як яме тормыштагы һәрнәрсәдән өстен. Аның туып- үскән ягында гына „йолдызлар тәлгәш- тәлгәш сибелә”, „таулары ап- ак яллы болытларны тышаулый”, „абагалары чәчәк ата”, „суларында кояш йөзә”, „күкеләре меңгә кадәр саный” . Гипербола – арттыру , сынландыру алымнары аша лирик геройның соклану хисе үстерелә. Шигырьнең беренче строфасы болай яңгырый:

Шундый як ул, карагыз сез
минем туган җиремә,
йолдызлар хәтта кызыгып
тәлгәш- тәлгәш сибелә.

Автор соңгы строфада үзенең яшәгән урынын сер итеп кенә укучыларга җиткерә.

Ышанмыйча сез сорарсыз:
Чынлап, андый җир кайда?
Сер итеп әйтәм алайса:
Аз-на-кай-да!... Шагыйрь шулкадәр җылы итеп, сокланып үз туган ягы турында гына яза ала.

2нче укучы:

**„Танышу нидән башлана?”** шигырендә туган авылын мактый. Аның кешеләре дә гадирәк, суы да тәмлерәк, таңы да матуррак, һавасы да сафрак.

Ни генә юк авылымда
тәмле чишмә сулары,
кәҗә сукмагыннан менсәң
җил сызгыра таулары.

Аның бу шигырен укыганда синең алдыңда чылтырап аккан чишмәләре, биек таулары белән бөтен бер дөнья ачыла.

3нче укучы:

**„Шәһәрдә нәүмиз хәтер” ш**игыренә игътибар итик. Бу әсәрендә шагыйребез үзенең туган авылын, анда үткән бала һәм үсмер чагын сагынуын гап- гади генә, әмма бик үтемле итеп тасвирлый. Бу шигырьне без туган нигезен сагынуның югары дәрәҗәдәге үрнәге, дип әйтә алабыз. Аны, әлбәттә, хәтерендә калган авыл чишмәсе төбендәге чуерташлар, тегермән, тәмле алмалар сагындыра. Ул уендашларын, сугыш кичкән агайларны сагына. Аның хәтерендә ат җигәргә өйрәнүләр, аулагыйлар, кунак кызлары, ул чорның ярлылыгы һәм бай күңеле. „Туган ягын сурәтләгәндә ул хыялый бер үсмер, ялларын тузгытып далада чапкан кырыкмыш тай, беренче саф мәхәббәте кабынган гашыйк, туган җиренең газиз баласы сыман! Гаҗәеп эпитетлар, сынландырулар, ашкын хисләр тулып тора аның туган әсәрләрендә. Миңа калса, Марсель туган җирен, Азнакай буйларын, җир өстеннән генә түгел, кошлар очар биеклектән күзәтә”, - дип яза Гариф Ахунов.

4 нче укучы:

**„Туган як тургае”**шигырендә ул туып- үскән җирендә генә бәхет тәмен белгәнен яза, аңа язу өчен илһамны туган ягы бирә. Туып- үскән нигез кеше

күңеленә моң сала, аны канатлы, илаһи итә, яшәүгә көч өсти, онытылмас моң булып озатып йөри. Анда аны газиз әткәе белән әнкәсе көтә.

Бәхет тәмен beләм
туган җирдә генә,
иген кырларына күмеләм.
Монда – гомер юлым,
монда – туган моңым,
тургай булып җырлый күңелем.

Бу нәфис яңгыраучы юлларда горурлану белән баетылган шатлык- сөенеч тасвирлана.

5нче укучы:

**„Ераклыклар җиле”** шигыренә игътибар итик:

Туган якның бүресе дә якын
бөкресе дә гарип тоелмыйдыр,
Җыры тынмас салкын чишмәләрнең
Суын эчеп кенә туелмыйдыр.

Шагыйрь туган ягын җаны- тәне белән яратмаса, мондый юлларны яза алыр идеме?

6 укучы:

Марсель Галиев иҗатында күңелнең иң нечкә кылларын тибрәткән әсәрләрнең берсе- **“Чатыр тау җиле”**Чатыр тау итәгендә үскән кеше өчен бу әсәр-җан авазы. Минем үземнен дә бу тауга менеп, аның матурлыгы белән хозуланганым бар.Искиткеч матур! Әлеге юлларны күзәтик: “Уй-хыялларыңа канат куяр өчен шушындый лаек биеклек кирәк икән. Кочагында- рәшә сулышыннан тибрәнгән япан киңлекләр. Бу кодрәт каршында үзеңнең бик кечкенә зат икәнлегеңне беләсең, әмма тау, үз биеклеге белән исертеп, сиздермичә генә олылау хисе юаныч бирә, күңел дөньяның чиге офык сызыгына тоташа да... йөрәгең тау йөрәге белән бер аһәңдә тибә башлый...” Бер генә тапкыр гына булса да, Чатыр тауга күтәрелергә кирәк әлеге язучы әйткән хисне тулысынча тою өчен!

Ә Чатыр-тау җилен ничек тасвирлый язучы: “Чатыр тау җиле үз катына кешеләр менгәнне нинди ярата, зарыгып көткән була; уйнаклап килеп кочаклап ала да, шатлыгыннанмы – әле җырлый, әле көлә, әле үкси... Аннары, үлән өстенә ятып мәтәлчек ата, билеңнән алып көрмәкләшә, аягыңа сөт тешле көчек булып сарыла, куеныңа кереп, суык борынлы песи булып мырылдый, сабый булып чәчеңне тузгыта, йолыккалый. Юк, мондый җил, мондый да саф, мәҗүси җил бүтән беркайда да исми, валлаһи исми. Рәхмәт сиңа, Чатыр- тау җиле! Күңелдәге юшкынны, гөнаһларны тараткан өчен мең рәхмәт сиңа! Җирсегән чакта җилне дә сагынасың икән!” “Чатыр тау җиле” традицион нәсер таләпләренә туры китереп иҗат ителгән. Нәсернең үзәге – туган җирне ярату хисен белдерү.

7нче укучы:

**“Нигез” п**овестендә дә туган якны сагыну, аның матурлыгына соклану темасы күтәрелә.“Кешеләр генәме, сулар да бит туган ягына кире кайта. Диңгезгә барып җиткән чишмә сулары, парга әйләнеп, болыт хасил итәләр дә, яңгыр булып, туган якка кайтып явалар. Табигатьнең ашкыну белән сагыну арасындагы мәңгелек бәйләнеше...” – дип яза ул әлеге повестендә.

Шулай ук туган як белән балачак аерылгысыз аның әсәрләрендә: “Тау астыннан караганда, авыл ак түбәләре белән уч төбендәгедәй җәйрәп ята. Сирәк кайтылганга күрә үзгәрешләр бигрәк тә нык сизелә. Ә мин, җүләр, һаман әле иске урамнарны, салам түбәле өйләрне юксынам. Малай чакта үзем ачып кергән капка тавышлары да хәтердән җуелмаган. Зур шәһәрләрдә, чит-ят илләрдә патшалар яшәгән, корольләр салдырган затлы сарайларны карап йөргәндә дә мин арыш саламы ябылган гади авыл өйләрен юксынып күз алдына китерә идем. Алтын белән чигелгән стеналар, читтән карап сокланыр өчен генә ясатылган асыл әйберләр – салкын купшылык иңне баса, җанны кыса башлый һәм шул чакта сиздерми генә артыңнан килеп кемдер чабуыңнан тарта, борылып карасаң... артыңда беркатлы елмаеп, малай чагың басып тора. Көзге кебек идәндә ул яланаякгыңнан яфрак-яфрак дымлы эзләр калдырып, сине үзе белән иярткә дә очыртып кына диңгезләр, кыя-таулар аша салам түбәле өйгә алып кайта. Тик... ул өйнең инде эченә сыеп керә алмыйсың. Арыш саламы ябылган “алтын түбәле” өй бала чакның бөек әкияте булып хәтер утравына күчкән.

Укытучы: Марсель Галиевнең барлык әсәрләре белән танышып чыктык. Тәнкыйтьчеләр язган мәкаләләргә дә игътибар иттек. Һәр иҗат кешесе үзенең туган җире, туган нигезе, суын эчеп үскән чишмәләренә мәдхия җырламый калмый. Марсель Галиевкә дә хас бу күренеш. Ул үзенең иҗаты аша безне туган телебезне, туган туфрагыбызны, үз нәселебезне, халкыбызның мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, күркәм йолаларын, тарихын хөрмәт итәргә, яратырга һәм беркайчан да онытмаска чакыра.Ә безнең бурыч-туган ягыбызны, телебезне, гореф-гадәтләребезне онытмыйча дәвам итәргә, яратырга һәм хөрмәт итәргә.

## Марсель Галиев шигырьләрендә Муйнак образы

*Мостафина Рената Радик кызы,*
*5 нче сыйныф укучысы, «Азнакай шәһәре гимназиясе”*
*Җитәкче: Хөсәенова Фәйрүзә Васил кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Марсель Галиев әсәрләре тема һәм жанр ягыннан бик бай. Аның шигъри тәлгәшләрендә, проза әсәрләрендә дөнья матурлыгы, якыннарына мәхәббәт, динебезгә һәм туган ягыбызга, тарихыбызга, телебезгә чиксез хөрмәт чагыла. Күпчелек проза жанрында иҗат итсә дә, мине Марсель Галиевнең шигырьләре таң калдыра. Дүртъюллык, ике-өч строфадан торган шигырьләренә дә күпме мәгънә салынган. Аның шигырьләре әллә ничекләр итеп җанны актара, рәхәт бер халәттә тибрәтә. Күз алдында төсләр, матур сурәт-картина. Аның теле, стиле үзенә бертөрле, беркемнекенә охшамаган: затлы, нәфис. Шагыйрьлек җене, хыялый алдану бәхете... Иҗатына бәяләмәне дә шагыйрьнең үз сүзләре белән кабатлыйсы килә: «Шигырь-мәңгелек упкынында тирбәлгән күңел бишеге...», «Шагыйрь-Күк белән Җир арадашчысы!»

**Теманың актуальлеге:** Г. Тукай исемендәге Татарстан дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык язучысы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Марсель Галиев - минем якташым. Балалар өчен язылган шигырьләре аның иҗатында билгеле бер урын алып тора. Дүрт томлык “Сайланма әсәрләре”нең беренче томында балалар өчен язылганнары “Сабыйлыкка ни житә?” исеме астында урнаштырылган. Биредә шагыйрь нинди генә образ тудырмаган... Төсле яңгыр, әтәч

койрыклы Кәҗә, умартачы Солтан бабай, җәяүле буран , Мырауҗан...санап китсәң, бик күп алар. Шулар арасында минем игътибарны Муйнак образы җәлеп итте. Әлеге образ Марсель Галиевнең җиде әсәрендә телгә алына. Шуңа күрә миндә Муйнак образы белән якыннан танышу теләге туды.

**Тикшерү объекты:** Марсель Галиевнең балалар өчен иҗат ителгән шигырьләре.

**Фәнни-эзләнү эшенең максаты:** Марсель Галиев яратып тасвирлаган Муйнак образына характеристика бирү.

Максатка ирешү өчен түбәндәге **бурычларны** үтәргә туры килде:

1) Марсель Галиевнең балалар өчен язылган әсәрләрен барлау.
2) Муйнак образын күрсәтүдә файдаланылган сурәтләү чараларын табу.

Муйнак образы Марсель Галиевнең балалар өчен язылган җиде шигырендә очрый. Муйнак – кечкенә генә көчек, минемчә. Чөнки аңа шагыйрь яратып кына:

Ипи – сиңа, Муйнак аша,
Әйдә, син дә үс әле! – ди “Кесәле шигырендә [1; 274]

Кечкенә малайның чалбар кесәсенә сыйган ипине дә яратып Муйнакка бирә ул.

Муйнакның тышкы кыяфәтен сурәтләгәндә, Марсель Галиев сурәтләү чараларыннан да бик оста файдалана. “Өтер койрыклы Муйнак”, “Кар борынлы Муйнак” [1; 288] кебек метафоралар кулланып, кечкенә көчекне безгә тагын матур итеп күз алдына китерергә ярдәм итә.

Тышкы матурлыгы өстенә, Муйнак-бик җитез дә икән әле. Кечкенә малайлар туп тибеп уйнарга бик яраталар. МарсельГалиевнең дә герое уйнарга бик ярата. Әлбәттә кечкенә Муйнак һәрвакыт аның белән янәшә.

Иң алдан гел туп йөгерә,
Аның артыннан Муйнак.
Алардан соң мин йөгерәм,
Арттан җил килә уйнап.
Кайткан чакта иң алда-җил,
Муйнак узалмый җилне.
“Без – дүртәү” шигыре [1; 270]

Этләрнең ихатадагы дошманнары, әлбәттә, песиләр. Аларның дуслыклары турында нинди генә әкиятләр сөйләсәләр дә, чынбарлыкта алар - бер-берсен күрә алмаучы ике хайван. Муйнак та Мырауҗанга карата бик ачулы:

Үрә басып Муйнак өрә,
Тимер чылбыр шау тартылган,
Кабарынган Мырауҗанны
Өзгәләп тә атар сыман. [1; 239]

“Оялу” шигырендә Марсель Галиев Муйнакны бик усал итеп сурәтләп кенә калмый, ул аны мактанчык та итеп күрсәтә. Мырауҗан белән талашканда ул үзенең гел эштә булуы, көне-төне ихата саклавы белән мактана, ә мәчене ялкаулыкта гаепли. Үзеннән зур йөк төяп кайтучы кырмысканы күргәч кенә, аларның бәхәсләренә нокта куела. Муйнакка шул кечкенә генә кырмыска алдында оят булып китә.

Чынбарлыкта бер-берсенә дошман булсалар да, шагыйрь үзенең рәсемендә аларны “дуслаштырып” та куя. “Альбомдагы рәсем” шигырендә:

Муйнак ята телен салындырып,
Мыраубикә аның сыртында.

Песи тирәсендә бөтерелә –
“чи-чи” килгән тычкан да монда! [1; 257]

Татар халкы элек-электән йорт хайваннарын, бигрәк этләрне яраткан. Чөнки алар хуҗаларына хыянәт итмәгәннәр, киресендә аларны саклап, яклап торганнар. Шагыйрь Мунакның тагын бер сыйфатына туктала: ул укымышлы һәм бик акыллы да икән әле.

Кара күзлекле Муйнак
Китап тоткан, күр әнә!
Мәчене куркытмаска
Өрү фәнен өйрәнә. [1; 249]

Марсель Галиев үзенең Муйнагын бик ярата. Ул аның чалымнарын һәркайда күрергә тели. Хәтта урман артында ишетелгән кайтаваз тавышында да ул Муйнак тавышын ишетә:

Учны-учка куеп без кычкырдык:
- Җиләкле урын кайдаауу?
Муйнак булып өрде урман
-Һау! Һау! һау! һау! [1; 255]

Фәнни – эзләнү эше барышында мин шагыйрьнең күп кенә шигырен укып өйрәндем, андагы образларны барлап чыктым. Гомумән, Марсель Галиев Муйнакны үз шигырьләрендә бик яратып сурәтләгән дигән нәтиҗәгә килдем. Төрле сурәтләү чаралары аша Муйнакны безгә акыллы да, кыю да итеп күрсәтә ала.

Эшемне Муйнакның барлык сыйфатларын туплап язган шигырь юлларым белән төгәллисем килә:

Муйнак дигән көчек белән
Таныштырдым мин сезне.
Марсель абый шигырьләре
Уйландыра бит безне.
Балалар да, өлкәннәр дә
Яраткан көчек Муйнак.
Үзе шаян, үзе җитез,
Үзе һәрвакыт тыйнак.
Муйнак белән якыннан
Танышырга булсагыз,
Марсель Галиев язган
Шигырьләрне укыгыз!

## Әдәбият дәресләрендә предметара бәйләнешләр принцибын тормышка ашыру

(7 нче сыйныфта Марсель Галиев иҗатын тарих һәм музыка фәне белән бәйләп өйрәнү буенча дәрес эшкәртмәсе)

*Мөхетдинова Резеда Фәвис кызы, “Лениногорск шәһәре 3 нче санлы урта гомуми белем бирү мәктәбе” нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы.*

**Максат**: Марсель Галиевнының “Уйна әле...” хикәясен анализлау

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**:

***Предмет буенча***: Марсель Галиев иҗатында булган үзенчәлекләрне өйрәнү, әдәбият, тарих һәм музыка фәннәре буенча белемнәрне тирәнәйтү;

***Предметара нәтиҗәләр***:

регулятив:
- уку мәсьәләсен кабул итү һәм дәрес дәвамында шуның буенча эшләү;
- куелган мәсьәлә нигезендә үз эшчәнлегеңне планлаштыру.

танып белү:
- укылган материал буенча үз фикереңне формалаштыра белү;
- өлешләрдән бербөтенне төзи белү;
- гомумиләштерү.

коммуникатив:
- үз карашыңны, фикереңне формалаштыру;
- бердәм эшчәнлектә уртак нәтиҗәгә килә белү;
- иптәшеңнең җавабын тыңлый белү;
- төп фикерне аерып ала белү.

***Шәхси нәтиҗәләр***: чагыштыра, гомумиләштерә белү, сөйләм телен камилләштерү, белемнәрне гамәлдә куллана белү.

**Дәрес төре**: яңа теманы өйрәнү.

**Метод һәм алымнар**: әңгәмә, дәреслек белән эшләү, биремнәр үтәү, сорауларга җавап бирү һ.б.

**Принциплар**: фәннилек, аңлылык һәм активлык, предметара бәйләнешләр принцибы, аңлаешлылык һәм көч җитү, системалылык һәм эзлеклелек, укучының шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алу, күрсәтмәлелек, аралашу.

**Чаралар**:
- программа, дәреслек, кулланмалар;
- компьютер, проектор, экран, пианино, пюпитр, гитара, граната муляжы шинель, солдат сумкасы, пилотка һ.б.

**Предметара бәйләнеш**: татар әдәбияты, музыка, тарих.

**Җиһазлау**: дәреслек, музыка өлкәсенә караган һәм сугыш чорын чагылдырган

**Укучылар белән эшләү формасы**: индивидуаль һәм фронталь.

**Дәрес барышы:**

I. ***Мотивлаштыру-ориентлаштыру этабы***.

1. Исәнләшү.

*Әдәбият укытучысы*: Исәнмесез, укучылар!

*Укучылар*: Хәерле көннәр!

*Әдәбият укытучысы*: Кәефләрегез ничек?

*Укучылар*: Яхшы!

*Әдәбият укытучысы*: Димәк, татар әдәбияты дәресен башларга мөмкин. Бүгенге дәрес бик кызыклы булырга охшап тора. Иң элек, өй эшләрен тикшереп алырбыз.

2. Өй эшен тикшерү, нәтиҗәләр ясау.
3. Уку мәсьәләсен кую.

*Әдәбият укытучысы*: Укучылар, без әдәбият дәресләрендә төрле әдәби әсәрләр белән танышабыз, алар буенча фикер алышабыз, анализлыйбыз. Сыйныфның бүгенге бизәлешенә игътибар итегез әле, без бүген нәрсәләр турында сөйләшербез икән, ничек уйлыйсыз?

*Укучылар*: Музыка һәм сугыш турында.

*Әдәбият укытучысы*: Укучылар, сезнең җавапларыгыз бик дөрес! Сез моны каян белдегез?

*Укучылар*: Сыйныфтагы предметларга карап белдек.

*Әдәбият укытучысы*: Сез бик сизгер икән! Афәрин! Укучылар, ничек уйлыйсыз, без моны кайсы язучы иҗатына бәйләп өйрәнербез?

*Укучылар*: Марсель Галиев иҗатына. Чөнки тактада Марсель Галиевның портреты тәкъдим ителә.

*Әдәбият укытучысы*: Дөрес!

**1 нче нәтиҗә.** Бүгенге дәрестә Марсель Галиевның “Уйна әле...” хикәясе белән танышабыз.

4. Дәреснең максатын билгеләү

*Әдәбият укытучысы*: Әйе, укучылар, без бүгенге дәрестә Марсель Галиев иҗаты белән танышабыз. Димәк, безнең максатыбыз нинди була?

*Укучылар*: Марсель Галиев иҗатына хас үзенчәлекләрне ачыклау, “Уйна әле...” хикәясен анализлау.

*Әдәбият укытучысы*: Афәрин! Бик яхшы!

II. Уку мәсьәләсен чишү этабы.

5. Яңа теманы өйрәнүгә әзерлек максатыннан белемнәрне актуальләштерү.

Музыка укытучысы пианинода “Әллүки”дән өзек уйный. Уйнап туктагач, укучылар белән сорау-җавап формасында әңгәмә үткәреп ала.

*Музыка укытучысы*: Хәерле көн, укучылар! Сез әлеге генә бер музыкаль әсәрдән өзек тыңладыгыз. Сезнең аны моңарчы кайчан да булса ишеткәнегез бар идеме?

*Укучылар*: Әйе.

*Музыка укытучысы:* Сез бу көй белән кайда очраштыгыз?

Укучыларның җаваплары тыңлана (әбием көйләп йөри иде, Илһам Шакиров башкаруында ишеткәнем бар һ.б.)

*Музыка укытучысы:* Сез әлеге көйне тыңлаганда нинди хисләр кичерәсез?

Укучыларның җаваплары тыңлана

*Әдәбият укытучысы*: Марсель Галиевның “Уйна әле...” хикәясендә дә “Әллүки” телгә алына. Ул әсәрнең кайсы өлешендә килеп керә?

*Укучылар*: Михаил бүреләр алдында үлем белән бергә-бер очрашкач, бу көйне исенә төшерә.

*Әдәбият укытучысы:* Ни өчен?

*Укучылар*: Чөнки бу көй аның күңеленә бик якын, ул аңа туган ягын, яыкннарын исенә төшерә. Ул үлем каршында үзен ялгыз итеп тоймас өчен, “Әллүки”не искә ала.

*Музыка укытучысы*: Укучылар, сезгә әсәрдә таныш булмаган берничә музыкаль термин очрагандыр. Әйдәгез әле, экранга күз салыйк һәм аларның мәгънәләрен, рәсемнәрен карап узыйк.

Экранда түбәндәге сүзләр мәгънәләре һәм рәсемнәре белән бергә тәкъдим ителә:

*Пюпитр* *Аккорд*

*Соната* *Гитара*

*Клавиша*

**2 нче нәтиҗә**. Кешегә авыр вакытында күңеленә якын көйләр, музыка ярдәмгә килә, хәлен җиңеләйтә.

*Музыка укытучысы*: Гитара образы әсәрдә нинди роль уйный. Ни өчен автор нәкъ менә шушы уен коралын сайлаган?

*Укучылар*: Әсәрдәге гитара образы зур әһәмияткә ия. Чөнки гитара кыллардан тора. Әсәрнең төп герое Михаил үлем белән күзгә-күз очраша. Димәк, аның гомере дә кыл өстендә дигән сүз. Гитара Михаилның тормыш юлын чагылдыра.

*Әдәбият укытучысы*: Михаилның баштагы гомере бәхетле узганмы?

*Укучылар*: Юк, аның гомере бәхетле узган дип әйтеп булмый. Ул ятим кала һәм аны урыс карчыгы тәрбияләп үстерә. Шуңа күрә ул Мөнир дигән исемен Михаилга үзгәртергә мәҗбүр була.

**3 нче нәтиҗә**. Михаил гомер буе үзен бәхетсез хис итә

III. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту.

*Әдәбият укытучысы:* Укучылар, хикәя нинди вакыйгага нигезләнеп язылган?

*Укучылар*: Хикәядә Бөек Ватан Сугышы вакыйгалары искә алына?

*Тарих укытучысы*: Укучылар, без Бөек Ватан Сугышы турында шактый күп мәгълүмат беләбез. Бүген дә әлеге ямьсез вакыйганы искә алмый мөмкин түгел. Чөнки анализлана торган әсәрдә дә сугыш төп урынны алып тора. Игътибарны экранга юнәлтик (Сугыш вакытын чагылдырган бер өзек тәкъдим ителә. Видеоязманы караганнан соң, тарих укытучысы да БВС турында бераз мәгълүмат бирә).

*Тарих укытучысы*: Әсәрдә Бөек Ватан Сугышына бәйле нинди урыннар бар?

*Укучылар*: Беренчедән, әсәрнең төп герое Михаил сугышта катнашып кайтып килә. Аның белән бер купеда кайтучы карчыкның улы да сугышта катанашкан, әмма аның үлде дигән хәбәре килгән.

*Тарих укытучысы*: Димәк, сугыш турында нәрсә әйтергә мөмкин?

*Укучылар*: Сугыш кешеләргә бары тик кайгы гына китерә.

**4 нче нәтиҗә**. Сугыш кешеләргә бары тик хәсрәт, кайгы гына алып килә.

IV. Рефлексия.

*Әдәбият укытучысы*: Укучылар, дәрестә алган белемнәребезнең ничек үзләштерелүен дифференциаль биремнәр ярдәмендә тикшерербез.

1 нче төркем өчен бирем: “Әсәр ни өчен өлешләргә бүлеп бирелә?”

2 нче төркем өчен бирем: “Автор ни өчен егетнең юлдашы итеп ялгыз карчыкны сайлый?”

3 нче төркем өчен бирем: “Хикәядәге чагыштыруларны табыгыз һәм аларның нинди роль уйнавын атагыз”.

Әдәбият укытучысы: Әйдәгез, биремнәрнең үтәлешен тикшереп чыгабыз (биремнәрнең үтәлеше дөрес яки ялгыш булудан чыгып, укытучы укучыларга билгеләр куя).

V. Дәресне йомгаклау.

6. Дәрескә нәтиҗәләр ясау.

*Әдәбият укытучысы*: Бүгенге дәрестә нәрсә өйрәндек?

*Укучылар*: Без Марсель Галиевның “Уйна әле...” хикәясен өйрәнеп анализладык.

*Тарих укытучысы*: Әсәр нинди вакыйгаларга нигезләнеп язылган?

*Укучылар*: Әсәр Бөек Ватан Сугышы вакыйгаларына нигезләнеп иҗат ителгән.

*Музыка укытучысы*: Әсәрдә музыка нинди роль уйный?

*Укучылар:* Әсәрдә музыка төп герой Михаилның авыр вакытларында ярдәмгә килә, юата, яшәү көче өсти.

7. Дәрескә укучылар бәя бирә.

*Әдәбият укытучысы*: Дәрестә ничек катнашуыгызга карап, үз-үзегезгә бәя бирегез. Моның өчен каршыгызда торган карточкалар белән җавап кайтарыгыз (укучылар сигнал карточкалары белән җавап бирә)

8. Өй эше бирү.

*Әдәбият укытучысы*: Укучылар, көндәлекләрне ачып, өй эшен язып куябыз. Өй эше өч төрле вариантта тәкъдим ителә. Үзегез сайлап алып эшләрсез:

а) “Сугыш хатирәләре” темасына проект әзерләргә

б) “Кеше һәм моң” темасына инша язарга

в) Михаил Нагимовичка характеристика язарга

*Әдәбият укытучысы:* Укучылар, дәрестә актив катнашуыгыз өчен зур рәхмәт! Дәрес шактый кызыклы узды. Без өч фән укытучысы да сездән канәгать калдык. Исән булыгыз!

## М. Галиев иҗатында туган як темасы

*Рахманова Диана, 7 сыйныф, “Азнакай шәһәре*
*5 нче урта гомуми белем бирү*
*һәм инглиз телен тирәнтен өйрәнү мәктәбе”.*
*Җитәкче: Шәхмиева Светлана Фәрәсәт кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Һәр төбәкнең үзенең күренекле шәхесләре, атаклы кешеләре була. Безнең районыбыз да талантлы шәхесләргә бик бай. Без әлеге күренекле шәхесләрне һәрдаим искә алабыз, әдәбият дәресләрендә якташ язучыларның иҗатларын өйрәнәбез. Шулар арасында миңа иң ошаганы – Марсель абый Галиевның иҗаты. Аның теле дә, стиле дә башка, чөнки ул берәүне дә кабатламый, берәүгә дә иярми. Аның һәр нәрсәгә үз карашы, үз мөнәсәбәте. Шуңа күрә минем Марсель абый иҗатын тирәнрәк өйрәнәсем, аның иҗаты турында күбрәк беләсем килде. Бигрәк тә туган ягыбызга багышланган әсәрләре мине кызыксындырды. Шуңа әлеге хезмәтемдә Марсель Галиев иҗатында туган як темасын күзәтүне **максат** итеп алдым. Минемчә, өйрәнелә торган бу тема мәктәп кысалары өчен бик **актуаль**.

Хезмәтемнең **бурычлары**:

1) язучының иҗаты белән танышу; якташ шагыйрьнең шигырьләре аша туган ягыбызның үзенә генә хас булган кабатланмас матурлыгын күрергә өйрәнү;

2) башкаларга шагыйрьнең дөньясын җиткерү.

3) туган төбәккә, аның кешеләренә, табигатенә хөрмәт хисе уяту.

Төп өлеш.

Марсель Галиев проза һәм поэзия жанрында иҗат итә. Поэзиясендә булсын, прозасында булсын туган җиргә мәхәббәт, аны өзелеп сагыну, чиксез соклану хисләре кызыл җеп булып сузылган. Аның лирикасында туган як темасы әйдәп баручы темаларның берсе булып тора.

Күзәтүемне Марсель Галиевнең “Туган як” шигыреннән башлыйм. Бу шигырьдә нинди серле итеп сурәтли алган ул туган якны. Аның туып- үскән ягында гына „йолдызлар тәлгәш- тәлгәш сибелә”, „таулары ап- ак яллы болытларны тышаулый”, „абагалары чәчәк ата”, „суларында кояш йөзә”, „малайлары Айга менеп кармак сала.”. Гипербола – арттыру , сынландыру алымнары аша лирик геройның соклану хисе үстерелә.

Туган якның тиңсез гүзәллеге, тагын бик күп шигырьләрендә, Марсель абыйга гына хас купшылык белән сурәтләнә.

Гап-гади Чатыр тау да аның өчен тау гына түгел:

Ерактан ул-зәңгәр пирамида.

Чал Уралның соңгы дулкыны.

Төбәгебездәге горур Чатыр тавының биеклеген һәм бөеклеген иң беренче Марсель абый дөньяга танытты. “ Чатыр тау җиле” нәсерендә ул аны мәгърур тау, туган як тәхете, туган ягымның йөзек кашы дип атый.

Марсель абыйның күңелендә туган якның ачык күңелле халкы, тиңсез матурлыгы яши.

Туган җирем,
Чибәр халкың суыңнандыр синең,
Күңелләре ачык капкалы.
Матуррак җирләр булса бардыр,
Тик мин сиңа тиңне тапмадым.

“Гомер йомгагы” әсәрендә балачагына кайта, күңелендә якты хатирәләрен яңарта: “Минем дә туган авылым, инешем, тау- үзәннәрем, урман- тугайларым, ерак киткән саен кечерәя барып, нәни генә хәтер йомгагына әверелеп, күңелемә күчкән...

Әнә ул - мин өстәл янында рәсем ясыйм,тышта буран, мич артында, тыйнак кына, чикерткә сайрый. Стенада күкеле сәгать келт-келт вакыт саный. Әни ястыкка аркасын терәп утырган да оек бәйли. Балачакның кадерле, самими сурәтләрен санап кына бетерерлекмени!”

Марсель абый  капка шыгырдавын да, әти-әнисенең тавышын да, күз карашын да, күрше- күләннәренең йөз рәвешен дә, авылының ярлы- ягымлы манзарасын да хәтерендә саклый. Һәм: ”Болар минем күңелемне юатып, илһамга баетып торучы истәлекләр,”- дип яза.

“Шәһәрдә нәүмиз хәтер” шигыренә игътибар итик. Бу әсәрендә шагыйребез үзенең туган авылын, анда үткән бала һәм үсмер чагын сагынуын гап- гади генә, әмма бик үтемле итеп тасвирлый. Бу шигырьне без туган нигезен сагынуның югары дәрәҗәдәге үрнәге, дип әйтә алабыз. Аны, әлбәттә, хәтерендә калган авыл чишмәсе төбендәге чуерташлар , тегермән, тәмле алмалар сагындыра. Ул яшьтәшләрен, сугыш кичкән агайларны сагына. Аның хәтерендә ат җигәргә өйрәнүләр, аулак өйләр, кунак кызлары, ул чорның ярлылыгы һәм бай күңеле.

Туган ягын сурәтләгәндә, ул-хыялый бер үсмер,  ялларын тузгытып чапкан колын, беренче саф мәхәббәте кабынган гашыйк, туган җиренең газиз баласы.

“Актүбә чишмәләре" шигырендә сагышлы юлларның кабатлануы шигырьнең тәэсирлелеген арттыра, сагыну хисен тагын да көчәйтә. Шагыйрь туган ягына ашкына, аңа мәдхия җырлый.

“Булсын иде” шигырендә ул авылын ни өчен сагынып кайтуын антитеза сурәтләү чарасы ярдәмендә аңлата.

“Туган як тургае" шигырендә ул туып - үскән җирендә генә бәхет тәмен белгәнен яза, аңа язу өчен илһамны туган ягы бирә.

Еракта яшәсә дә, туган төбәк, аның гүзәл табигате Марсель абыйны үзенә тартып тора.

Үскәнбезме таралышыр өчен
Туган җирдән ерак- еракка.
Яшәсәк тә кайсы тарафларда-
Юллар тарта һаман шул якка. –дип яза ул ”Туган җиргә мәдхия” шигырендә.

“Туган як мәзәкләре”ндәге каһарманнар туган төбәгебезнең  гади  кешеләре. Алар җылы юмор, кешегә мәхәббәт белән язылган. Аларда мин безнең якка гына хас исемнәр, безнең якта кулланыла  торган сүзләр очраттым. Ә бу инде  язучының туган яктан аерылгысыз икәнен күрсәтә.

Марсель абый әсәрләрендә очраган Тымытык, Сәпәй, Актүбә, Урсай, Әгерҗе һ.б.- болар безнең Азнакай районы авыллары, төбәкнең топонимикасы. Аларның һәрберсенең үз тарихы бар. Язучының әсәрләре аша алар күпләргә танылдылар.

Эзләнү эшемдә максатыма ирештем дип саныйм. Эш барышында Марсель Галиевның туган якка багышланган әсәрләре белән таныштым. Тәнкыйтьчеләр язган мәкаләләргә игътибар иттем.

Мин үткәргән тикшеренүләрдән күренгәнчә, Марсель абый-үзенең туган җиренә мәдхия җырлаучы язучы. Ул үзенең иҗаты белән туган якны яратырга, аны сакларга, күңел белән тоемлый белергә өнди, халкыбызны хөрмәт итәргә чакыра.

Минем уйлавымча, туган якларыннан читтә яшәүчеләр, Марсель Галиев шигырьләрен укып, күңелләренә тынычлык, юаныч, сагынуларына дәва табарлар.

Шундый якташыбыз булуы белән мин горурланам һәм Марсель абыйның иҗади мирасын ныклап өйрәнергә кирәк дип уйлыйм.

## Учымда-тургай шәүләсе
## *(Марсель Галиев иҗатында кош образлары)*

*Рахманова Нәзилә, 10 сыйныф,*
*«Азнакай шәһәре 4 нче лицее”*
*Җитәкче: Сабирова Халидә Гарифҗан кызы,*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

Көмеш телле кошчык сибә генә
Игеннәргә шифа сүрәсен.
Бу – бәхетле нокта.Башны чөям,
Учка кысып тургай шәүләсен.
*Марсель Галиев.*

Элек-электән үк кеше белән табигать аерылгысыз булган. Кеше үзен беркайчан да табигатьтән өстен куймаган. Ата-бабаларыбыз терлек-туар, кошлар һәм күбәләкләр белән киңәшеп, серләшеп, кайгы-шатлыкларны уртаклашып яшәгәннәр. Бу – рухи тормышның бөтенлеге.

Ата-баба сандугач, карлыгач, күке, кыр казы, тургай белән серләшеп гомер кичергән. Бу кошларның һәрберсе кеше күңеленә үзенчә тәэсир иткән, кеше күңеленең аерым халәтенә аерым кош булган (Мәһдиев, Бәхилләшү., 1990:426). Кошлар-табигать бизәкләре. Алар әкиятләрдә, мәкаль-әйтемнәрдә, йолалар, юраулар, төрле кушаматларда яшиләр. Кеше үз тирә-юнендә яшәүче, моңлы тавышлары, тышкы матурлыклары белән аның тормышын бизәүче, үзенә яхшы таныш булган кошларга мөкиббән. Кош образларын шагыйрьләр һәм язучылар үз иҗатларында яратып тасвирлыйлар. Кошлар белән кешеләрнең уртаклыгы шунда: алар да нәкъ кешеләр кебек, кошларда да кеше язмышлары.

Дөньяда, табигатьтә бик күп төр кошлар бар. Алар 28 отрядка, семьячылыкка, яки 8600 төркемгә берләшәләр (Сов. энц. слов., 1979: 1091-1092). Ә Идел-Урал регионында тереклек итүче кошларның төре өч дистәдән дә артмый. Татар халык авыз иҗаты әсәрләрендә һәм язучылар иҗатында әлеге кошларның барсын да очратырга мөмкин.

Фәнни-эзләнү эшемнең **объекты**-Марсель Галиев эшчәнлеге. **Предметы** исә Марсель Галиевнең кош образларын яктырткан әсәрләре.

Фәнни-эзләнү эшен язганда түбәндәге ***максат*** куелды: М.Галиевнең кошларга мөнәсәбәтен, образ буларак язучы иҗатында нинди кошлар алынуын, яратып кулланган образларын ачыклау, шагыйрьнең күңел халәтен чагылдырган образларны билгеләү.

Максаттан чыгып, түбәндәге ***бурычлар*** куелды:

1) Марсель Галиевнең тормыш юлына һәм эшчәнлегенә караган материалны барлау, туплау, системалаштыру;

2) Кошлар белән бәйле лирик әсәрләрен уку һәм анализлау.

Хезмәтнең ***структурасына*** килгәндә, фәнни-эзләнү эше керештән, төп бүлектән, йомгак һәм файдаланылган әдәбият исемлегеннән тора.

Бу тема ***бик актуаль, чөнки*** табигатькә, җан ияләренә мөнәсәбәттә кеше күңеле ныграк ачыла, әхлакый йөзе ныграк тоемлана.

М.Галиев иҗатында кош образлары ярдәмендә чагыштыру, метафора, янәшәлек һәм башка алымнар белән ясалган сүз-сурәтләр, тәгъбирләр лирик әсәрләрнең идеясен матур яңгырашлы, йөгерек телле, җыйнак формада белдерү өчен хезмәт итәләр. Лирик геройның тышкы һәм эчке матурлыгын, үз-үзен тотышын, рухи дөньясын тыңлаучы күңеленә тәэсир итәрлек дәрәҗәдә сурәтләүдә аларның роле зур.

М.Галиев шигырьләрендә иң киң таралган кош образлары-тургай, акчарлак, карга, сандугач, карлыгач, чыпчык, былбыл, торна, кыр казы, тәкәрлек, песнәк, саескан, бөркет, аккош, сыерчык, ләкләк, тилгән, тукран булса, шулар арасыннан язучы тургай образын аеруча яратып кулланган. “Тургай биеклеге” шигырендә лирик герой өчен буй җитмәс зәңгәр күктә очучы тургай образы бәхетле балачак белән бәйле:

Төнге юлның соңы җитеп килә,<br>
Ә малайҗан - татлы төшендә.

Тургайларга кадәр очып менгәч,<br>
Уяныр ул толып эчендә.

“Тургай шүәләсе” лирик әсәрендә “моң бәбәге” булган тургай бисмилла әйтеп ямьле җәйне башлый. Ул үзе “көмеш телле” һәм басудагы игеннәргә “шифа сүрәсе” сибә. “Арышлар буйга сикерә” шигырендә шагыйрь “тургай кояштан тама” дигән тасвир бирә. Малайчакның бәхетле мизгелләре дә тургай җыры белән бәйле. Гомумән, лирик геройның “тугайлары тургайлы”, “күңеле тургай булып җырлый”, “туган җире- тургай җыры”. Әдип өчен тургай – басу-кырлар Алласы:

Сары диңгез уртасында<br>
Җилкәндәй килә торасы.<br>
Ә күктә – кырларым Алласы –<br>
Җырдан яралган *тургай* баласы. “Август кыры”

М.Галиевнең  герой-шагыйрь Муса Җәлилгә атап язган шигырьләре байтак. Үзенең бөтен гомерен туган иленә, туган халкына багышлаган Муса Җәлилнең тормышы-героик тормыш ул. Менә ничә еллар инде ул халык күңелендә якты бер җыр булып яши. Муса Җәлил-үлемсез. Бернинди явыз үлем, бернинди дошман гильотинасы да аны безнең арадан алып китә алмый.  Шуңа күрә дә М.Галиев “Муса” шигырендә герой-шагыйрьнең җырларын *“күк тулы тургайлар”* дип тасвирлый;

Хыялымны кисә алмадың, җәллад!<br>
Тамыры аның илдә калды.<br>
Җырларымны сыйдыра алмадың зинданыңа.<br>
*Тургай* белән күкләр тулы!

Әдип лирик шигырьләрендә *сандугач* һәм *былбыл* образларын яратып куллана. *Былбыл* образы аша киләчәккә якты өмет белдерелә. *Былбыл* атамасы *сандугач* мәгънәсендә йөри. *Сандугач* атамасы *былбыл* сүзе белән алыштырыла. *Сандугач* образының үзенә генә хас мәгънә төрләре бик киң. Шагыйрьнең лирик шигырьләрендә сандугач-сөенеч-шатлык билгесе, ул туганнарның, дус-ишләрнең бергә җыелып күңел ачуларын гәүдәләндерүче. *Сандугач* лирик геройның рухи терәге-борчуларын уртаклашучы, аның сердәше ролендә килә.

“Былбыл җаны” шагыйрь Мөдәррис Әгъләмовка багышланган. Әдип шагыйрьнең җанын *“былбыл җаны”* дип атый. Халкы өчен затлы әсәрләр язган М.Әгъләмовның бәргәләнгән йөрәген *былбыл җаны* белән чагыштыра. Лирик герой фани дөньяда нибары 60 ел яшәгән шагыйрьне сагына һәм бик иртә бакыйлыкка күчүенә күңеле сызлана:

Шул халкым дип бәргәләнгән йөрәк
Соңгы тибешләрен саныймы;
Күкләр тынын сизгән *былбыл* җаны
Каурый канатларын саныймы?

Гадәттә, сандугач кеше күзенә күренми, шуңа аның гаҗәеп музыкаль тавышы күңелдә үзенә күрә бер серлелек уята. Бу исә үзенчәлекле символик мәгънә тудыра. “Җәй хозурында” шигырендә *күке сандугач* белән чагыштырып бирелә. *Күке* күпме генә тырышмасын, *сандугач* кебек матур сайрый алмас:

*Күкенең* тавышы үзгәргән,
Сакаулый, салкынмы тигәндер?
Ә бәлки, үз моңын үзгәртеп,
*Сандугач* буласы килгәндер.

М.Галиевнең “Мәңгелек хәрәкәт” шигыре Испания шагыйре бөек Федерико Гарсиа Лоркага багышланган. Бу гаҗәеп шагыйрьне әдип *сандугачка* тиңли һәм аны *“испан сандугачы”* дип атый:

Төнен кунып зәйтүн агачына
Испан *сандугачы* сайрыйдыр.
Яңа кабынасы йолдызларга
Күк бәгыре урын сайлыйдыр.

Туган тел! Бу сүз һәркем өчен кадерле, газиз! Чөнки тел – тормыш чыганагы. Һәркем өчен иң моңлы көй - үзенең милли көе, иң матур, иң кадерле тел-үзенең туган теле. М.Галиев туган телгә зур игътибар бирә һәм газиз туган телен *былбыллар теле* дип саный. Ә инде аның “Туган тел” шигырендә *былбыл* сайрап туган телгә кунган:

Бөек тә син, боек та син,
И туган тел, туган тел,
Күп гамәлләр кылган тел!
Аргамаклар җилеп чапкан,
*Былбыл* сайрап кунган тел.

Татарстан Республикасының беренче Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә багышланган “Дан язмышы” шигырендә “*былбыл моңы*”, “*бөркет ымы*” белән илбашының исеме чагыштырыла. Минтимер Шәрип улы-үзен бөтенләе белән туган милләтенә, республика халкына багышлаган шәхес. Хәзерге Татарстан Республикасын оештыручы, бөек тарихлы татар дигән милләтнең горур исемен

дөнья күләмендә ишеттерүче беренче Президентыбызның исеме кошлар белән бәйле икән. Аның исемендә *былбыл* аһәңе ишетелә һәм *бөркет* ымы чагыла. *Бөркет*-безнең якларда яшәүче иң зур, җитез һәм матур, нык аяклы, үткен күзле, киң канатлы  каракош. Бу корыч кебек кошның ныклыгы “Минтимер” исемендә чагылыш тапкан:

Мулла кушкан корыч исем
Тәкъдиренә булгандыр.
*Бөркет* ымы, *былбыл* моңы
Бер йөрәктә тугандыр.

М.Галиев,  Азнакай районы Уразай авыл хуҗалыгын күп еллар җитәкләгән колхоз рәисе Мөхәммәдъяров Ринат Әзәл улына багышлап, “Гомер тавыннан карап” исемле шигырен яза. Якын дустын *бөркетләр* биеклегенә күтәрә:

Җилгә канат куеп тормыш дәрте
*Бөркет* булып иңгә кунсын икән.
Ак болытлар баштан сыйпап узар
Лаек биеклегең булсын икән.

Әйе, кешене хезмәт бизи! Ул җитәкләгән зур хуҗалык районда гына түгел, республикада да алдынгылардан санала. Шуңа күрә дә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре исеменә лаек булган Ринат Әзәл улы-бөркетләр биеклегендә!

*Күке* -гомер озынлыгын фараз итүче, моңлылык, сагышлану билгесе. “*Кәккүк* туган якта Стәрле таллыгында гомер саный”. Яки “*күке*-урман чегәне-гомер юрый”. “*Күке* кычкырган чакта өянкеләр башын ия”.

М.Галиевнең язучы Хәсән Сарьянга багышланган “Ике урман чигендә” шигыре бар.  Монда кәккүк кайгы-хәсрәт символы буларак бирелә. Кәккүк яшь гомернең, гомумән, кеше гомеренең кыскалыгын искәртүче символ буларак кулланылган (Мәһдиев, фәнни хезм. җыент.,1982: 77):

Кем гомерен саный башлады соң,
*Күке* аваз салды якында?
*Күке* тавышы... Изге бер моң гүя,
Манарадай нарат янында
Тыңладык без, нинди моңсулык бу?
*Күке* чикнең теге ягында.

“Бер көнлек гомер” шигырендә лирик геройның *кәккүк* образы аша туган илен сагынуы, моңаю хисләре белдерелә. Ниндидер сәбәпләр аркасында туган җиреннән аерылган лирик геройның сагышы да *кәккүк* хәле белән тиңләштерелә:

Купшы залларга китереп,
*Күкене* тыңлап кара –
Өянке, инеш, болыннарр
Бар моңын алып кала.

“Торналар төшкәндә” туган як темасына багышланган. Туган җир манзарасын, күңелгә якын һәм газиз булган басу-кырлар, тауларны, тугайларны, урман-суларны. әлбәттә, *торналар* белдерә:

-Торыйк! – диеп, сузып-сузып,
Күк битенә сөрмә сызып,
Сагынып кайта *торналар.*

-Күлем кайда? Күгем – анда.
-Күгем кайда? Күлем – анда...

“Юл чатында” лирик әсәрендә юлчыларны озатып *торналар* оча. Аларның тавышлары  иңрәп кала. *Торна*-күчмә кош. Кешене моңаерга, хәсрәтләнергә мәҗбүр итүче тагын бер сәбәп-гомер иткән җирдән, якыннардан аерылу. Кешеләрнең дә язмышлары күчмә кошларныкы кебек:

Һаваларда-*торна* тавышлары .
Ишетелә канат кагышлары,
Кошларда да кеше язмышлары,
Чит җирләргә китеп барышлары. “Кайту”

М.Галиев Төркиягә баргач, Динизле шәһәрендә *әтәчкә* куелган һәйкәл күрә. Шуннан соң “Әтәчкә һәйкәл” исемле шаян шигыре туа. Шаян булса да, тирән мәгънә салынган. Гади генә дип йөргән *әтәчләрне* дә аңлау өчен, дөнья күрү кирәк икән бит!

Профессор Ф.Урманчиевның «Дастаннарга лаек замана» дип аталган хезмәтендә кошлар образы һәм аларның сайравы күп вакытта сагыш-моң, хәтта кайгы-хәсрәт белән янәшә килү гасырлар буе үстерелгән закончалык дип күрсәтелә (Урманчеев, 1990: 180). Мисал өчен *аккош* образын алыйк.  М.Галиевнең “Бер үк күпер булган юлыбызда” шигырендә *аккош* һәм *кара аккошны* чагыштырып бирә: *аккош* гел ак ул хыяллар; *кара аккош*-чынбарлык. Тормышта да нәкъ шулай.

Кошлар, юкса, бездән бәхетлерәк.
Яман сүздән җаны бизмәгән.
Ник соң Алла кешегә дә телне
Сайрар өчен генә бирмәгән?    “Ерак янәшәлек”

Акчарлак-зур су, диңгез кошы. М.Галиев иҗатында бу образ лирик геройның кайгы-хәсрәте, борчулы хисләре белән янәшә кулланыла. Акчарлаклар-Идел кошлары. Алар Идел буена язны алып килә:

Иделемнең ачык көндәлге сыман
Акчарлаклар күктә, укып кара... “Чистарыну”

“Яшьлек акчарлаклары” шигырендә бу кошлар лирик геройның яшьлеге символы буларак кулланылган. Лирик герой Агыйдел буенда яшьлеген исенә төшерә. Су өстендә уйнап очкан кошлар яшьлек *акчарлаклары* буларак тасвирлана:

Язылмыйча калган ак көндәлек сыман
Оча уйнап, безнең яшьлек *акчарлаклары*.

Марсель Галиев  кешегә гаять зур игътибар бирә, шәхес, язылган һәм язылмаган кануннар хакында уйлана, бүгенге көн күзлегеннән чыгып бәя бирә, үз-үзе белән бәхәскә керә, нәтиҗә ясый. Бу яктан әдипнең гыйбарәләре үткенлеге, төрткеле булулары белән аерылып торалар. Афористик гыйбарәләрдә  шагыйрьнең дөньяга карашы, яшәеш кыйммәтләренә мөнәсәбәте, фәлсәфи уйланулары чагыла. Тормыш-яшәешнең төрле ягына караган әлеге хикмәтле сүзләрдә иҗтимагый-сәяси мәсьәләләр, яшәеш кыйммәтләре, әхлакый төшенчәләргә бәйле проблемалар яктыртылган. М.Галиевнең кошлар белән бәйле афоризмнары да байтак. Әдипнең афоризмнары аша гомер итү, тәкъдир һәм язмыш, туганлык-дуслык мөнәсәбәтләре, эш-гамәл, дан-дәрәҗә, холык-фигыль хакындагы тирән мәгънәле фәлсәфи уйланулар аша тормыш һәм яшәеш үзенең агы һәм карасы белән күз алдына килеп баса. Әдипнең канатлы сүзләре фикер тыгызлыгы ягыннан игътибарны җәлеп итәләр (Тимергалин, Марсельезалы сәхифәләр, 2 нче том, 2011:381). Менә аларның кайберләре:

“Сандугач буласы килүдән кәккүкләр сакаулана”.

“Кара карга карда кара күләгә калдырмый”.

“Очып үтешли карлыгач түшен чылатып алгач, кытыкланып, күлнең зиһене таралды”.

“Гәрәбә күз күкнең сүтелгән сүрүен торналар белән типчи”.

“Бәхет кошын яралый күрмә”.

“Әтәчнең әтәчлеге кикригендә генә түгел”.

“Җырчы сәхнәдән сөйләргә тотынса, сандугач оятыннан чыпчыкка әверелә”.

“Очар кошлар кәрванын күреп талпынган җаның, күк гөмбәзенә бәрелеп канатын канатканда, үзең әрнемә, шагыйрь, сүзең әрнесен”.

Фәлсәфи фикерләүнең бер формасы булган афоризмнарда хәзерге чорның иҗтимагый-сәяси, мәдәни проблемалары, халык тормышына караган гомумиләштерүләр тупланган. Әдипнең афоризмнары образлылыгы, эмоциональ тәэсир итү көче, катлаулы күренешләрне үткен итеп чагылдыру, фикерне тыгыз итеп бирү мөмкинлеге белән характерлана.

Йомгаклап әйткәндә, шагыйрь кошлар дөньясы аша яшәешнең өзлексез агышын, табигать белән кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне тасвирлый. Аларның сайравы, җылы якка китүләре, я кайтулары кеше күңелендә моңсулык, сагыш тудыруы, якыннарны, сөйгән ярларны искә төшерүе, гомер агышын, дөньяның фанилыгын искәртүе-табигый хәл (Мәһдиев, фәнни хезм. җыент.,1982: 89 бит). М.Галиев табигатьтәге реаль кошлар белән “күңел кошы” арасында параллельлек үткәрә. Кеше күңеле хөрлек теләгән кебек, кошлар да азатлык тели. Кошларны рәнҗеткән кешенең үз күңеле дә тар, тоткынлыкта яши.

Әйләнә-тирәбезгә, кош-кортларга, җанварларга гына түгел, бер-беребезгә карата да матур мөнәсәбәтләр югала барган хәзерге заманда, Марсель Галиев әсәрләре мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек, киң күңеллелек, кайгыртучанлык кебек матур сыйфатларны үстерергә ярдәм итә.

## ***“Үз тәхетен эзлим һәрбер сүзгә...” (әдәби – музыкаль кичә үрнәге)***

*Сабирова Халидә Гарифҗан кызы, Азнакай шәһәре*

*4 нче лицееның туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

“Ул сүзләрне кая куярсың?” – дип
Сорасагыз миннән әгәр дә,
Үз тәхетен эзлим һәрбер сүзгә
Язылачак яңа шигырьдә.
М.Галиев

Кичә укучыларны язучының тормыш юлы, иҗаты белән таныштыру; әсәрләрен уку, бәяләү; шигъриятькә мәхәббәт тәрбияләү; сәләтле балаларны иҗади эшкә җәлеп итү, сәләтләрен үстерү өчен мәйдан ачу **максатыннан** уздырыла.

**Кичәнең барышы**

*Кичә Миргаяз Шәрәфиев башкаруында “Кайту” (М.Галиев сүзләре, Л.Батыр-Болгари көе) дигән җыр тыңлау белән башлана. Аннары укучылар М. Галиевнең “Туган як”, “Малай чакка хат”, “Туган як тургае”шигырьләрен сәнгатьле итеп яттан сөйли.*

**1 нче алып баручы.** Хәерле көн, хөрмәтле кунаклар, укытучылар һәм укучылар! Бүгенге кичә якташ язучыбыз Марсель Галиевнең иҗатына багышлана. Автор үзе дә әдәби-музыкаль кичәбездә катнаша. Әйдәгез, кадерле кунагыбызны кайнар алкышлар белән сәламлик.

**2 нче алып баручы.** Моннан 75 ел элек, 1946 елның 8 октябрендә Татарстанның Азнакай районы Балтач авылында игенче Баян абзый гаиләсендә Марсель исемле малай дөньяга аваз сала. Әле ул үзенең татар дөньясында үзенчәлекле шагыйрь, Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Марсель Гали булачын белми, әлбәттә. Моңарчы әле бик күп юллар узасы, зур эшләр башкарырга туры киләчәк аңа. (Экранда слайдлар: бала чагы, әти-әнисе)

**1 нче алып баручы.** Марсель абый, иң беренче язмагыз кайда һәм кайчан басылып чыкканы хәтерегездәме әле?

**Марсель Галиев.** 1968 елда. Азнакай районының "Маяк" газетасында. Армиядән кыска вакытлы ялга җибәргәннәр иде. Туган яктан яңадан китеп барыш. Поезд белән Идел аша чыкканда шундый юллар күңелгә килде:

Идел, Идел
Күзен кыса кояш нурларыннан,
Елмая күк сине каршылап.
Тукта, поезд, нигә ашкынасың,
Карый алмыйм сине яхшылап...

**2 нче алып баручы.** 1979 елда беренче китабы -"Еллар чалымы" исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. Әлеге җыентыкта тупланган лирик әсәрләре төсле аһәңгә бай: табигать сулышы һәм җан тибрәнеше бер яссылыкта үрелеп бара. Шуңа күрә дә аның шигърияте, укыган саен яңа төсмерләре белән ачылып, кабатланмас хисләр тудыра.

("Бер елганың ике яры", "Әбиләр чуагы", "Юл чатында" шигырьләре укыла)

**1 нче алып баручы.** Безнең якларның даны саналган, җырларда җырланган Чатыр тау М.Галиев иҗатында аеруча зур урын алып тора. Инде без күреп гадәтләнгән Чатыр тауны ул туган як тәхете итте. Аның күзгә-башка күренмәгән җиле дә, баксаң, бик үзенчәлекле икән. "... уйнаклап килеп кочаклап ала да, шатлыгыннанмы-әле җылый, әле көлә, әле үкси... аннары, үлән өстенә ятып мәтәлчек ата, билеңнән алып көрмәкләшә, аягыңа сөт тешле көчек булып сарыла, куеныңа кереп, суык борынлы песи булып мырылдый, сабый булып чәчеңне тузгыта, йолыккалый. Юк, мондый җил, мондый саф, мәҗүси җил бүтән беркайда да исми, валлаһи, исми..." – ди ул һәм менә шулай Азнакай ягының исәр җилләренә кадәр яратып, тәмләп яратып яза. Чатыр тауның җил-аргамагында ул үзе генә түгел, күпме язучыларны хозурландыра.

( "Чатыр тау" шигыре укыла.)

**2 нче алып баручы.** Әдип туган телебез язмышына, аның киләчәгенә битараф түгел. Ул борчыла, ана телен хөрмәт итәргә, онытмаска кирәклеген искәртә. Туган телгә дан җырлый.

("Туган тел" шигыре укыла)

**1 нче алып баручы.** Иҗат дөньясында һәркемнең үз тавы, үз биеклеге була. Мондый билгеләмә М.Галиевнең иҗатына бигрәк тә туры килә. Ул сүзләрнең тәмен, кадерен тоя, аларны зөбәрҗәт ташындагы төрле төсләр-чагылышлар белән уйната белә. Шагыйрь һәр сүзнең үз тәхетен эзләп таба белә. Тукай үзенең туган телен,

Шүрәлесен, Туфан Миңнуллин үзенең Әлмәндәрен, ә Марсель Галиев үзенең әнисе образын тәхеткә күтәререлек сүзләр таба.

*Зөһрә Шәрифуллина башкаруында видеоязмада "Су буеннан әнкәй кайтып килә" (М.Галиев сүзләре, Л.Батыр-Болгари көе) җырын тыңлау.*

**2 нче алып баручы.** М.Галиев халыкның җыр лирикасын да читләтеп үтми. Аның күп лирик шигырьләре җыр булып китә. "Һаваларда торна тавышлары", "Көзге моң", "Нинди моң бар төнге күзләреңдә?", "Су буеннан әнкәй кайтып килә", "Миләшле көз", "Миләүшә", "Син дә кайт мәхәббәт ярына" һ.б. шигырьләренә композиторларыбыз тарафыннан көй язылган. Кеше рухының нинди генә тирбәнешләре юк бу җырларда! "Болар классик җырлар, киләчәккә барачак затлы җырлар," - ди алар турында Равил Фәйзуллин.

*Миргаяз Шәрәфиев башкаруында "Көзге моң" ( М.Галиев сүзләре, Р.Яхин көе) романсын тыңлау.*

**1нче алып баручы.** М.Галиев-юмор остасы да. 1996 елда язучының "Кәефең шәпме?" китабы басыла. Әлеге китапта көлкеле хикәяләр, күренекле шәхесләр турында төртмәле һәм шаян истәлекләр тупланган. 2003 елда чыккан "Арыслан йокысы" китабында юморескалар, әдәбият-сәнгать кешеләре хакында елмаюлы хатирәләр язылган.

*("Рәтле эш", "Шәп чакларың бар иде", "Шүрәле нигә кирәк?" мәзәкләре укыла)*

**2 нче алып баручы.** Кеше күңелендә уелып кала торган иң якты, иң гүзәл вакыт – балачак. М.Галиевнең "Җиңәсем килде" (1981), "Шүрәле һәм җил" (1990), "Шүрәле гаеплеме?" (2002) китапларында балалар өчен язылган хикәяләр, шигырь һәм балладалар тупланган. Әлеге әсәрләрдә сабый бала дөньяны өйрәнә, аны танып-белергә тырыша, ә янында иң кадерле кешеләре -әнисе белән әтисе була. Балачактагы уеннар-иң кызыклысы, дуслар-иң якын җан дуслар, хыяллар-иң татлылары. Әдип бала күңеленең дөньясын бар нечкәлекләре белән ачып бирә.

**1 нче алып баручы.** М.Галиевнең тагын бер талантлы ягы-мемуарлар язу остасы булу. Әдипнең 1998 елда "Догалы еллар" исеме астында әдәби-публицистик китабы дөнья күрә. Нәби Дәүли, Хәсән Сарьян, Рөстәм Яхин, Равил Фәйзуллиннар турында хатирәләр яза. Язучының һәр кыйссасында тарих сурәтләнә. Канлы һәм шанлы, фаҗигале, кимсетүле һәм кисәтүле горур тарих! Рөстәм Яхин турындагы язмасында композиторның моң чыганагын болай тасвирлый: "Татарның киң ябалдашлы, тирән тамырлы гомер агачында сындырылган, күмерләнгән, кайгы-хәсрәт, әрнү-каргышлары гына түгел, биеккә үрелгән нык-сәламәт үсентеләрендә яшәүгә мәдхия, тыенкы сагыш, сөю-сәгадәт рухы да бар. Рөстәм ага үз иҗатында милли төсмерләрне нәкъ менә шундый тармаклардан үрелеп алгандыр."

**2 нче алып баручы.** Марсель Галиев-татар халкының язмышы, тарихы, бүгенгесе, теле, әдәбияты, мәдәнияте, хәтта мәзәге турында фәлсәфи фикер йөртүче, иҗаты жанр төрлелеге белән аерылып торган әдип. Гади генә күренешләрдән шигърият таба белү, табигатьнең нәфис төсләрен рәссамнәрчә күрә алу, хис һәм фикер тәңгәллегенә омтылу – М.Галиев иҗатына хас сыйфатлар, әнә шулар. Сүзнең тәмен, җаен белеп, моңын, көен тоеп, үткәннәргә нәтиҗә ясап, алга омтылып яши ул.

**1 нче алып баручы.** 2011 елда М.Галиевнең 6 томлык әсәрләре басылып чыкты. Әдипнең әсәрләре Европа һәм Азия халыклары телләренә тәрҗемә ителгән. Аерым

әсәрләре рус, поляк, украин, осетин, каракалпак, үзбәк, казакъ, чуваш халыклары телләрендә дөнья күрде.

*Хәйдәр Бигичев башкаруында видеоязмада “Казанымның җиде капкасы”(М.Галиев сүзләре, С.Вәлиди көе)җыры тыңлана. Алга таба язучы М.Галиевкә сүз бирелә.*

**2 нче алып баручы.** Хөрмәтле Марсель абый, безнең туган тел укытучыбыз Сезгә булган ихтирамын үзенең шигырь юлларында белдерә. Рәхим итеп тыңлагыз!

**Укытучы үзе язган шигырь юлларын укый.**

Иҗатыңа башым иям

Марсель абый, шигырьләрең укыйм да мин,
Уйга калам...
Шагыйрь йөрәгенә күпме җиһан сыйган
Таңга калам!
Син шатлансаң, Марсель абый,
Бөтен дөнья сөенәдер:
Зәңгәр күктә тургай сайрый,
Гөмбәзеннән кояш көләдер.
Син хәсрәтләнсәң, Марсель абый,
Җитә кебек ахырзаман!
Шундый тойгы... Йөрәк яна,
Күңелләрдә давыл уйный, бик тә яман.
Марсель абый, иҗатыңа башым иям,
Язганнарың ифрат затлы -
Күңел хөрлегеңнән киләдер.
Хөрлек тәэсиреннән туган горурлыгың
Һәммәбезне әсир итәдер!

## Марсель Галиевның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган дәрестән тыш чара

*Садриева Алия Габдулла кызы,*
*Әтнә районы Күәм урта гомуми белем мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

*Рухны сафландыра, калебне чистарта, телне, җанны баета торган, күңеленңнең иң түр диварына эленгән бакый шамаиленә мәңгелек хакыйкатьне нәкышләүче иҗат!*

*Хәезмәтнең актуальлелеге.* Марсель Галиев-татар халкының язмышы, тарихы, бүгенгесе, теле, әдәбияты, мәдәнияты, хәтта мәзәге турында фәлсәфи фикер йөртүче әдип. Базар икътисады, шоу-бизнес, реклама һәм пиар колач җәйгән хәзерге чорда милли рухны саклап калыр өчен, аның җитди, катлаулы, телгә бай иҗаты һәр татар баласына таныш булырга, өйрәнелергә тиеш дип саныйм.

Татар мәктәпләре өчен яңа стандартларга нигезләнеп төзелгән уку програмасына Марсель Галиевның түбәндәге әсәрләре кертелгән:

- 1 сыйныф - ”Кайтаваз мәгарәсе бүлеге”ндә ”Кайтаваз” шигыре (охшаш яңгырашлы сүзләр, рифма һәм шигырь турында төшенчә);
- 2 сыйныф - ”Кызык һәм көлкеле хәлләр” бүлегендә “ Көзге каршында”, “Тамаша” шигырьләре(әсәрдә капма-каршылык-контраст турында төшенчә);

- 4 сыйныфта  “Туган як” шигыре.;
- 7 сыйныфта “Уйна әле” хикәясе;
- 11 сыйнйыфта 1980-2000 еллар  шигъриятенә гомуми күзәтү ясаганда гына исеме аталып үтә ( ни кызганыч!).

Рус мәктәпләренең татар төркеме өчен төзелгән программада “Җиңәсем килде”, “Нигез” хикәяләре, “Су буеннан әнкәй кайтып килә” шигыре (җыр) өйрәнелә.

Дәрес саны аз булуны сәбәп итеп, әдипнең иҗатын өстән генә өйрәнергә ярамый. Дәрестән тыш эшчәнлектә әдипнең күпкырлы иҗатын өйрәнүне максат итеп куям.Әдипнең иҗатын тематикага бүлеп, укучылар төркемнәрдә өйрәнеп һәм чыгыш ясарга әзерләнәләр.

5-11 нче сыйныфлар өчен дәрестән тыш чара эшкәртмәсен тәкъдим итәм.

*Максат*:Укучыларны Марсель Галиевның тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру; иҗаты һәм шәхесе  аша тарихи үткәнебезгә, әдәбиятыбызга кызыксыну, ихтирам тәрбияләү; туган телнең, туган нигезнең кадерен белергә өйрәтү; сәнгатьле сөйләм күнекмәләре үстерү.

*Җиһазлау:* Әдипнең портреты, китап күргәзмәсе, Х.Бигичев башкаруында “Кайту” , Айдар Фәйзрахманов  башкаруында “Су буеннан әнкәй кайтып килә” җырының аудиоязмасы, “Нигез” хикәясе өчен фон-аудиоязма, Ноубук, экран, кичә барышы эчтәлеген чагылдырган презентация.

“Татар теле камил һәм бай тел. Әмма без океан уртасындагы утрау кебек. Чит телләрдән саклау өчен без калька сүзләрне тәнкыйть утында тотарга тиеш”, “Милләтне саклап калу өчен халыкның бөеклеген тану рухы булырга тиеш”. “Безнең сандыкны ачып, телнең төбенә төшеп караган юк” дип язылган плакатлар.

**Укытучының кереш сүзе.**

“Миндә татар йөрәге тибә… Татар-барча континентларга таралган дөньяви халык. Татар-нинди яңгыравыклы исем! Пышылдап кына әйтсәң дә тантаналы яңгырап кала. Бу сүздә космик куәт сулышы тоенләнгән. Ә син, милләттәшем, йөртергә хаклымы шундый да шәүкәтле исемне?! Дөнья картасында үз тамгаларын таш-мәрмәргә уеп калдырган бөек халыкның тарихын аң-вөҗүденә сыйдыра аласыңмы?” ( “Шанлы исем”, М.Галиев “Әсәрләр” 2 том, 318- 322 битләр).

Әлеге фикернең авторы Марсель Галиев. Кем соң ул? Татар халкының тарихи үткәне, бүгенгесе белән нинди бәйләнеше бар?

Марсель Галиев-татар халкының язмышы, тарихы, бүгенгесе, теле, әдәбияты, мәдәнияты, хәтта мәзәге турында фәлсәфи фикер йөртүче әдип. Аның житди, катлаулы, телгә бай иҗаты һәр татар баласына таныш булырга, өйрә-нелергә тиеш дип саныйм.  Кадерле укучыларым, без бүген “Каләм очында-галәм” дип исемләнгән әдәби кичәгә шушы олы шәхес һәм аның иҗаты белән танышырга җыелдык.

**Беренче укучы**.  Марсель Галиев әсәрләре тема һәм жанр ягыннан бик бай. Аның шигъри тәлгәшләрендә, проза әсәрләрендә дөнья матурлыгы, якынна-рына мәхәббәт, динебезгә һәм туган ягыбызга, тарихыбызга, телебезгә чиксез хөрмәт чагыла. Аның лирикасында туган як темасы әйдәп баручы темалар-ның берсе булып тора.

Лирик герой өчен туган як яме тормыштагы һәрнәрсәдән өстен: “ Әкияттәге кебек: тарак ташласаң-урман калка, күзге ыргытсаң-күл хасил була, тыл-сымлы авазыңнан  таулар ярала безнең якларда”. Аның туып-үскән ягында гына “

йолдызлар тәлгәш-тәлгәш сибелә", "таулары ап- ак яллы болытларны тышаулый", "абагалары чәчәк ата", "суларында кояш йөзә", "күкеләре меңгә кадәр саный". Гипербола, сынландыру алымнары аша лирик геройның сокла-ну хисе үстерелә.

"Туган як"шигыре укыла. .

**Икенче укучы.** Танылган әдип-шагыйрь, прозаик һәм драматург Марсель Баян улы Галиев 1946 елның 8 октябрендә Татарстан Республикасы Азнакай районы Балтач авылында игенче гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч мәк-тәпне туган авылында, сигезенче сыйныфны шул ук районадагы Туйкә авылы мәктәбендә, унберне исә 1964 елда Азнакайның 1 нче номерлы урта мәктә-бендә укып тәмамлый.Гаскәри хезмәткә алынганчы бер ел Азнакайдагы төзе-леш оешмасында (СМУ-29) рәссам-бизәүче булып эшли.

Р.Асаев башкаруында "Туган җир кадере" җыры.

**Өченче укучы.*М.Галиев "Чатыр тау")***

Ерактан ул – зәңгәр пирамида,
чал Уралның соңгы дулкыны.
Иңнәренә ятып оеп кала
төньяк җилләренең салкыны.
Җил йомгагы булып кылганнары
үзәннәргә таба йөгерә.
Кайнап аккан ак болытлар аша
тау кояшка гүя үрелә.
Ә төннәрен чума офыкларга,
син ерактан карап тор гына;

Алма кебек өзелә дә күктән
тауга йолдыз тама тын гына.
Куакларда әле төн кунаклый,
тау башында инде яңа таң.
Саумы, диеп дәшәм еллар аша,
күңелдәге сынын яңартам.
Якынлашкан саен ерагая,
төшләреңдә күпме чакырма;
Мин ачмаган гаҗәп әкият калган
мәгарәле зәңгәр Чатырда!

**Дүртенче укучы**. Армиядә чагында (1965–1968) Пермь шәһәрендә кече авиабелгечләр әзерли торган берьеллык хәрби мәктәпне бетереп, хезмәтен Белоруссиянең Бобруйск шәһәрендә, дивизия штабында дәвам иттерә. Гаскә-ри хезмәт мөддәтен тутырып кайткач, М.Галиев 1969 елда Казан дәүләт университетының журналистика факультетына укырга керә..

***Марсель Галиевның "Туган тел" шигырен үзе башкаруында тыңлау.***

**Бишенче укучы**.Укуын тәмамлагач, 1974 елдан 1979 елга кадәр Татарстан Язучылар берлегенең матур әдәбиятны пропагандалау бюросында эшли, аннан соң өч елга якын «Казан утлары» журналының проза бүлеген җитәкли. 1982–1984 елларда М.Галиев Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институтының икееллык Югары әдәби курсларында белемен арттыра.

Шагыйрьлек "җене" кагылу , хыялый алдану бәхете күпләргә бирелмәгән. Әмма һәр милләтнең күз карасыдай чын шагыйрьләре гасырдан гасырга бөртекләп кенә туадыр.Ул халык бәгыреннән янартаудан бәреп чыга да, билгеле бер көйгә салынган аң-зиһен гамәлен җимереп, тирә-юньне күмеп китә. Бу гарасатлы көч тынгач кына, аның никадәр олылык иясе икәнен тора- тора аңлый барасың.

( "Шигърият рухы", М.Галиев "Әсәрләр" 2 том, 324 бит).

**Алтынчы укучы.** Марсель Галиев, нигездә, поэзия һәм проза жанрларында иҗат итә. Матбугатта беренче шигырьләре һәм хикәяләре үткән гасырның җитмешенче елларында күренә башлый.

*"Марсель Гали шигырьләренә тулы бер дөнья-Иделле, карагайлы, йолдызлы, алсу таңлы, кояшлы дөнья сыйган. Рәсем сәнгате белән шөгыльләнүче шәхес буларак, ул төсләр балкышын үз поэзиясеннә җыя алган.*

*Туган ягын сурәтләгәндә ул хыялый бер үсмер, ялларын тузгытып далада чапкан кырыкмыш тай, беренче саф мәхәббәте кабынган гашыйк, туган җиренең гази баласы.Көтелмәгән эпитетлар, сынландырулар, ашкын хисле саба җиле гүзәл әкият булып тора аның туган ягына багышланган нәсерлә-рендә”*,-дип яза Татарстаннаң халык язучысы Гариф Ахунов.

Бер төркем шигъри әсәрләре 1970 елда яшь шагыйрьләрнең күмәк җыенты-гына («Беренче карлыгачлар») кертелә, ә 1979 елда «Еллар чалымы» исеме белән шигырьләре тупланган мөстәкыйль җыентыгы, 1980 елда ике лирик повестен һәм хикәяләрен эченә алган «Ул чакта» исемле проза китабы дөнья күрә. Бу җыентыклар икесе дә әдәби тәнкыйть һәм укучылар тарафыннан уңай бәяләнә. Беренче китапларыннан соң узган өч дистә еллар дәвамында әдипнең иҗат активлыгы, бигрәк тә проза өлкәсендә, арткannан-арта бара. Аның кеше җаны-рухындагы тирән уй-хис тирбәлешләрен заман, туган җир, туган табигать һәм тарихи хәтер белән бәйләп, тормыш вакыйгаларын югары сәнгать кимәлендә калку итеп гәүдәләндергән «Ерак урман авазы» романы, «Ак абагалар», «Нигез», «Алтын тотка» кебек лирик повестьлары һәм хикәяләре ике гасыр арасы татар интеллектуаль прозасының яңа бер казанышы итеп бәяләнергә хаклы. Туган якны сагыну, аның матурлыгына соклану, аның белән горурлану Марсель Галиев әсәрләрендә кызыл җеп булып сузылган. “*Кешеләр генәме, сулар да бит туган ягына кире кайта. Диңгезгә барып җиткән чишмә сулары, парга әйләнеп, болыт хасил итәләр дә, яңгыр булып, туган якка кайтып явалар. Табигатьнең ашкыну белән сагыну арасындагы мәңгелек бәйләнеше...*” – дип яза ул “Нигез” повестенда.

**Җиденче укучы**.***“Нигез” хикәясеннән өзек.***

*Сугыш бетеп, бер ел үткәч, Алтын Болак авылы кешеләре матур бер гадәт уйлап чыгарды. Хатын-кызлар, яудан кайткан ир-атлар Җиңү көнендә Өянке янына җыела. Шушыннан киткәннәр бит алар, шушыннан озатып калганнар бит аларны… Ирләре һәлак булган хатыннар, эчке бер өмет белән, үзләре чиккән кульяулыкларны Өянке ботакларына элделәр. Алардан соң, вәгъдәләр куешкан егетләре кайтмый калган кызлар, кульяулык тотып, Өянке янына килделәр. Күзләр яшьләнде. Китте хатирәләр.*

*Авылдан чыгып киткән йөз унике ир-егет кире әйләнеп кайтмады. Ә Өянке ботакларында алар истәлегенә төрле җепләр белән чигелгән йөз унбер кульяулык җилферди. Бер кульяулык… әлегә эленмәгән… Нәзифә кулында. Җиңү көнендә ул урамга чыга алмый. Өянке янына җыелган халыкны койма ярыгыннан гына күзәтә. Төне буе чиккән кульяулыгы күз яшенә чыланган. Аның да кешеләр арасында буласы, кульяулыкны бергә эләсе килә. Әмма ире Хикмәтулла турында, немецларга сатылган, үзе теләп пленга төшкән икән, дигән хәбәр бөтен авылга таралган.*

*Караңгы төшкәч, курка-курка гына басып, Нәзифә Өянке янына килә. Калтыранган куллары белән кульяулыгын бәйли.*

*Әлегә Өянкенең ботакларында таң җилендә йөз унике кульяулык җилферди. Йөз унике язмыш… Тумый калган күпме бала… Салынмый калган күпме нигез… Җырланмый калган күпме җыр…*

*Сугыш яралары төзәлә барган саен, Өянке ботакларына Җиңү көнендә эленгән кульяулыклар саны да елдан-ел кими башлады.*

*Өянке басу юлына күз салды. Кара пинжәк кигән, күн чемодан тоткан ят бер кеше авылга якынлашып килә иде. Тирә-юньне күзләп, ашыга-ашыга атлый.*

*Байтирәкләр турына җиткәч туктады, койма аша үрелеп карады да чемоданын куеп йөткереп алды. Шулчакта капкадан кулына йөгән тоткан Байтирәк килеп чыкты. Шунда ук таныды ул абыйсын. Тик…Нигәдер агары-нып китте дә, кеше күрмиме дигәндәй, югары оч ягына карап алды. Каушап калган Байтирәк капканы эчтән шартлатып япты да тынычлана алмыйча:*
*Кеше күзенә ничек күренерсең икән?! Ник кайттың? — диде, ачуына буылып.*

*Туган авылына кайтып җиткәч… чит җирләрдән исән-имин алып кайткан өметен бертуганы рәхимсез рәвештә салып таптавын күргәч… сыгылды да төште Хикмәтулла. Аның күз алдында кара күләгәләр биеште. Чайкалып, койма тактасына тотынды. Туган җир туфрагына баскач, әллә нәрсә булды. Каршыдагы Өянке, урам, өйләр, йөзтүбән әйләнеп, керфекләре арасында калтырый башлады. Күз яшьләре, тәгәрәп, сукмакка төште дә челпәрәмә килде. Ул, таяныч эзләгәндәй, моннан ун ел элек хушлашып калган өйләргә, таныш капкаларга карады. Барысы да нәкъ шул чактагы сыман, берни дә үзгәрмәгән кебек.*

*Хикмәтулла, ашыга-ашыга, үз өенә таба атлады.Нәзифәнең күзләрендә бер генә тамчы икеләнү-шикләнү чагылып алса да, кире борылачак. Әсирлектә булганнарга нинди караш икәнлеген белә иде ул.*

*Бусагага чыккан Нәзифә кисәк утлы һава сулагандай булды. Аяк астын-дагы баскычны тоймыйча атлап егыла башлаган хатынын Хикмәтулла чак тотып калды.*

*Авыл өстенә төн иңгәч, алар туйганчы сөйләшергә-серләшергә Өянке янына килделәр. Күбрәк Нәзифә сөйләде. Хикмәтулла үзе кичергәннәрне сөйләргә әзер түгел иде.*

*Сугышның икенче елында ук әсирлеккә эләккән солдат җаны коллыкны күтәрә алмады. Иң авыр минутларында авылын, шушы Өянке янында озатып калган Нәзифәсен уйлап юана иде.*

*Өянке үз күләгәсенә карап утыра. Янәшәсендә кешеләр сөйләшкәнне тыңлау рәхәт аңа.*

*Олы юлдан чыгып киткәннәрне сагына, кайтып кергәннәр өчен сөенә белә бит ул да. Әгәр урыныннан куба алса, кунак кайтасы өйнең тәрәзәсен шакып, иң беренче ул сөенче алыр иде.*

**Сигезенче укучы.** М.Галиевнең юмор-сатира жанрында (“Кәефең шәпме?”, “Арыслан йокысы” җыентыклары), балалар әдәбияты (“Ак рәсем”, “Шүрәле һәм җил” исемле шигъри җыентыклар, “Җиңәсем килде” исемле нәни хикәяләр җыентыгы), драматургия, әдәби тәрҗемә һәм җыр текстлары иҗат итү өлкәләрендә дә үзенчәлекле уңышлары бар.

***Сез дә ышанырсыз!***

*Көн салкын. Сыкы тузаны –*
*ява вак кына бөртек.*
*Марат белән безнең өйгә*
*Имән утыны керттек.*
*Ә Маратлар өенә без*
*Керттек нарат утыны.*
*Ишек ачкач, уйнап торды*
*кышның салкын ак тыны.*
*Икебезнең дә әниләр*
*калдылар ягып мичкә,*
*Ә без киттек тау шуарга, -*
*Коймак өлгерер кичкә.*
*Бервакыт таудан күз салсак...*
*“Я, ни булды?” диярсез,*
*Әйтсәк, ышанмассыз , көлеп*
*малайларга сөйләрсез.*
*Тау башыннан хәйран калып*
*сүзсез торабыз карап:*

*Маратларның морҗасыннан*
*Үсеп чыккан дәү нарат!*
*Ә безнең морҗа турында*
*Тармакланган дәү имән –*
*Очы күкләргә тигән!*

*Зәңгәр нарат, зәңгәр имән*
*Бик мәһабәт үсә дә...*
*Төтен булып таралмасмы,*
*Әз генә җил иссә дә?*

**Тугызынчы укучы.**

***Танышу нидән башлана?***

*Ни генә юк бу чормада:*
*Иске урак дисеңме,*
*Чабагачлар, шүре, киле –*
*Бар да серле исемле.*
*Бабайлардан калган әйбер*
*Почмакларга өелгән.*
*Тузаннарын кагып алам –*
*Танышам мин өй белән.*
*Ни генә юк авылымда:*
*Тәмле чишмә сулары,*
*Кәҗә сукмагыннан менсәң,*
*Җил сызгырта таулары.*

*Каен урманына кадәр*
*Күпме өйләр тезелгән.*
*Санап чыгам морҗаларын –*
*Танышам авыл белән.*
*Бормалы юллардан китеп,*
*Ил буйлап йөрсәң иде,*
*Диңгез, таулар һәм тайгалар,*
*Шәһәрләр күрсәң иде.*
*Серләр челтәреннән торган*
*Картага мин иеләм,*
*Үсеп җиткәч, дөнья гизеп,*
*Танышырмын ил белән.*

**Укытучы**. Шагыйрьнең «Су буеннан әнкәй кайтып килә», «Көзге моң», «Кайту» кебек җырлары, халыкның күңел моңына әверелеп, бөтен татар галәменә таралган. Хәйдәр Бигичев башкаруында “Кайту” җырының аудиоязмасын тыңлау.

*“Кайту”*

*Олы юлдан яуга киткән чакта*
*Таң җиленнән томан таралды.*
*Авыл башындагы куш наратка*
*Атлар да бит борылып карады.*
*Һаваларда торна тавышлары,*
*Ишетелә канат кагышлары.*
*Кошларда да кеше язмышлары,*
*Чит җирләргә китеп барышлары.*
*Туган якның хәбәрләрен белдек*
*Ызаннардан искән җилләрдән.*
*Күпләребез олы юлдан кире*
*Кайталмады ерак илләрдән.*
*Һаваларда торна тавышлары,*
*Ишетелә канат кагышлары.*
*Кошларда да кеше язмышлары,*
*Чит җирләрдән кайтып барышлары.*

**Унынчы укучы чыгышы**.(“Галибанә моң”, М.Галиев “Әсәрләр” 2 том, 297-298 битләр).

*Татар җырында –*

*Биек диварлар белән чикләнгән Күк асты иле – борынгы кытай халыкларына күчкән ефәктәй нәфис көй борылмалары бар!*

*Татар җырында –*

*Күз нурлары аша алтын-көмешкә җан эретеп, курганнар йөрәгендә искиткеч җәүһәрләр калдырган скиф осталарының тылсымлы сулышы бар!*

*Татар җырында –*

*Алтай-Саян төбәгеннән кайнап чыгып, гасырлар аша килә-килә, Цезарьләр шәһәре – Римгә кадәрге ераклыкларны тояк тетрәүләре белән уяткан Атилла һуннарының тантанасы бар!*

*Татар җырында –*

*Алтын Урданың җилгә изүен аскан балбаллы далаларында Идегәйдән илсез калган мосафир-кыпчаклар яккан учакларның әрнүле күмер пышылдаулары бар!*

*Татар җырында – Идел карамаларыннан алып малахит Урал сыртлары аша Себер карагайларына кадәрге киңлектә дәрья булып шаулаган кара урманнарның гөнаһсыз-шомлы тирәнлеге бар!*

*Укытучы.Татар җырын Марсель Галиев менә ничек бәяли.Ә бүген татар җыры ни дәрәҗәдә соң?*

*Марсель ага үзенең "Карак такмакчыларга тукмак кирәк!" язмасында җыр һәм композитор, җырчылар турында түбәндәге фикерләрен белдерә:*

*"Бүгенге эстрадада алабута-кычыткannan башлап кәҗә сакалына кадәр җырлап чыктылар да, берсен-берсе уздырып, туган көн темасына тотын-дылар. Әнкә итәгеннән төшә алмау, "Нигә елыйсың, әнкәй?" – дип читтән торып кайгырту – эстраданың озакка сузылган чире булып калыр, ахрысы."...*

*"Җырны бар иткән дә-сүз , җырны хур иткән дә-сүз...Әйе, сүз- җырның умыртка баганасы. Көй-җырның рухи җаны. Моңлы тавыш-җырны бишегеннән алып, тәпи бастырып, дөньяга таратучы илаһи көч. Шушы өч кодрәт иясе-шагыйрь, композитор, җырчы-сәләт ягыннан югары кимәлдә тәңгәл килгәндә генә мөкәммәл җыр туа".*

Әйдәгез хәзер Марсель Галиевның танылган композитор Луиза-Батыр Болгари көенә язылган "Су буеннан әнкәй кайтып килә" җырын Айдар Фәйзрахманов язмасында тыңлыйк.

Су буеннан әнкәй кайтып килә.

*Су буеннан әнкәй кайтып килә,*
*Каз каурые алган кулына.*
*Чәчләренә, җылы карлар булып,*
*Тал мамыгы ява тын гына.*
*Хәтерлиме әнкәй күпме еллар*
*Шушы сукмаклардан узганын?*
*Эзләп төште микән сагынып ул*
*Чишмәдән су алган кыз чагын?..*

*Шул чакларга алып китәр сыман —*
*Атлар уйнап чаба үзәннән.*
*Туган җирләр әнкәй белән бергә*
*Бик үзгәргән инде, үзгәргән.*
*Су буеннан әнкәй кайтып килә,*
*Каз каурые алган кулына.*
*Эзләренә, җылы карлар булып,*
*Тал мамыгы ява тын гына…*

**Унберенче укучы**. Әдипнең «Исемсез утрауда» драмасы 1983 елда Минзә-лә татар драма театры, «Әлегә соң түгел» драмасы 1985 елда Татарстан Күчмә театры (хәзерге К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры) сәхнәләрендә куела.

Марсель Хәким улы Сәлимҗанов-мәшһүр татар режиссеры, СССР халык артисты, РФ һәм ТАССРның атказанган сәнгать хезмәткәре СССРның халык артисты, РФ һәм ТАССРның атказанган сәнгать хезмәткәре, Г.Тукай һәм К.С. Станиславский исемендәге Дәүләт премияләре, «Алтын битлек» премиясе лауреаты.Чыгышы белән Әтнә ягыннан, әтисе Хәким Сәлимҗанов Бәрәскә авылыннан.Шуңа күрә:"Театрның йөрәге-Бәрәскәдә!" - диләр.

"Хаким" (Ил эчендә ил ул – театр) *МарсельСәлимҗановка.*

Ул – Чыңгыз хан иде сәнгатендә,
Йөз-кыяфәт шундый чалымнан.
Юкка гына кылыч уйнатмаган, -
Сәхнә женле малай чагыннан.
Ил эчендә үзе бер ил кебек
Театрга халык агыла.

Сүз сәнгате мәйдан тоткан илнең
Ул ханы да иде, даны да.
Мут күзләрен кысып, ул күзәтте
Сәхнә белән милләт арасын.
Нинди җепләр бәйли, йөрәк аша,
Бу дөньяның агын, карасын.

Сак тәвәккәл иде.Тәхетләлгә
Абынмады, артык кабынып.
Бөкреләрнең сынын турайтам дип,
Сүнгән йолдызларны кабызып,

Яшәде ул!Аның әмереннән
Кыйбла якка сәхнә әйләнде;
Утырып уйлау хәтәр чорда сәхнә
Хәрәкәткә күбрәк көйләнде.

**Укытучы.**Марсель Галиев шигырьләре... Алар әллә ничекләр итеп җанны актара, рәхәт бер халәттә тибрәтә. Күз алдында төсләр, матур сурәт-картина. Хисләр бии... Аның теле, стиле, аһәңнәре үзенә бертөрле, беркемнекенә охшамаган: затлы, нәзберек, нәфис. Шагыйрьлек җене, хыялый алдану бәхете... Иҗатына бәяләмәне дә шагыйрьнең үз сүзләре белән кабатлыйсы килә.

"Сүз өзелә күңел тәлгәшеннән..."

"Шигырь-мәңгелек упкынында тирбәлгән күңел бишеге..."

"Шагыйрь-Күк белән Җир арадашчысы!"

***М.Галиев " Бәгырь авазы". Илдус Әхмәтҗанов башкара.***

**Уникенче укучы**.М.Галиевнең туксанынчы еллардан башлап матбугатта өлешләп басыла килгән һәм 1998 елда аерым китап булып нәшер ителгән «Догалы еллар» исемле сәнгати-публицистик әсәре язучының күңел дөнь-ясын-уй-гамьнәрен, әрнү-шатлыкларын, өмет-кичерешләрен, заманның һәм үткәннең тарихи вакыйгалары фонында күренекле шәхесләрнең, үз чордаш-ларының җанлы портретларын шагыйранә бәян итә. Бу китап фәлсәфи-фикри тирәнлеге, эчтәлегенең тематик колачы белән татар мемуар жанры әдәбиятын да үзенчәлекле бер яңалык булып тора. 1998 елда «Татнефть»нең «Рухият» яңарыш фонды оештырган әдәби конкурста «Догалы еллар» әсәре беренче дәрәҗә дипломга лаек була. Әдипнең төрле елларда үткәрелгән иң яхшы балалар җыры, иң яхшы юмористик хикәя, иң яхшы публицистик әсәрне билгеләү ярышларында да җиңүче булганы бар.

**Унөченче укучы**. 2005 елда Татарстан китап нәшриятында әдипнең «Рух» исемендә яңа китабы басылып чыга. Аны шулай ук эчтәлеге һәм язылуы-стиле буенча «Догалы еллар»ның дәвамы дип карарга мөмкин.

"Рух - милләтнең фидаи җаны, максатлы омтылышы, үзеннән югарырак сикерә алу мөмкинлеге. Рухи кодрәт ул-бөгелгәндә дә бөгелмәү, егылганда да егылмау, чигенгәндә дә чигенмичә яшәү тантанасы.

Үз милләтеннән ваз кичеп, бүтән тамырга ялганган нәсел язмышын күзалла.
Беренче буында тел бетә. Моң, хәтер кала.
Икенче буында моң бетә. Хәтер кала.
Өченче буында инде хәтер дә бетә.
Тамчылап-тамчылап саега тел дәрьясы.
Өзелеп-өзелеп югала моң тылсымы.
Ялкыннарда бии-бии сүнә хәтер.
Берәмләп-берәмләп ава халык урманы.
Тел, Моң, Хәтер - рухның таяныч нигезе". Марсель Галиев. Рух. 45 нче бит

**Укытучы.** М.Галиевнең "Учымда-тургай шәүләсе" исемле шигырьләр китабы, публицистик язмалары туплап бирелгән «Талисман» исемле җыентыгы да әдәбият сөючеләр тарафыннан җылы кабул ителде. Әдипнең аерым әсәрләре рус, поляк, украин, үзбәк, казакъ, каракалпак, осетин, чуаш телләренә тәрҗемә ителә. 1993 елдан М.Галиев «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем йөртә, ә 1996 елда татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткәне өчен Татарстан

Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев Указы нигезендә Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнә. 2006 елда ул Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. М.Галиев – 1979 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

Укучылар, менә без Марсель Галиев иҗаты белән танышып үттек.Аның каләме очлы, иҗаты-очсыз-кырыйсыз галәме. Бер кичәдә генә иҗатын өйрәнеп тә, бәя биреп тә бетереп булмый. Шулай да аның иҗатына татар һәм башкорт әдәбиятының олпат язучыларың тәнкыйть фикерләренең берничәсе белән таныштырып үтәм.

*“Марсель Галиев-бу дөньяның, тормышның яңа якларын ача белүе һәм күргәненә карата үзенең мөнәсәбәте, саф фикере булуы белән ул башкалардан нык аерыла һәм шуңа күрә кызыксыну уята. Кызыксыну уята алу-бик мөһим мәсьәлә.Такташ шундый булды:аның һәр язганын нәрсә әйтә, нинди яңа сүз алып килә, дип көтеп алалар иде.Әсәрләре белән кызыксыну уята алган Марсель Галиев безнең әдәбиятта үзенә аерым урын тота”. Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еники.*

*“Аның ярсулы да, акыллы да, моңсу да, чәнечкеле дә, ягымлы да таланты минем күз алдымда үсә, ныгый, халык күңелендә тамырлана барды. Шигърияте татар поэзиясенә күркәм бер күренеш булса, прозадагы һәм публицистикадагы иҗаты аерым бәягә хаклы. Нәрсә турында гына язмасын ул чәчкән бәрәкәтле орлыклардан игелекле үсентеләр баш төртеп чыга... Марсель Галиев шигырьләрен укыганда мин шуны тоям:*

*Күңелләрдә-кошлар тавышы,*
*Зиһеннәрдә-заман язмышы”. Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәрим.*

Укучылар, туган җиребезне яратыйк, тарихыбызны өйрәник, телебезне саклыйк, горур халык булып яшик. дигән

## Марсель Галиев иҗатында туган як темасы

*Сиразиева Зарина, 6 класс, Казан шәһәре*
*“43 нче урта гомуми белем мәктәбе”*
*Җитәкче:Баһавиева Лилия Данис кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Туган җир! Һәрбер кеше өчен нинди газиз, кадерле, тирән мәгънәле сүзләр! Туган җир дигәч тә, туып-үскән нигез, туган туфрак, иксез-чиксез иркен болыннар, туган якның гүзәл табигате күз алдына килеп баса.

Туган ил! Туган җир! Туган туфрак! Туган җир кешеләре! Туган як табигате! Болар-шагыйрь иҗатының төп темалары. Күп кенә язучылар, шагыйрьләр үз иҗатларында туган як темасын чагылдыралар. М.Галиевның иҗатында туган як темасы зур урын алып тора. Ватанына булган мәхәббәтен үзенең иҗаты аша укучыларына җиткерә. Үзенең иҗаты белән туган илне яратырга, аны сакларга, күңел белән тоемлый белергә өнди.

Фәнни-тикшеренү эше атар шагыйре, язучы, Г. Тукай исемендәге Татарстан дәүләт премиясе лауреаты. Татарстанның халык язучысы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Марсель Баян улы Галиевка багышланды.

Марсель Галиев иҗатын тирәнтен өйрәнү һәм аның иҗатында туган як темасының чагылышын күзәтү максатыннан чыгып башкарылды.Сайлап алынган темам бүгенге көндә дә актуаль.

**Эшемнең максаты :**М.Галиевның күпкырлы эшчәнлеген билгеләү

**Эшемнең бурычлары:**

1. М.Галиевның хезмәтләре белән танышу;
2. Әдип иҗатында туган як темасының чагылышын күзәтү;

Тикшерү өчен М.Галиевның “Туган як” , “Танышу нидән башлана”, “Шәһәрдә нәүмиз хәтер” , “Китү”, “Кайту”, “Актүбә чишмәләре” , “Туган як тургае” , “Ераклыклар җиле” шигырьләре алынды.

Марсель Галиевнең **„Туган як”** шигыре матур Азнакай төбәгенә багышланган. Лирик герой өчен туган як яме тормыштагы һәрнәрсәдән өстен. Аның туып- үскән ягында гына „йолдызлар тәлгәш-тәлгәш сибелә”, „таулары ап-ак яллы болытларны тышаулый”, „абагалары чәчәк ата”, „суларында кояш йөзә”,. „күкеләре меңгә кадәр саный” . Гипербола-арттыру , сынландыру алымнары аша лирик геройның соклану хисе үстерелә. Шигырьнең беренче строфасы болай яңгырый:

Шундый як ул, карагыз сез
минем туган җиремә,
йолдызлар хәтта кызыгып
тәлгәш – тәлгәш сибелә.

Автор соңгы строфада үзенең яшәгән урынын сер итеп кенә укучыларга җиткерә.

Ышанмыйча сез сорарсыз:
Чынлап, андый җир кайда?
Сер итеп әйтәм алайса:
Аз-на-кай-да!... Шагыйрь шулкадәр җылы итеп, сокланып үз туган ягы турында гына яза ала.

Автор **„Танышу нидән башлана?”** шигырендә туган авылын мактый. Аның кешеләре дә гадирак, суы да тәмлерәк, таңы да матуррак, һавасы да сафрак.

Ни генә юк авылымда
тәмле чишмә сулары,
кәҗә сукмагыннан менсәң
җил сызгыра таулары.

Аның бу шигырен укыганда синең алдыңда чылтырап аккан чишмәләре, биек таулары белән бөтен бер дөнья ачыла.

**„Шәһәрдә нәүмиз хәтер”** шигыренә игътибар итик. Бу әсәрендә шагыйребез үзенең туган авылын, анда үткән бала һәм үсмер чагын сагынуын гап- гади генә, әмма бик үтемле итеп тасвирлый. Бу шигырьне без туган нигезен сагынуның югары дәрәҗәдәге үрнәге, дип әйтә алабыз. Аны, әлбәттә, хәтерендә калган авыл чишмәсе төбендәге чуерташлар , тегермән, тәмле алмалар сагындыра. Ул уендашларын, сугыш кичкән агайларны сагына. Аның хәтерендә ат җигәргә өйрәнүләр, аулагыйлар, кунак кызлары, ул чорның ярлылыгы һәм бай күңеле. „Туган ягын сурәтләгәндә ул хыялый бер үсмер, ялларын тузгытып далада чапкан кырыкмыш тай, беренче саф мәхәббәте кабынган гашыйк, туган җиренең газиз баласы сыман! Гаҗәеп эпитетлар, сынландырулар, ашкын хисләр тулып тора аның туган әсәрләрендә. Миңа калса, Марсель туган җирен, Азнакай буйларын, җир өстеннән генә түгел, кошлар очар биеклектән күзәтә”, - дип яза Гариф Ахунов.

**„Булсин иде”** шигырендә ул авылын ни өчен сагынып кайтуын антитеза сурәтләү чарасы ярдәмендә аңлата. „Зур шәһәрдә яшел болыннар, киң кырлар, көтүдән юашланып кайткан сыерлар, балыклы инешләр булса, мин авылны сагынып кайтмас идем”-, дип яза. М.Галиевның лирик герое-шәһәрләшеп килүче кичәге авыл

кешесе.Ул каршылыклы хисләр, уйлар иясе, авылны онытa алмау- аның үзенчәлекле сыйфаты. Лирик герой шәһәрдә яши, ләкин авылын, туганнарын, урманнар, чишмәләр, тауларны сагынып яши. Һәм шул ук минутта ул авылга бөтенләйгә кайтмаячак инде. **„Китү”** һәм **„Кайту”** шигырьләрендә автор геройның катлаулы рухи халәтен, каршылыклы күңел дөньясын бик тәэсирле итеп сурәтли. Туган җирдән киткәндә аның күңелендәге аерылу, үкенеч, чарасызлык хисләре, аңа кайткан вакытта рәхәтлек, шатлык, канәгатьләнү хисләре белән алышына.

**„Актүбә чишмәләре”** шигырендә сагышлы юлларның кабатлануы шигырьнең тәэсирлелеген арттыра, сагыну хисен тагын да көчәйтә. Шагыйрь туган ягына ашкына, аңа мәдхия җырлый.

**„Туган як тургае”** шигырендә ул туып-үскән җирендә генә бәхет тәмен белгәнен яза, аңа язу өчен илһамны туган ягы бирә. Туып-үскән нигез кеше күңеленә моң сала, аны канатлы, илаһи итә, яшәүгә көч өсти, онытылмас моң булып озатып йөри. Анда аны газиз әткәе белән әнкәе көтә.

Бәхет тәмен беләм
туган җирдә генә,
иген кырларына күмеләм.

Монда – гомер юлым,
монда – туган моңым,
тургай булып җырлый күңелем.

Бу нәфис яңгыраучы юлларда горурлану белән баетылган шатлык- сөенеч тасвирлана.

**„Ераклыклар җиле”** шигыренә игътибар итек:

Туган якның бүресе дә якын
бөкресе дә гарип тоелмыйдыр,
Җыры тынмас салкын чишмәләрнең
Суын эчеп кенә туелмыйдыр.

Шагыйрь туган ягын җаны-тәне белән яратмаса, мондый юлларны яза алыр идеме?

М.Галиев үз шигырьләрендә балачактан күңелендә калган хатирәләрен яңартып, инде олыгайгач, уйландырган уйларын да язган. Аның әсәрләренә авторның йөрәге аша үтеп, шигырь юлларына әверелгән кичерешләр дәрьясы, уйланулар сыйган.Аның әсәрләре аша һәркем туган якның ниндидер серле тарту көчен, сихри романтикасын тоя, шул хиснең чынлыгына, кеше өчен кадерле булуына ышана

Фәнни-тикшеренү эшен башкарганда түбәндәге нәтиҗәләр килеп чыга.

Марсель Галиевның иҗаты күпкырлы. Аның иҗатында туган як темасы зур урын алып тора. Ватанына булган мәхәббәтен үзенең иҗаты аша укучыларына җиткерә. Үзенең иҗаты белән туган илне яратырга, аны сакларга, күңел белән тоемлый белергә өнди. Чыннан да, заманалар нинди генә үзгәрмәсен, ил тарихында нинди генә вакыйгалар булмасын, туган илне ярату тойгысы, аңа файда китерү теләге һич кенә кимергә тиеш түгел. Марсель Галиевның туып- үскән ягы матурлыгын сурәтләп язган шигырьләре татар поэзиясенең иң уңышлы әсәрләре арасыннан урын алып тора. Аның иҗади мирасын ныклап өйрәнергә кирәк. Аның шигърияте әле күп кенә алдагы буыннарны уйландырачак, үзе белән хыял дөньясына, рухи кичерешләр дәрьясына алып керәчәк.

## Марсель Галиевның “Нигез”повестенда мифологик образларның яктыртылышы тора

*Усманова Ләйлә, 7 сыйныф, Казан шәһәре*
*Авиатөзелеш районының 37нче рус гимназиясе*

Хезмәтемнең актуальлеге булып повестьта мифологик образларны билгеләү, аларны башка халык мифологиясе белән чагыштыру.

Эшемнең максатлары: повестьтан мифологик образларны, мифологик символларны табу, аларны дөрес итеп билгеләү, башка халык мифологиясе белән аермаларын табу.

Эшемнең тикшерү объекты булып: кәҗә, ләкләк, өянке, кояш образлары тора.

Татар әдәбияты үзенең үсеш-үзгәреш тарихында мифлар белән үзенең бәйләнешен саклап килә. 20нче гасырда мифология белән әдәбият арасындагы бу бәйләнеш тагы да көчәя, тыгызлана. Мифологик сюжетларны һәм образларны әдәби әсәргә кертеп җибәрәләр, тормышны мифология белән үреп бирәләр, әсәрләренә бер төсмер өстиләр. Марсель Галиевнең әсәрләре беркемне дә битараф калдыра алмый. Чөнки Марсель абыйда берәүне дә кабатламаган үз язу стиле бар. Ул заманча фикерләве, сүз остасы буларак әдәбиятка килеп керә.

Әгәр дә игътибар белән укысаң, “Нигез” повестенда беренче карашка бернинди мифологик элементлар да күренми. “Нигез” повесте-күптөрле язмышларны бер ноктада туплаган әсәр.

Марсель Галиевның “Нигез” повесте татар авылының милли рухын, әниләргә булган мәхәббәтне һәм татар аналарының балаларын ничек тәрбияләвен күрсәтүче әсәр.

Мифологик элементлар дигәндә, мифологик символлар, образлар әсәр эчендә тикшерелеп, аларның әсәрне төзүдәге вазыйфаларын ачыклау тора. “Нигез” әсәре үзе миф буларак кабул ителә. Икенче төрле тормыш мифы дип атарга да була. Чөнки әсәрдә табигать күренешләре, хайваннар, хатирәләр-барысы да җанландырыла.

Әсәрнең нигезендә Өянке образы урын ала. Язучы Өянкене үзе үк баш хәреф белән бирә. Әсәрнең эчтәлегендә Өянке барлык вакыйгаларның үзәген тәшкил итә һәм мифологик символ буларак күптөрле мәгънәләрдә ачыла. Өянке әсәрдә хәтере булган җанлы образ итеп кенә түгел, ә “халык хәтере” дәрәҗәсенә җиткерелгән символик образ буларак тәшкил итә. Өянке агачы үткәнне ачыкларга ярдәм итә. Өянке хәтеренә сеңеп калган хатирәләр тормыштан алган кичерешләр, тәэсирләр рәвешендә тасвирлана.

Өянке символ буларак күптөрле мәгънәләргә ия. Беренчедән, ул-нигез символы, икенчедән, Өянке-ул кешедә яшәгән хәтер символы, өченчедән, Өянке-яшәеш, тормыш символы.

Образ-геройларның хис-кичерешләрен бирү, тулаем сурәтләнгән вакыйгаларны җанландыру өчен Табигать образлары сынландырып бирелә. Кояш образ дәрәҗәсенә җиткерелә. Борынгы кешеләр Кояш образын изгеләштергәннәр, аңа табынганнар. Әсәрдә Кояш образы барысын да хәрәкәткә китерүче буларак аңлашыла.

Кәҗә образы әкияти, мифологик персонаж дәрәҗәсенә күтәрелә. Песи белән дуслашуы, аны баласы урынына күрүе, ишекне келә бавын теше белән аска тартып,

стенага терәп куюы-үзе бер могҗиза. Кәҗәнең сакаллы булуын да автор үзенчә хикәяли. Автор кешелек дөньясына карап барысы да җиңел бирелсә, кеше яшәүнең тәмен татый алмас иде дигән фикер үткәрә. Мифологик образ буларак игътибар итү-аның "Алпамша" исемле кушаматында чагылыш таба. Төрки әдәбиятта таралган "Алпамша" дастанының исеме белән аваздаш. Алпамша мифологик образының кәҗә белән берниндиурта клыгы булмаса да, дастан герое белән охшаш яклары сизелә. Төрки әкиятләрдә (башкорт, үзбәк, казах, каракалпак халыкларында) Алпамша образы батыр, зур баһадир гәүдәле, ару-талуны, куркуны белми торган мифик образ дигәнне аңлата. Әсәрдәге кәҗә образы менә шундый сыйфатка ия булган мифик образ буларак килеп баса.

Ләкләк символы өянкегә бәйле рәвештә әсәргә килеп керә. Ләкләк-ул изгелек символы. Ләкләк теләсә нинди авылга туктап, агачка кунмый. Димәк, ләкләк кунган җир изге җир булып санала, ә Алтын Болак авылы-изге җир. Димәк, изгелек-бәхет, өмет, ышаныч символы. Кошны күргәч тә, һәр кеше үз телендә (татар кешесе татарча, рус балалары-русча, украин балалары-украинча) эндәшә һәм бу дуслык, бердәмлек символы буларак та аңлашыла ала. Хәзерге заманда ата-аналар балаларына яңа туган сабыйларны ләкләк китерә дип уйдырмалар уйлап чыгаралар. Борынгы заманнарда ук ләкләк образы изге кош булып саналган. Борынгы римнар ләкләкне яңа туган балаларны алып килә торган символ дип ышанып яшәгәннәр.

Шулай итеп, мифологик символлар әсәрнең үзәгенә мәңгелек, фәлсәфи төшенчәләренең үтеп керүенә ярдәм итәләр. Марсель абый Галиевнең "Нигез"әсәрендәге мифологик элементлар аермачык итеп сурәтләнми. Укучы әсәрне "Нигез" әсәре җиткерелгән төп фикерне уйлап бетерергә, ачыктан-ачык күрсәтелмәгән якларны таба белергә этәрә. Әсәр укучыны тормыш, яшәеш хакында яңа карашлар тудырырга, үзаңын үстерергә ярдәм итәр дип ышанасы килә.

## Марсель Галиевның "Рух" китабында парлы сүзләр

*Фазлыева Гөлфинә Нәшәт кызы, Азнакай шәһәре*
*7нче гомуми урта белем бирү мәктәбенең*
*теле һәм әдәбияты укытучысы*

Фәнни-гамәли эшем рус мәктәбендә татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучыларга һәм ана телен (татар телен) укытучы мөгаллимнәргә багышлана. **Фәнни-гамәли эшнең әһәмияте:** Рус телендә белем бирүче мәктәпләрнең татар төркемнәрендә укучы балаларның программа материалларын кабатлау һәм ныгыту вакытында Марсель Галиев иҗатына игътибарны арттыру.

Рус телендә белем бирүче мәктәпләрнең татар төркемнәрендә укучы балаларны олимдиадаларга әзерләгәндә 5-9 нчы сыйныфларда үткән программа материалларын кабатлау һәм ныгыту таләп ителә. Шушы максаттан чыгып, текст эченнән парлы сүзләрне табу, аларның ясалу төрләрен аңлату өстендә эшләү өчен Марсель Галиевның "Рух" китабын уңышлы кулланырга мөмкин. Синонимнарны өйрәнү, кабатлау вакытында берничә эш төренә тукталам.

-Парлы сүзләрне компонентларның лексик-семантик мөнәсәбәтләренә, кулланылыш өлкәсенә, грамматик формаларына карап төркемләү.

-Марсель Галиевның "Рух" исемле китабында кулланылган парлы сүзләрне табып, аларның ясалышына аңлатма бирү.

Татар телендә парлы сүзләрне компонентларның лексик-семантик мөнәсәбәтләренә карап төркемләү кабул ителгән һәм аларның өч төп тибы билгеләнгән: 1) синонимик: *көч-хәл, көч-куәт һ.б.* 2) антонимик: *көне-төне, яше-карты һ.б.* 3) гомумиләштереп күзаллауга бәйле ясалган парлы сүзләр: *ипи-тоз, аш-су һ.б.* [3: 42-43] Шулай ук парлы сүзләр компонентларның нинди кулланылыш өлкәсенә караулары буенча  (алынма сүз, архаиклашкан сүз) һәм аларның статусы, нинди грамматик формада килүләре буенча да төркемләнәләр: 1) һәр ике компонент та хәзерге телдә кулланыла торган мөстәкыйль сүз: *ата-ана, уен-көлке һ.б.* 2) парлы сүзнең бер компоненты (сирәгрәк икесе дә) алынма сүз: *кайгы-хәсрәт, мәкер-хәйлә һ.б.* 3) икенче компонент беренчесенең архаиклашкан варианты: *бала-чага, иген-тару һ.б.* 4) икенче компонент беренчесенең фонетик варианты: *малай-шалай, имеш-мимеш һ.б.* 5) компонентлары мөстәкыйль кулланылмый торган парлы сүзләр: *ыгы-зыгы, ыбыр-чыбыр, урык-сурык һ.б.* 6) икенче компоненты кара, мазар, фәлән сүзләре белән ясалган парлы сүзләр: *кеше-кара, әйбер-фәлән, китап-мазар һ.б.* 7) компонентлары 3 зат тартым кушымчасы алган сүзләрдән төзелгән парлы сүзләр: *уты-суы, башы-ахыры һ.б.*[2: 38-39]

Марсель Галиевның "Рух" исемле китабында чор-заман, тарихыбыз хакында фәлсәфи уйланулар, халкыбызның мәшһүр шәхесләре турында әдәби портретлар тупланып бирелгән һәм анда автор парлы сүзләрне бик күпләп, мул куллана. Парлы сүзләрне компонентларның лексик-семантик мөнәсәбәтләренә карап төркемләү тибына аеруча еш һәм актив синонимик парлы сүзләр кулланылган. Бу төр парлы сүзләрнең зур күпчелеген ике компоненты да актив кулланылыштагы парлы сүзләр тәшкил итә: Халыкның *холык-табигате*, тарихы, *гореф-гадәте*, омтылышы, *уй-гаме* сүзләргә сыйган. Ана карынының ук без телнең *моң-яңгырашын тән-вөҗүдебезгә* сеңдереп үсәбез. Менә мин, *иксез-чиксез* тел дәрьясын күзаллап, гаҗизанә калып торам. ("Сүзгә сусау", 5 б.)

"Рух" әсәрендә капма-каршы (антонимик) мәгънәле сүзләр дә парлашкан: *Җәяүле-атлы* шигърият бишеге. Кичерегез безне, *гаярь-күндәм* малкайлар! ("Ат рухы", 12 бит.) Үз биләмәсенең иминлеге өчен *көне-төне* уяу сакта тора. Малай, *эсселе-суыклы* булып, балбалның җылы ташына сыенды. ("Дала рухы", 28 б.)

Нинди дә булса билге буенча охшату, гомумиләштерү нигезендә парлашкан сүзләр дә очрый әсәрдә: Китап битенә сибелгән һәр хәрефнең үзенчәлекле *билге-бизәкләре* аша дөньяны күзаллау – шәмдәлле, каурый каләмле чорлардан килгән бөек халәт иде бит. *Кәгазь-каләм* күпме фидаи җаннарның инсаниятенең маяклары иткән иде! ("Китап рухы", 54 б.)

Парлы сүзләрне компонентларның нинди кулланылыш өлкәсенә караулары буенча  (алынма сүз, архаиклашкан сүз) һәм аларның статусы, нинди грамматик формада килүләре буенча төркемләгәндә һәр ике компонент та хәзерге телдә кулланыла торган мөстәкыйль сүзле парлы сүзләрне җөмләләрдән табабыз: Яңа язып китергән көйләренә *җан-сулышын* үзеннән бүлеп биргән өчен аңа кайсы композитор гына мәңге рәхмәтле түгел икән?! Көтелмәгән *кайгы-хәсрәт* ачысын да аңа бәләкәйдән үк татырга туры килгән. Безнең *татар-башкорт* көйләрендәге традицион бормаларны, миллизмнарны моң дип атаучылар да бар. ("Илһамлы халыкның илханы булыр", 386, 392 б.)

Компонентларының икесе дә, яки берсе генә алынма сүз булган парлы сүзләрне язучы шулай ук күпләп куллана: Халыкның *холык-табигате*, тарихы, *гореф-гадәте*,

омтылышы, *уй-гаме* сүзләргә сыйган. Туган телнең *көй-тибрәнешенә*, нәкъ менә шул телнең табигатенә *хас-тәңгәл* моң туа. Кешенең тәнен, җанын туган тел сугарып килә, ул аның холкын билгели, *аң-зиһененә* чиксез үсеш мөмкинлеге бирә, шул телнең эчке хасиятеннән ялралган *җыр-моң* исә кешенең *халәт-рухиясенә* дәва, омтылыш дәрте өсти. ("Сүзгә сусау", 5 б.)

Икенче компонент беренчесенең архаиклашкан варианты булган парлы сүзле җөмләләр: Безнең ул кадәр үк явыз түгеллегебезгә тәмам ышангач, суырлар *бала-чагалары*, бөтен гаиләләре белән оялары кырыена чыгып яттылар. Киресенчә, чын *ир-ат* нәкъ менә шундый булырга тиеш дип уйлап, аларга кызыгып карый идек. ("Сөйлә, җил... юат мине", 66,72 б.)

Югарыда билгеләп үткәнчә, Марсель Галиев үзенең "Рух" әсәрендә татар теле, сүзе, моңы турында, аерым бер образлар, башлыча ана, ат, фән, җир, дала, Атилла, тәңре, милләт, татар рухы, тарихыбыз хакында фәлсәфи уйлануларын сурәтли. Ә фәлсәфилек-гомумиләштереп күзаллауга нигезләнгән фикерләүне таләп итә, шуңа бәйле М. Галиев үзенең әсәрләрендә парлы сүзләрне күпләп кулланган, чөнки алар җыймалык мәгънәсенә ия лексик берәмлекләр.

## "Туган җирем тургай булып, Сыйган күңел читлегенә" ("Нигез" әсәре буенча 7 нче класста сыйныфтан тыш уку дәресе)

*Хәйретдинова Флёра Мөгътәсим кызы,*
*Азнакай шәһәре 9 нчы гомуми урта белем мәктәбенең*
*туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы*

*1.Дәреснең максат һәм бурычлары.*

1) Әсәрдә мифологик образның бирелеше.

2)Сентименталь рухтагы әсәрләр укырга күнектерү.

3) Анализ нәтиҗәсендә әсәрнең эчтәлеген табу.

4)Туган җирнең, туган нигезнең кадерен белергә өйрәтү.

*Дәрес тибы*. Дәрес- конференция.

***Дәрес барышы.***

*Мотивация.* «Киткәннәрнең җылы аяк эзен Саклап тора сыман бусага, Кеше кайта, Кайта туган өйгә, Бик күп сулар аккан булса да". (Х. Әюп)

Шигырь юллары турында фикер алышу.

Кластер ысулы ярдәмендә укучылар белән "Нигез нәрсә ул?" соравын ачыклау.

*I. Әсәргә анализ ясау.*

*Укытучы.* Туган илнең, туган туфракның җылысын тоеп яшәүдән дә рәхәт нәрсә юктыр. Туган җир туфрагының исен тоеп яшәү җанга яшәү дәрте өсти. Туган туфрак җылысының кодрәте көчле: үз кешеләрен үзенә тарта ул. Бүген без якташыбыз-районыбызның Балтач авылында туып үскән язучы, шагыйрь Марсель Галиевнең "Нигез" әсәрен өйрәнербез. Аның биографиясе белән танышып китик. (Бер укучы авторның биографиясен сөйли).

Укучылардан повестьның сюжетын анализга ярдәм итәрлек итеп сөйләтү. Алар түбәндәге тәртиптә сөйлиләр:

1) Әсәрнең төп герое Тәнзил һәм аның балачагы белән бәйле вакыйгалар;

2) Өянкенең күз алдында булган вакыйгалар;

3) Өянкене утыртучы Сәмигулла абзый һәм аның уллары Давыт, Хикмәтулла һәм Байтирәк белән бәйле вакыйгалар;

4) Урта яшьләрдәге Тәнзил туган авылында;

5) Күрше кызы Нәзиләнең туе һәм Өянке вакыйгасы.

*Укучы.* Әсәрдәге вакыйгалар Алтын Болак авылында бара. Тәнзил шул авыл малае. Тап-такыр итеп кырылган, кояш ялаган башы тәбикмәк ябылган кебек ялтырап тора. Кушаматы-бүре маңгай. Башка меңнәрчә авылдагы вакыйга, эш-мәшәкатьләр аларга да хас. Әсәр башында ук аларның көтү чираты килеп җитүе, әнисенең сыер савуы, Алпамша кушаматлы кәҗәләренең бәтиен бүре ашавы кебек вакыйгалары белән танышабыз.

Тәнзил үзенең дуслары Зәбир, Фирзан белән төрле шуклыклар эшләргә дә бик маһир булалар. Елына бер печән өмәсеннән "йомшап, мәзәк хәлдә кайткан" Нәүширван абзыйның хатыны Сабирәттәй кабарынып каршы ала. Нәүширван абзыйның хатынына: "Сине сагынып кайттыммыни мин сугыштан, убыр! Шушы киртә казыклары тартып кайтармаган булса... белмисез полячкаларның чибәрлеген, Брониславага җитәргәме сиңа?"- дип кычкыргач, хатыны, көнләшеп, ишеген эчтән бикли дә кереп китә. Нәүширван абзый юеш үләндә йоклап китә. Малайлар сугышта булган кеше җирдә йокларга тиеш түгел дип, бер хәйлә табалар. Җепле бәрәңгене тәрәзә кагарга куеп, Сабирәттәйне йоклатмыйлар. Ахырда хатыны ирен чыгып алырга мәҗбүр була. Икенче көнне авылда Сабирәттәйләргә җен килгән, тәрәзәләрен шакыган дигән хәбәр тарала.

Тәнзил туган ягының табигатенә, аның Сарай, Чатыртауларына карап соклана.

*Укытучы.* Тәнзилнең әти-әниләре турында ниләр белдегез?

*Укучы.*Тәнзилнең әтисе агачтан да, калайдан да әллә ниләр ясый белә. Агач саплы, җиз божралыпәкеләре генә дә ни тора! Әтисенең пәкесе йомшак ала дип, күрше-тирә чәч алдырырга аларга керә.

Кечкенәрәк чакта аңа әтисе кырдан "куян чәе", "куян ипие" алып кайта торган була. Малай аңа чын күңелдән ышана. "Ул ипигә кырлар исе, кояш нуры, җил тәме сеңәдер. Юл йөреп кайткан ипи шуңа бик тәмле тоеладыр", - ди Тәнзил.

Әнисе коры гына сөйләшә, улының аркасыннан да сөйми, иркә сүзләр дә әйтми. Ләкин ул беренче карашка гына шулай. Чит авылда берәр кешенең фаҗигале үлемен сөйләсәләр, шуңа да елый торган була.

*Укытучы.* Тәнзилнең яраткан шөгыльләре, хыяллары нинди?

*Укучы.* Аның хыялы үскәч көтүче булу. "Көтү көткәндә уйланып йөрергә була", - ди ул Сафуанга. Иң яраткан шөгыле – рәсем ясау. Иптәш малайларының портретларын ясый, табигатьне рәсемгә төшерә.

*Укытучы.* Әдипләр мәгънә ясауда аеруча актив катнашкан образларны кабатлыйлар. Әсәрдә нинди образ еш кабатлана?

*Укучы.* Өянке. Ул метафора булып килгән. Өянке-авылдагы вакыйгаларның шаһиты. Аны Сәмигулла туган нигезенә утырткан. Сәмгулла олы улы Давыт белән төпчеге-Байтирәкне калдырып, биш-алты өй аша гына яшь хатынга йортка керә, үзе белән уртанчы улы Хикмәтне дә ала. Яшь хатынга киткәнче өен сипләп, үзәккә күчереп куя. Өянке беренче нигездә утырып кала, Сәмигулла аны бер мәртәбә кисәргә талпына, ләкин кулы бармый. Ихатасыз, хуҗасыз калган Өянке баштагы мәлләрдә куркып яши. Чөнки теләсә кайсы килеп ышкына, сындыра. Иң хәтәре: янәшәдәге тәмле сулы коны җир белән тигезлиләр. Томаланган су кешеләргә рәнҗи, моны Өянке тамырлары сизә. Өянке суга интексә дә, кешеләр язмышы белән яшәп, ул бу хакта онытты бугай.

Ир-атлар сугышка Өянке янынннан китәләр. Авыр сугыш елларының үтә зәһәр салкыннарында барлы-юклы утыннар ягылып беткәч, чират Өянкегә дә җитә. Менә шунда сугышта гарипләнеп кайткан Байтирәк: “ Шушыннан күпме иртләр сугышка китте. Үрдән авыл күмелгәч, иң соңыннан шушы Өянке хушлашып калды безнең белән. Яу кырындагы ирләрегезнең хәтерен кисәргә ничек кулыгыз бара?” – дип Өянкене саклап кала.

Җиңү көне саен исән кайткан ирләр, хатын-кызлар Өянке янына җыела. Авылның 112 ир-егете сугыштан әйләнеп кайтмый. Ләкин агачта 111 кулъяулык җилферди. Берсен хикмәт хатыны Нәзифә элми. Чөнки ире хакында авылда немецларга сатылган дигән сүзләр йөри. Ләкин Нәзифә караңгы төшкәч кенә кулъяулыгын Өянкегә бәйли.

*Укытучы.*Ни өчен Байтирәк бертуганы Хикмәтулланы яратмый башлый?

*Укучы*. Байтирәк абыйсы Хикмәтне сатлыкҗан, бөтен нәселгә кара якты, ди.

*Укытучы.* Ә чынлыкта Хикмәт белән нәрсәләр була?

*Укучы*.42 нче елда концлагерьдан беренче мәртәбә качканда, ул исән калырмын дип ышанмаган иде. Бары тик иректә үлү турында уйлаган иде. Ул авылы, карт наратлар шаулаган зират, Өянке янында озатып калган Нәзифә – бу күренешләргә мәҗүсиләрчә табына һәм туган җир кадеренз дзхеле барлыкны шушы мәсхәрәле язмышын үзгәртеп кенә ирешә ала иде. (Бер укучы Хикмәтнең иптәшләре белән канауга ун чакрым озынлыгындагы күмелгән торба эченнән качарга омтылуы хакындагы вакыйганы сөйли).

*Укучы*. Җиде мәртәбә каяканнан соң, атарга хөкем ителеп, Италия чигендәге үлем лагерена китерәләр Хикмәтне. Куба утравында шикәр камышы плантациясендә дә, Багам утрауларында да эшли. Француз пароходының трюмына эләгеп, материкка кайтып егыла. Сугышка китүенә 10 ел узгач кына ул авылына аяк баса. Хикмәтулланы үлеменнән бердәнбер хыялы-кояш чыгышы ягында калган туган иле генә саклап кала.

*Укытучы.* Байтирәккә язмыш нинди сынаулар әзерләп куйган?

*Укучы* .Байтирәк 20 яшендә сугышка китә. Киткәндә Өянкене кочаклап: “Шулай бер кыз да кочакламаган килеш сугышка китәм”, - дип елый. Шунда аны Солтания үзенә чакырып кочаклый Сугышның икенче елында Байтирәк чәчләре агарган бөкре ир булып кайтып төшә. Госпитальдә ятканда Байтирәк: “Исән-сау шул Өянке төбендә бер утырсам үлсәм дә үкенмим”, - дип уйлана торган булган. Алар Солтания белән өйләнешәләр.

*Укытучы.* Давыт хакында ниләр әйтә аласыз?

*Укучы.* Беркөнне авылга Сәмигулланың олы улы Давыт затлы машиналарда тап-таза ирләр белән кайтып төшә, дөресрәге, үтешли сугылып чыга. Ул дәрәҗәле урында эшли, иптәшләре аңа Давид Самойлович дип кенә дәшәләр. Кайчандыр сиртмәле кое янындагы ябага туп тибеп уйнаган Давыт үзенең туган нигезен күрергә кайткан. (268 нче биттәге юлларны табып уку). 70 яшьлек Давыт кулъяулыгын чыгарып, читкә борылды да, тиз генә күз төпләрен сөртте, аннары, иелеп кулъяулыгына туфрак алып төрде дә саубуллашып китеп барды.

*Укытучы.* Повестьның икенче бүлегендә Тәнзил инде урта яшьләрдәге ир. Туган авылына кайткач аны нинди уйлар били?

*Укучы.*Тәнзил Алтын Болак авылы буйлап йөри. Әнисе аңа: “Читтән кайталар да шул аръяк болында йөриләр, ни калгандыр инде анда, - ди. Читтән кайтканнарның

үзгәрмичә калган болын-таулар арасында үткәндәге эзләрен хәтерләрендә яңартып йөрүләрен гомере буе авылдан чыкмаган әни каян аңласын?!”- дип уйлый Тәнзил.

*II. Әсәргә анализ ясау.*

*Укытучы.*Хәзер әсәрне өлешләргә бүлик һәм шушы вакыйгалар арасындагы бәйләнешләрне табыйк.

*Укучы.* Повестьта башка авылдашлары кебек Хикмәт тә, Байтирәк тә ил азатлыгы өчен көрәшкә күтәреләләр: яу кырына китәләр. Байтирәк сугышта чагында авылын, бигрәк тә туган нигезендәге Өянкене бик сагына. Хикмәтне мәсхәрәле язмышы – әсирлеккә эләгүе бик эзәрлекли, башкалар кебек кулына корал тотып сугыша алмавына кайгыра. Зур газаплар белән тоткынлыктан, үлемнән котылуына да кояш чыгышы ягында калган туган иленә бурычлы ул. Чөнки Ватанына кайтасы килү теләге шулкадәр көчле була.

*Укучы.* Ир уртасы Тәнзилне туган авылы, туган нигезе тартып кайтарганын белдек. Авыл урамнары буйлап йөргәндә аңа бала чагындагы хисләре әйләнеп кайталар. Хәтта ул инде бакый дөньяга күчкән усал, төмсә Нәүширван абыйны да “гел буйга сөйләшүчеләр арасында бер аркылыга сөйләшүче кирәк инде ул” дип яратып искә ала. Дусты Зәбир дә бу дөньяда юк инде.

*Укучы.*Яшүсмер чагында ук авылдан чыгып киткән Давыт та, сагынып, туган нигезен күрергә дип кайткан.

*Укытучы.*Бу өлешләр ни турында?

*Укучы.*Бу өлешләрне “Туган якны сагыну” яки “Балачак һәм сагыну” дип исемләп булыр иде. Аларны гомумиләштереп, туган якны сагыну дибез.

*Укытучы.*Каршылыкларны эзлибез.

*Укучы.*Хикмәт, Байтирәк, Нәүширван абзыйлар, Мәдинә апа, Тәнзилнең әти-әнисе туган авылларында яшәп гомер итәләр. Каршылык туган авылларыннан читкә киткән Давыт белән Тәнзилнең күңелләрендә. Аларның икесенең дә күңелләрендә бала чактагы табигать, авыл күренешләре, гореф-гадәтләр, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр хәзер хәтергә әйләнгән. Хәтер буларак алар олы яшьтәге кешеләрдә сагыну хисе уяталар.

*Укытучы*. Хис дәрәҗәсе, хиснең сәбәбе, юану эзлибез.

*Укучы*. Хис тудыручы сәбәп-туган яктан китү дәрәҗәсе-Давытның туган нигезендә күңеле тулуы, Тәнзил иптәшләре белән очраша алмавына үкенә. Берсе кулъяулыгына нигез туфрагын алып китә, икенчесе авыл урамнары, зират тирәләре буйлап йөри, тауларга карап уйланалар-әнә шулай юаналар, сагынуларын басарга телиләр.

*Укытучы.*Әсәрдә Өянке-метафора дигән идек. Метафора белән төп өлеш кушылуы нәтиҗәсендә туган эчтәлекне табыйк.

*Укучы.* Өянке-хәтер сакчысы. Авылдагы бөтен кешеләрнең уй-серләрен, моңзарларын ишетеп тора. Авыр сугыш елларында да күпме хатын-кыз аңа килеп “сыена” торган була. Сусызлыктан интеккәндә дә, кешеләр аңа зыян салганда да зарланмый ул. Гомере буе кешеләр гаме белән яши. Өянкегә карап Давыт та үз нигезен тапты, Байтирәк тә аны сугыштан сагынып кайтты.

- Өянке: “Кешеләр агачлар кебек бер урында гына тамыр җибәреп яши алсалар, кайту-китү, сагынулар булмас иде”,-ди. Кәүсәсе корып, җиргә ауганда да аның тамырлары шул үскән урынында калачак.

*Укытучы.*Әсәрнең идеясен билгелик.

*Укучы.*Кешегә туган ягында һәммә нәрсә якын. Берәүләргә нигез бүген тормыш итә торган урын, икенчеләрнең ул хыялында гына яши. Нигез белән бәйле Өянке дә, корып ауса да, алар хәтерендә яшәячәк. Туган якның кадере читкә киткәч тагын да ныграк арта икән. Дәреснең темасы итеп алынган шигъри юллар да шуңа аваздаш. Туган як турындагы хатирәләр тургай кебек күңел түрендә “сайрап” торалар.

## Марсель Галиев – Чатыр тавының биеклеген һәм бөеклеген дөньяга танытучы

*Хәкимов Айгиз, Авзалов Әмир, 5 сыйныф,*
*«Азнакай шәһәре 7 нче урта гомуми белем мәктәбе»*
*Җитәкче: Кашапова Фирүзә Фәнил кызы*
*туган тел (татар теле) һәм әдәбияты укытучысы*

Туган ягыбыз Азнакай-Идел йортның кояш чыгышы тарафында, Чал Уралның соңгы дулкыннары кучкар- кучкар хасил таулар иткән манзаралы як булыр.

Аз да түгел, күп тә түгел....

90 ел аңа бары.

Я, әйтегез, нинди як бу?

Гүзәл АЗНАКАЙ ягы.

Һәр авазы табигый чиратлашып килгән А-з-н-а-к-а-й дигән тылсымлы аһәңгә тугайлар киңлеге дә, тутлы каенлыкларның тымызык ак төннәре дә, бөгелә-бөгелә аккан елгалары да, Чатыр тавы да, шушында гомер сөргән кешеләрнең тулган ай кебек карашлары да сыйган.

Җире-җәннәт, суы- ширбәт, халкы-талант шул Азнакаемның. Чыннан да, үз җиребездә туып үскән якташларыбыз фән, медицина, хокук, хәрби өлкәләрдә үзләренең талантларын күрсәттеләр. Туган ягыбызның гүзәл табигатеннән илһам алып, кеше җаны өчен рухи азык тудыручы сәнгать, әдәбият, мәдәният осталары да аерым игътибарга һәм хөрмәткә лаек . Илсөяр Хәйруллина, Роза Щербакова, Рәшит Зәкиев кебек журналистларыбыз, мәшһүр артистларыбыз Әзһәр Шакиров, Нәҗибә Ихсанова, танылган җырчыларыбыз Зәйнәп Фәрхетдинова, Миргаяз Шәрәфиев, Равил Галиев, Данир Сабиров-безнең горурлыгыбыз. Яраткан композиторыбыз Сания Әхмәтова, әдәбият тарихына кергән якташларыбыз Әнәс Кари, Гариф Галиев исемнәрен дә зур хөрмәт белән искә алабыз. Шушы күренекле якташларыбыз арасында Татарстанның халык язучысы **Марсель Галиев** тә бар.

Без бу эзләнү эшебездә 1)якташ шагыйребез Марсель Галиев иҗаты өчен туган ягыбызның җанга якын табигатенең илһам чыганагы булуын һәм 2)аның иҗатында туган як табигате, бигрәк тә Чатыр тавының биеклеге һәм бөеклеге темасының үзәктә торуын дәлилләү максатын куйдык.

Эзләнү барышына түбәндәге бурычлар билгеләдек:

1. Марсель Галиевнең тормышын һәм иҗатын өйрәнү.
2. Сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү.
3. Укучыларда Марсель Галиев иҗатына кызыксыну уяту;
4. Якташ шагыйребез Марсель Галиев иҗаты аша укучыларда туган як табигатен ярату хисе һәм аны сакларга омтылыш тәрбияләү.
5. Мөстәкыйль фикер йөртү һәм фикерләребезне дәлилли белү күнекмәләре формалаштыру.

Эш барышында түбәндәге эзләнү методлары кулландык:

1. Район үзәк һәм балалар китапханәсендә булу, якташ язучылар, аерым алганда, Марсель Галиевнең әсәрләре һәм аның иҗаты турында язмалар белән танышу һәм аларны өйрәнү;

2. Мәктәп, район һәм шәһәр туган якны өйрәнү музейларында булу; юбиляр шагыйребез Марсель Галиев тормышы һәм иҗатына кагылышлы материаллар, экспонатлар белән танышу;

3. Шагыйрь Марсель Галиев шигырьләрен, әсәрләрен өйрәнү, “Әдәби туган як” түгәрәгендә нәфис сүз бәйгесе үткәрү;

5. Марсель Галиев турында тупланган материаллардан презентация, “Чатыр тау җиле” әсәренә буктрейлер-китапнамә төзү.

Куйган максатыбызга ирешү юлында төп чыганак итеп М. Галиевнең шигырьләрен, әсәрләрен һәм аның иҗаты турында “Мәйдан” журналындагы, “Балачак әдипләре” китабындагы язмалар һәм 4 томлы “Сайланма әсәрләр”е алынды.

Азнакай-безнең туган ягыбыз. Ул республикабызның көньяк-көнчыгышында урнашкан. 90 еллык тарихы булган Азнакай төбәгенә килгән һәр кеше аның гаҗәеп матур табигатенә, кешеләрнең нечкә күңеллелегенә, рухи гүзәллегенә сокланып туя алмый.

Районыбыз территориясе буенча агучы Ык елгасы, аның янәшәсендәге күлле әрәмәлекләре, болыннар, табигатьнең матур манзараларына бай күренешләр хакында күп сөйләргә мөмкин**.** Ә бу матурлыклар туган як шагыйрьләре иҗатында чагылыш табамы соң? Без бүген үзебезнең якның шифалы суларын эчеп, сихәтле тау һавасын сулап үскән халык шагыйре Марсель Галиев иҗатына тукталып, шул сорауга җавап эзләрбез. Балтач авылында туып, бүгенге көндә Казанда яшәүче якташыбыз үзенең туган ягын “кечкенә Швейцария” дип тиккә генә атамаган шул! Чыннан да, безнең якларның матурлыгы, халкының уңганлыгы күпләрне сокландырырлык.

Ә туган ягым Азнакайның горурлыгы булган мәгърур Чатыр тавы – Татарстаныбызның иң уникаль табигать һәйкәле, безнеңчә.

Ерактан ул - зәңгәр пирамида
Чал Уралның соңгы дулкыны (М. Галиев)

Әйеее...Изге тавыбыз шагыйрьләрне йөрәкләргә үтәрлек юллар язарга илһамландыра, шушы якларда туып-үскән күпләрне кулына каләм алырга мәҗбүр итә. Чатыр тауны зурлаган шагыйрьләребез арасында Марсель Галиев, Илдус Гыйләҗев, Нур Әхмәдиев, Флёра Гыйззәтуллина... һәм башка күренекле якташларыбыз бар. Без аларны “Чатыр тау мәҗнүннәре” дибез.

Чатыртауны “үзләштерде” Нур Әхмәди, Ирек Бәдри,
Имештер лә тауны тери Илдус Гыйләҗ, Марсель Гали...

Чыннан да, Марсель Галиев “Чатыр тау” шигырендә:

“Тауларның да,
Тауларның да маңгаена
Язылады, язылады язмышлар.
Без ялгышсак,
Без ялгышсак,тауларга да
Кагылады ялгышлар.
Аргамаклар,

Аргамаклар таудан чаба,
Тугайларда,тугайларда - томаннар.
Бу дөньяны,бу дөньяны без шушылай
Яратырга туганнар", - дип язса, "Тау рухы" шигырендә:
"Чатыр тау, дисәм, күңелдә
Чөелә бер горурлык.
Ул горурлык гел дә шулай
Тау рухына торырлык!
Саумы, диеп каршылый ул,
Кочаклап ала җиле.
Тау гынамы – туган җирнең
Кыйбласы, шәмаиле.
Төрле милләт кешеләре
Төпләнгәннәр китмәскә.
Үзара дус,тату булсаң,
Нигә гомер итмәскә.", - дип горурлана...

Татарстанның иң биек ноктасы - мәгърур Чатыр тауга сокланып һәм аны яратып мәдхия җырлый:

Исәнме, мәгърур тау!
Туган як тәхете - Чатыр тау, исәнме!..

Бакый заманнарда, дәһшәтле бозлык чорында мамонтларның күз карашын хәтеренә сеңдереп калыккансың да, бүген инде туган ягымның йөзек кашы булып, күпме күңелләрне әсир иткәнсең.

Янәшәңдәге дулкын-дулкын таулар иңенә басып меник әле синең ияреңә.

И бу җиһанның гадел минутлары...
И бу җанның убылыр упкыннары...
Ә җиле...

Рәхмәт сиңа, Чатыр тау җиле! Күңелдәге юшкынны, гөнаһларны тараткан өчен мең рәхмәт сиңа!"

Әйе, төбәгебездәге горур Чатыр тавының биеклеген һәм бөеклеген дә иң әүвәл Марсель Галиев һәм Илдус Гыйләҗев дөньяга танытты. Азнакаем горурлыгы Чатыр тау иҗат кешеләренең берсен дә битараф калдырмый шул.

Татарстан Республикасының халык язучысы, драматург, күренекле җәмәгать эшлеклесе Рабит Батулла да әсәрләнгән аның сыртына менгәч. "Чыннан да, Азнакайның Чатыр тау башыннан дөнья башкача күренә икән. Тау башында сулыш та, офык та киңәя", - дип бәян итә ул тәэсирләрен. Югыйсә, кайда гына булмаган да, тауларның ниндиләренә генә күтәрелмәгән әдип!

Әйе... Чатыр тауны элеккеге заманнардан ук зурлыйлар, ихтирам итәләр, аңа багышлап шигырьләр, җырлар язалар, ерак сәфәрләргә чыкканда аңа карап дога кылалар, аның фатихасын сорыйлар. Менә шундый ул безнең төбәкнең тәхете – Чатыр тау!

Синдәдер хыялы күпләрнең,
Туган як тәхете-Чатыр тау,
Син безне биеккә күтәрдең,
Туган як бәхете-Чатыр тау,- дип рухлана Марсель Галиев тә.

Татарстанның халык язучысы, бик күп төрле хөкүмәт бүләкләре иясе булган якташыбыз төрле жанрларда иҗат итә. Күп кенә шигырьләренә-бигрәк тә туган як табигатенә хозурланып язган шигырьләренә - композиторлар көй язган. Алар “Кайту” дип аталган җырлар җыентыгында тупланган.

75 ел яшәү дәверендә аның дистәләрчә повестьлары, лирик һәм юмористик хикәяләре, шактый күп шигырьләре дөнья күрә, драмалары сәхнәгә куела. Аның аерым әсәрләре төрек, украин, осетин, үзбәк, казакъ, каракалпак, чуаш телләренә тәрҗемә ителә.

1998 нче елда "Рухият" фонды үткәргән ярышта "Догалы еллар" әсәре өчен

I дәрәҗә лауреат Дипломы белән бүләкләнә. 1995 нче елда аңа "Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе" дигән мактаулы исем бирелә. 1996 нчы елда татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткән өчен Президент Указы белән Татарстан Республикасының Мактау грамотасы тапшырыла. Ул - Г.Тукай исемендәге Татарстан дәүләт премиясе лауреаты.

Сулар өчен һава, эчәр өчен су, азыкланыр өчен икмәк кирәк булган кебек үк, кеше җаны һәрчак туган җиренә омтыла. Шуңа да аңа дан җырлаучы сәләт ияләре якташ шагыйрь-язучыларыбыз зур хөрмәткә лаек. Яраткан язучыбыз Марсель Галиев тә шундый шәхесләрдән! Без алар белән горурланыйк, алар сыман туган җиребезне яратыйк, Азнакаебыздан, Чатыр тавыбыздан илһам алыйк!

Бу фикеребезне раслап, чыгышыбызны Марсель Галиев иҗаты турында танылган шәхесләрнең сүзләре белән йомгаклыйсы килә:

“М.Галиев әдәби телнең иң бөек мөнбәренә менгән. Бу мөнбәргә аны Чатыр тау, туган ягы мендергән...” *Флера Сафиуллина, профессор*.

“Туган якны сурәтләгәндә, ул-хыялый бер үсмер, ялларын тузгытып далада чапкан кырыкмыш тай,...туган җирнең газиз баласы...” *Гариф Ахунов, татар халык язучысы*

Шулай итеп, без туган ягыбыз Азнакай, аның бөек һәм биек Чатыр тавы үзенең гаҗәеп табигате, рухи гүзәллеге белән горурлана; туган җир иҗат кешеләренә илһам бирә һәм талантлы халкым туган ягым матурлыгына мәдхия җырлый, дигән нәтиҗә ясыйбыз.

## Марсель Галиев иҗатына багышланган әдәби кичә

*Шакирова Дилбәр Сәгыйть кызы, Мамадыш районы*
*“Тау Иле урта гомуми белем мәктәбе”нең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Рус телендә белем бирүче мәктәбебездә татар балаларының туган телләренә кызыксынуын арттыру максатыннан төрле чаралар, бәйгеләр үтә. Милли китабыбызга, аның тарихына мәхәббәт тәрбияләү-безнең төп бурычыбыз. Марсель Галиев иҗатына багышланган бу әдәби чара 9-10 нчы сыйныф укучылары белән әзерләнде.

**Максат:**

- Марсель Галиевның тормышы һәм иҗаты турында белешмә бирү.
- Сәнгатьле сөйләмнәрен, үз фикерләрен төгәл итеп әйтеп бирү күнекмәләрен үстерү.
- Хәзерге татар әдәбиятына кызыксыну уяту, китап укуга җәлеп итү.
- Кешеләргә, туган якка карата миһербанлылык хисләре тәрбияләү.

**Материаллар һәм җиһазлар:**

- Марсель Галиев портреты.
- М. Галиевның китаплары, төрле еллардагы әдәби журналлар.

**1 нче алып баручы**.

Марсель ага Галиев туган ягында алтын көз патшалык иткәндә туган. Әйдәгез, шигырьләрен тыңлап китик.

**1 нче укучы.**

**Әбиләр чуагы.**

Бу - әбиләр чуагы бу!
Чатнап яна пәрәвезләр,
Күктә – кошлар көтүе.
Әҗәткә көн алып көздән
Җәйнең бәйрәм итүе.

**2 нче укучы.**

Бу – әбиләр чуагы бу!
Сары балкыш кая? Уйный
Яшел төсләр тилереп.
Тик күлмәкчән чыккан бабай
Керде салкын тидереп.

**3 нче укучы.**

Бу – әбиләр чуагы бу!
Очып арган күбәләкләр
Канат какты җанланып.
Борылып җәйгә карадыңмы,
Кадрен белеп, таң калып?

**4 нче укучы.**

Бу – әбиләр чуагы бу!
Беркатлы карт алмагач та
Ышанып чәчәк атты.
Җәнлек сыман посып кына
Бусагага көз ятты.
Бу – әбиләр чуагы бу...

**1 нче алып баручы**.

Марсель Галиев шигырьләре... Алар әллә ничекләр итеп җанны актара, рәхәт бер халәттә тибрәтә. Күз алдында төсләр, матур сурәт-картина. Хисләр бии... Аның теле, стиле, аһәңнәре үзенә бертөрле, беркемнекенә охшамаган: затлы, нәзберек, нәфис. Шагыйрьлек җене, хыялый алдану бәхете... Иҗатына бәяләмәне дә шагыйрьнең үз сүзләре белән кабатлыйсы килә.

«Шигырь – мәңгелек упкынында тирбәлгән күңел бишеге...»

«Шагыйрь – Күк белән Җир арадашчысы!»

Болар Марсель Галиев фикерләре. Сүзләре, шигыре күңел тәлгәшеннән өзелгән!

**2 нче алып баручы**.

Язучы һәм шагыйрь Марсель Баян улы Галиев 1946 нчы елның 8 нче октябрендә Татарстанның Азнакай районы Балтач авылында туа. Авыл баласы табигатькә якын һәм шуңа күрә яңа өлгергән игеннең хуш исенә, меңләгән энҗедәй җемелдәүче кар бөртекләренә тирән мәхәббәте, өзелеп яратуы чагыла аның.

**5нче укучы.**

Йолдыз нурлары калтырый
Иртәнге көмеш чыкта.
Өянкеләр башын ия
Күке кычкырган чакта.

**6 нчы укучы.**

Күке кычкырган чагында
Нигә соң дөнья моңлы?
Затлы тавышын көйләгән
Сандугач хәтта тынды.

**7 нче укучы.**

Ә син санама гомереӊ,
Туган як моңын тыңла.
Тыңла да җаныңа сеңдер,
Мәгънәсен сүзсез аңла.

**8 нче укучы.**

Купшы залларга китереп
Күкене тыңлап кара –
Өянке, инеш, болыннар
Бар моңын алып кала.

**9 нчы укучы.**

Туган җир моңы. Елларны
Сынама. Тыңлап кара.
Беркөнлек озын гомерле
Күбәләк очып бара...

**10 нчы укучы.**

**Чатыр тау**

Ерактан ул – зәңгәр пирамида,
чал Уралның соңгы дулкыны.
Иңнәренә ятып оеп кала
төньяк җилләренең салкыны.

**11 нче укучы.**

Җил йомгагы булып кылганнары
үзәннәргә таба йөгерә.
Кайнап аккан ак болытлар аша
тау кояшка гүя үрелә.

**12 нче укучы.**

Ә төннәрен чума офыкларга,
син ерактан карап тор гына;
Алма кебек өзелә дә күктән
тауга йолдыз тама тын гына.

**13 нче укучы.**

Куакларда әле төн кунаклый,
тау башында инде яңа таң.
Саумы, диеп дәшәм еллар аша,
күңелдәге сынын яңартам.

**1 нче алып баручы.**

1964 нче елда Азнакайдагы 1 нче татар урта мәктәбен тәмамлый. 1965 -1968 нче елларда армиядә хезмәт итә. 1969 нчы елда Марсель Галиев Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга керә. 1974 -1983 нче елларда ул Татарстан Язучылар берлегендә һәм «Казан утлары» журналы редакциясендә эшли. Аннары профессиональ язучы була. Марсель Галиев шигърият һәм проза жанрларында иҗат итә. 1979 нчы елда «Еллар чалымы» исемле беренче шигырьләр китабы, ә 1980 нче елда «Ул чакта» исемле проза китабы дөнья күрә.

**2 нче алып баручы.**

(“Нигез” әсәреннән өзек укый.) Әнә тыкрыктан минем әни төшеп килә. Көянтә-чиләк аскан, кулында төенчек. Чишмә янына җиткәч, ул миңа кул изи. Мин таудан төшәм, түмгәктән түмгәккә сикереп,аксырганакларның киң, яссы яфракларына җыелган чык суын түгә-чәчрәтә, әнигә таба йөгерәм. Ул инде чиләкләренә су тутырып куйган, төенчек асылган сары буяулы көянтәне сузып, миңа каршы килә...

1 **нче укучы. Күрше кызы**

Күзәттем ни, сүз әйттем ни –
үземнең үз күңел эшем:
Чытлыкланып, кәз-кәз басып,
назлыкайның күр йөрешен:
Җилфер керләр эләргә дип
нәзакәтле үрелешен;
Күз карашын тәкатьсезләп
сыгылма бил бөгелешен.

**2 нче укучы.**

Нинди гадел чишкән Ходай
җете төсләр бүленешен:
Җир кызына өстәп биргән
ягымлы нур – Күк өлешен.
Бар барлыгы әйтеп тора
хисләренең түгелешен

**3 нче укучы.**

Күр әле син: үлән-чыкта
эзләренең чигелешен.
Ә егетнең койма аша
үрелеп бер үбелешен.

Бу мизгелдә йөрәгендә
тылсымлы сүз тибелешен
Белми әле: мәхәббәтнең
**4 нче укучы.**
Бирмә, Ходай, мәхәббәттән
күңел дәрте сүрелешен.
Ул хәзергә белмәсен дә:
җиңәм, диеп, җиңелешен.
Күзәттем дә, сүз әйттем дә,
**5 нче укучы. Ачыла да ябыла...**
Нинди җил килеп кагыла
Капкаңның келәсенә;
Нинди бу – бөек ышаныч
Сөенеч киләсенә:

мең үлеп, мең терелешен;
Назлыкайның, куллар болгап,
томаннарга күмелешен...

Миңа нәрсә, күңел эшем:
Кайтар, Вакыт, назлыкайның,
Ыспай басып, бер йөрешен.
Тик бер генә кабатлачы
Шушы җәннәт күренешен.

Ак атта, җилле җайдакның
Тупырдап керәсенә!

Марсель Галиев үз шигырьләрендә балачактан күңелендә калган хатирәләрен яңартып, инде олыгайгач, уйландырган уйларын да язган. Аның әсәрләренә авторның йөрәге аша үтеп, шигырь юлларына әверелгән кичерешләр дәрьясы, уйланулар сыйган. Аның әсәрләре аша һәркем туган якның ниндидер серле тарту көчен, сихри романтикасын тоя, шул хиснең чынлыгына, кеше өчен кадерле булуына ышана.

## “Марсель Галиев иҗатында чагыштырулар”

*Шарипов Айнур, 7нче сыйныф, “Лениногорск шәһәре*
*3нче санлы урта гомуми белем бирү мәктәбе”*
*Җитәкче: Мөхетдинова Резеда Фәвис кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы.*

Бүгенге көндә Марсель Галиев иҗатындагы сурәтләү чаралары тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән һәм бу темамның *актуальлеген* билгели.

Хезмәтнең *максаты*-М. Галиев иҗатындагы чагыштыруларны төркемләп өйрәнү һәм әсәрләрнең телен баетуда аларның ачыклау.

*Бурычлар*:

1. М. Галиев иҗаты белән танышу;
2. Язучының “Су каргышы”, “Еллар чалымы”, “Арыслан йокысы” җыентыкларына кертелгән әсәрләрдән чагыштыруларны табу;
3. Гомуми нәтиҗәләр чыгару.

Өйрәнү *объекты* – М. Галиевның проза һәм поэзия жанрындагы әсәрләре. Өйрәнү *предметы* – әсәрләрдә кулланылган чагыштырулар.

Кулланылган *методлар*: чагыштыру, эзләнү, классификация, анализ.

*Нәтиҗәләр*. М. Галиев әсәрләренең теле гади һәм бик кызыклы. Шулай ук әлеге әсәрләрнең сурәтләү чараларына бай булуын да искәртергә кирәк. Без язучы әсәрләреннән чагыштыруларны аерып алып, төркемләп өйрәндек һәм аларның шактый күп булуына игътибар иттек. Чагыштырулар М. Галиев әсәрләренең телен кызыклы, үзенчәлеклерәк итә дигән фикергә килдек.

Марсель Галиев проза жанрында да, поэзия жанрында да иҗат иткән әдип. Әсәрләре белән танышканда, андагы сурәтләү чараларының шактый булуына

игътибар итәсең. Без язучы иҗатындагы чагыштыруларны аерып өйрәнергә уйладык.

Чагыштыру-нинди дә булса күренешне башка күренешкә охшату ярдәмендә барлыкка килгән сурәтләү чарасы [Заһидуллина, 2005: 92]. Чагыштырулар төрле чаралар ярдәмендә ясала. Аларның һәркайсына аерым тукталырбыз.

М. Галиев иҗатында *-дай/-дәй, -рак/-рәк* аффикслары белән ясалган чагыштырулар, башка чаралар ярдәмендә ясалган чагыштыруларга караганда, шактый аз булуына игътибар иттек. Түбәндәге чагыштырулар әлеге аффикслар белән ясалган:

Синең аваз – бер *тамчыдай*... [Галиев, 1979: 13].

*Кылалмастай* ни каладыр? [Галиев, 1979: 41].

Көн сүрелә учак *күмередәй*,
Ут аласы килми бүлмәгә [Галиев, 1979: 56].

Төнге *күлдәй* күзләр тын, боек ... [Галиев, 1979: 60].

Яфраклары сары *күбәләктәй*
Кунсын әле, кунсын иңеңә [Галиев, 1979: 64].

...Аяк тавышына әнкәй чыга,
йокламыйча көтеп *торгандай* [Галиев, 1979: 81].

Берни *булмагандай*, гасырның
Дулкын-дулкын агылып барышы [Галиев, 1979: 13].

Тагын шунысы бар: М. Галиев поэзиясендә *-рак/-рәк* аффикслары белән ясалган чагыштырулар безгә очрамады. Ләкин без әлеге ысул белән ясалган чагыштыруларны язучының прозасыннан таба алдык:

Мин әйтәм, синең өй Рудирнекеннән *тәбәнәгрәк* булып калды бит, әй! – дип өсти Нургали абзый [Галиев, 2003: 18].

Метражы буенча минем өй *биегрәк* килеп чыга [Галиев, 2003: 18].

Бер-ике көннән яңадан барырсың, икенче *төрлерәк* сүзләр эзләп [Галиев, 2003: 26].

Мыек чылгыен сыпырып, сул күзен кыса төшеп, башын артка *чөебрәк*, склад баскычыннан астагы халыкка вәкарь белән карап тора [Галиев, 2003: 26].

М. Галиев иҗаты *кебек, сыман, шикелле, күк* бәйлекләре ярдәмендә ясалган чагыштыруларга шактый бай. Шунысын да әйтергә кирәк: бу ысул белән ясалган чагыштырулар, башкалары белән чагыштырганда, күпчелек урынны биләп тора. Моңа поэзиядән мисаллар китерик:

Ә күзләре моңсу елмаялар,
баеп барган кояш *шикелле* [Галиев, 1979: 10].

Сагыш *кебек* ачы тәмәкене
салмак кына, тәмләп суырып... [Галиев, 1979: 10].

Җир шары да инде алар өчен
түбәтәй *күк* гади бер нәрсә [Галиев, 1979: 10].

Иртәнге уй тонык сулар *кебек*,
Идел *сыман* китә яктырып [Галиев, 1979: 11].

Тал мамыгы ява карлар *кебек*... [Галиев, 1979: 14].

Гармуны тәмам ярсыган,
бәхеттән шашкан *кебек* [Галиев, 1979: 21].

Алма *кебек* өзелә дә күктән
тауга йолдыз тама тын гына [Галиев, 1979: 25].

Дулкыннар шавын пышылдый
Хәтер *күк* кабырчыклар [Галиев, 1979: 26].
Яшь кызлар толымы *кебек*
Шәп чыбыркы үрүче [Галиев, 1979: 32].
Дулкындагы күбек *сыман*
Сүнәр-сүнмәс уй калган... [Галиев, 1979: 34].
Монда хыял – арканнарын өзеп
үрә баскан кыргый ат *сыман* [Галиев, 1979: 38].
Тарихның бу япан киңлекләре
Ирләр учы *кебек* ачыла [Галиев, 1979: 38].
Табигать *күк* хәрәкәттә алар,
Охшаш моңга, җилгә, болытка [Галиев, 1979: 39].
Ә карашы кара ялкын *сыман* [Галиев, 1979: 43].
Табигатьнең үзе кебек
чишелгән изүләре... [Галиев, 1979: 45].

К*ебек, сыман, шикелле, күк* бәйлекләре ярдәмендә ясалган чагыштырулар язучының прозасында да күп. Моңа мисаллар карап китик:

Җәлил поселогы тирәләренә җиткәч, юллар пәрәвез җебе *кебек* чуала башлады [Галиев, 2003: 8].

Азнакайга пыяла *кебек* егерме җиде юл бер яктан килеп керә, пыяла *кебек* егерме җиде юл икенче яктан чыгып китә [Галиев, 2003: 8].

Йөрмә Шәрип малайлары *кебек*! [Галиев, 2003: 11].

Аны күргәч, “КамАЗ”лар чүгеп кала, алдан барган машиналарны суырып алып, чәйнәп төкергән *кебек* кенә узып китә ул [Галиев, 2003: 13].

Янәсе, сиксән-йөз чакрым тизлектә барган машина аңа туктап торган *шикелле* тоела [Галиев, 2003: 13].

Корбанын тапкан бөркет *кебек* кагына [Галиев, 2003: 14].

Земфирә ханым, сыңар бармагын бөгеп ым гына кага, шулчак Ифтирам, аяк очларына гына басып, хатынының бармак юнәлешенә таба, җеп белән тартылган *шикелле*, суырылып китеп бара [Галиев, 2003: 15].

Баш түбәмдә нидер чатнап ярылды *сыман* [Галиев, 2003: 16].

Ул менә хәзер, колак артын кашыткан мәчек *кебек*, ләззәтле мырлый башлар иде *сыман* [Галиев, 2003: 25].

Чагыштырулар ясалуның тагын бер ысулы бар. Ул – *гүя, әйтерсең лә* теркәгечләре ярдәмендә. Әлеге төр чагыштырулар М. Галиев иҗатында күп түгел. Аның позиясеннән без түбәндәгеләрне таба алдык:

Кайнап аккан ак болытлар аша
тау кояшка *гүя* үрелә [Галиев, 1979: 25].
Кешелекнең узган бала чагы
кайтып килгән *гүя* атларда [Галиев, 1979: 39].
Бу җаныңны чайкап алыр өчен
дөнья *гүя* сулар яраткан [Галиев, 1979: 47].
Урманның бөтен җәнлеге
әйләнгән *гүя* ташка [Галиев, 1979: 50].
Сөембикә *гүя* ак калфаклы
Казан бүген моңсу-сөйкемле [Галиев, 1979: 70].

*Әйтерсең* шәм – кайнар ялкынлы [Галиев, 1979: 72].

Сөембикә *гүя* ак калфаклы

Казан бүген моңсу-сөйкемле [Галиев, 1979: 70].

Без югарыда карап киткән чагыштыруларның барысы да *гади* чагыштырулар. Әлеге чагыштырулар бер сурәтләү объектын ачыклап-сыйфатлап килә. М. Галиев иҗатында гади чагыштыруларның бер җөмлә эчендә берничәшәр килү очракларын да күрдек. Алар яки төрле сурәтләү объектларына карый, яки бер үк объектны төрле яклап күрсәтә.

М. Галиев үз иҗатында *киңәйтелгән* (*җәенке*), ягъни чагыштырыла торган күренешләрнең мөстәкыйль образлар аша сыйфатлануына корылган чагыштыруларга да мөрәҗәгать иткән. Түбәндәге мисаллар моңа дәлил булып тора:

Ифтирамны сөйләтмәү – *кәҗәнең сакалын кыруга бәрабәр* [Галиев, 2003: 12].

Пожар каланчасы *аның белән чагыштырганда бик тәбәнәк* калды [Галиев, 2003: 16].

*Сыер теле зурлыгындагы тимер келәгә* кулын салуга, кече капка челтерәп ачылды [Галиев, 2003: 23].

Шулай итеп, М. Галиев иҗатында чагыштырулар шактый зур роль уйный. Язучы аларның һәркайсын урынлы куллана һәм шуның нәтиҗәсендә, чагыштырулар әсәрләрнең телен кабатланмас матур, төзек, камил һәм үзенчәлекле итә дигән фикергә килергә мөмкин.

Димәк, без М. Галиев иижатында кулланылган чагыштыруларны туплап, төркемнәргә аерып өйрәнгәннән соң түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

1. *-дай/-дәй, -рак/-рәк* аффикслары белән ясалган чагыштырулар, башка чаралар ярдәмендә ясалган чагыштыруларга караганда, иң азы;
2. *кебек, сыман, шикелле, күк* бәйлекләре ярдәмендә ясалган чагыштырулар, язучы иҗатындагы чагыштыруларның иң күп өлешен тәшкил итә;
3. М. Галиев иҗатында гади чагыштырулар күп. Әмма без берничә киңәйтелгән чагыштыруны да очрата алдык (Пожар каланчасы *аның белән чагыштырганда бик тәбәнәк* калды [Галиев, 2003: 16], *Сыер теле зурлыгындагы тимер келәгә* кулын салуга, кече капка челтерәп ачылды [Галиев, 2003: 23]);
4. Бер җөмлә эчендә берничә чагыштыру бергә килгән очраклар да бар (Иртәнге уй тонык сулар *кебек*, Идел *сыман* китә яктырып [Галиев, 1979: 11], Табигать *күк* хәрәкәттә алар, Охшаш моңга, җилгә, болытка [Галиев, 1979: 39], Азнакайга пыяла *кебек* егерме җиде юл бер яктан килеп керә, пыяла *кебек* егерме җиде юл икенче яктан чыгып китә [Галиев, 2003: 8], Ул менә хәзер, колак артын кашыткан мәчек *кебек*, ләззәтле мырлый башлар иде *сыман* [Галиев, 2003: 25]);
5. М. Галиев үз иҗатында кулланган чагыштырулар әсәрләрнең телен үзенчәлекле итә.

## **“Сүз пирамидаларга кадәр туган, Сүз – пирамидалардан соң да калачак...”**

(Марсель Галиевның “Рух” әсәрендә Сүзгә мәдхия)

*Шәрәфиева Азалия, 10 нчы сыйныф,*
*«Азнакай шәһәре гимназиясе»*
*Җитәкче: Ибраһимова Чулпан Рәфәт кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Туган тел төшенчәсенә зур мәгънә салынган. Ул Ватан, туган җир, ата-ана сүзләре белән бер үк дәрәҗәдә торучы бөек, изге һәм кадерле сүз. Ул телне шуңа күрә туган

тел дип атыйлар да. Телгә баланы аның иң газиз, иң якын кешесе-әнисе өйрәтә. Тел-ананың балага зур бүләге.

Туган тел! Һәркем өчен дә газиз, иң кадерле, бернәрсә белән дә алыштырмый торган сүз. Туган телебезне саклау, үстерү, аның сафлыгын булдыру, матурлыгын күрә белү яшь буынның изге бурычы.

Кешегә нәселнең, халкының асыл сыйфатлары иң әувәл тел тәме, тел кодрәте ярдәмендә бирелә. Туган тел ул-халкыбызнең рухи көзгесе. Шушы телдә милләтнең бөтен гореф-гадәтләре генә түгел, үткәне, бүгенгесе, киләчәге дә. Туганнан алып, соңгы сулышына кадәр, тел һәм сүз-кешенең аерылгысыз юлдашы.

Тел һәм сүз.... Бу турыда без туган тел һәм әдәбияты дәресләрендә бик күп сөйләшәбез.Туган тел дәресләрендә сүзләрне грамматик яктан карасак, әдәбият дәресләрендә сүз тәме, аның мәгънәсе турында аңлашабыз. Телебезнең никадәр бай, никадәр моңлы икәненә ианабыз. Ләкин, кызганычка каршы, туган телебездә иркен аралашсак та, сүзләрнең тәмен белү, аны тиешле урында, дөрес куллану осталыгы җитми безгә. Укытучым миңа М. Галиевның “Рух” әсәрендәге “Сүзгә сусау”, “Сүз рухы” бүлекләрен укырга тәкъдим итте. Нәкъ менә шушы әсәрләр аркылы мин телемнең бөеклеген, сүзләрнең никадәр могҗизага ия икәнлеген аңладым.

«Сүз пирамидаларга кадәр туган, Сүз-пирамидалардан соң да калачак...» дип яза Марсель Галиев. “Ни хикмәт бар Сүздә, ни серләр бар? Яме, тәме, гаме нинди?” – дигән сорау бирә автор әлеге әсәрендә. Шушы кызыклы фикер мине эзләнү-тикшеренү эшенә этәрде. Чынлап та, нәрсә ул Сүз, нинди сүзләр була, Сүз көче нәрсә ул? Бу тема миңа бик кызыклы тоелды. М. Галиевның “Рух” әсәрендә Сүзгә кагылышлы өлешләрне барлау, тел, сүз турындагы фикерләрне аерып чыгару, аны туган тел дәресендә алган белемнәр белән чагыштыру ***максаты*** куелды.

Марсель Галиев фикер тирәнлеге белән тел нечкәлеген тәңгәл китерә белгән язучы. Язган һәр җөмләсе укучыны гаҗәпләндерә. Аның күңеленнән чыккан, кулыннан төшкән һәр әсәр кояш нуры кебек ялтырап китә. Марсель Галиев һәр әсәрендә үзе булып кала.

Аның әсәрләре, кагыйдә буларак, интеллектуаль укучыны күздә тотып языла һәм ассоциатив чагыштыруларга, яңача көтелмәгән образлы тәгъбирләргә бай булуы белән аерылып тора. Шуңа күрә дә аның әсәрләрен кат-кат укырга кирәк. Шунда гына ул сиңа ачыла, күңел кылларына үтеп кереп сине тирән уйларга сала, аңны сискәндереп җибәрә.

М.Галиев 2005 елда еллар буе иҗат иткән “Рух” дип аталган затлы китабын бастырып чыгара. “Ат рухы”, “Милләт рухы”, “Китап рухы”, Җир рухы”, “Дала рухы” кебек бүлекләр белән бергә Сүзгә мәдхия җырлаган “Сүзгә сусау”, “Сүз рухы” дип аталган аерым язмалар да бар. Әдип әлеге әсәрләрдә Сүзнең изгелеге, Сүзләрнең барлыкка килү тарихы, Сүзнең кеше акылыннан өстен икәнлеге, татар милләтенең дөньядагы урыны, бай тарихлы үткәне һәм бүгенгесе хакында уйлана.

“Тел байлыгы-буыннан буынга күчә барган ганимәтле мирас, халык бәгыренә язылган тере сүзләр йолдызлыгы”, - дип яза Марсель Галиев. Халыкның холык-табигате, тарихы, гореф-гадәте, омтылышы, уй-гаме сүзләрдә. Ана карынында ук без телнең моң-яңгырашын тән-вөҗүдебезгә сеңдереп үсәбез. Кешенең җанын, тәнен туган тел сугарып килә. Халыкның үткәне, маһирлыгы, хәсрәте, моңы, осталыгы Сүзгә сыйган. Кешегә сүз байлыгы әнисеннән, туган җиреннән килә. Язучы да тел коелары саега башласа, сүзгә сусап, туган ягына кайта. Мондагы

болыннар, таулар, урманнар аңа көч бирә, җанын ял иттерә. “Тәүге сүз-әнкәм сүзе-зиһенемне иркәләп уяткан. Аннары берәм-берәм ачыла башлаган тел коелары. Мин шул коелардан Сүзне чүмечләп-чүмечләп чумырып алганмын,”- ди автор, үзенең тел байлыгы мул булуын аңлатып. Туган тел коесы саекмасын, киләчәк буыннарга да эчәрлек көмештәй чиста суы мәңге булсын иде.

Телнең үсеш тарихына да кагыла автор. Ул аның үсешен могҗиза ди. “Дәверләр буенча берничә сүз, берләшеп, чарлана-чарлана килә дә, ниһаять, тыгыз кысылып, алмаз ядрә булып йомарлана, төп сүзне хасил итә”. “Кайчакларда аваз-хәрефләрне уйнатып, урынын күчереп, Сүзнең башын әйләндереп кара, гасырлар бутала, вакыт ярларыннан чыга, мәгънә йөзтүбән әйләнә”... Нинди матур фикерләр.

Телне, Сүзләрне ул өч зурлык белән тиңли. Беренчесе, йолдызлык. “Күк пышылдавыннанмы, Җир сулышыннанмы яратылган мөкатдәс сүз йолдызлыгы?”. “Сүзләр Күк гөмбәзендәге йолдызлар мириадасы кебек, күренә дә, күренми дә, беленә дә, беленми дә, сүнә дә, сүнми дә, ерак та, якын да, үлә дә, үлми дә.” Икенчесе, телне дәрья белән чагыштыра. Тел дәрьясының аргы ягына берәүнең дә мәңге җитә алмаячагын ул ачык аңлый. Чөнки телне белү, сүзләрнең асыл мәгънәсен ачып бетерү кешегә тулысынча бирелмәгән. Ләкин тел дәрьясы авторны алгысыта, әйдәкли, очындыра, хыял җилкәннәрен киерә. Ә дәрьяның дулкыннары-Сүз тәңкәләре. Алар җем-җем килә. Дәрья өстендәге сүзләрне күпләр аңлый, белә, куллана, ә син төпкәрәк чумып кара һәм энҗе-мәрҗәннәргә тиң сүзләрне табарсың дип киңәш бирә Марсель Галиев. Өченчесе, Телне мәгъруур тирәк, ди. Тирәкнең мең-мең яфраклары – сүзләр. Алар ягымлы шыбырдашып, аң-зиһенгә, тәнгә, җанга шифа булып таралалар. Әлеге тирәк үз байлыгыннан үзе сыгылган. Йолдызлык та, дәрья да, мәгъруур тирәк тә бөеклек символы. Менә шунда без үзебезнең нинди бөек тел хуҗалары икәнлеген аңлыйбыз. “Үз байлыгыннан үзе сыгылган” телне саклыйсы, яклыйсы, өйрәнәсе килә.

Телдәге сүзләрне берничә төркемгә бүлеп карый. Бу бүленеш бик кызыклы, искиткеч, тел дәресләрендә аларны чагыштырып өйрәнергә була.

1. Чыныгып чарланган, чакматашка әверелгән баба сүзләр...
2. Изге нурында җылытып торучы торучы, тудыручы кодрәте бирелгән әнкә сүзләр...
3. Корыч ныклыгына тиң әткә сүзләр...
4. Шәрык илләреннән асылташлар, ислемайлар белән килгән мосафир сүзләр...
5. Күк катларыннан иңдерелгән дини сүзләр...
6. Гашыйклар ирененда бөреләнгән тылсымлы сүзләр...
7. Үз телебезнең яңгырашына ягымлыланып күчкән алынма сүзләр...

Һәрберсенә телебездән мисаллар китерергә мөмкин. “Җебен-җепкә, ибен-ипкә, җеген җеккә китереп күпме дәверләр буена тукыла ул тел келәме”.

Сүзләрнең ниндиләре генә юк безнең телебездә. Чынлап та, уйлый башласаң шулай бит. Тел дәресләрендә без сүзнең бу ягына игътибар итмибез. Бәлки шуңа күрә дә сөйләмебездә хаталар китәдер. Автор безгә сүзләрнең күптөрлелеген исбатлый: имин сүзләр, алкын сүзләр, ялкын сүзләр, фатихалы сүзләр, кыерсытылган, кимсетелгән, тапланган; әчкелтем сүз, сусыл сүз, чәнечкеле сүз, татлы, өрфия, ягымлы; талымлы, сөннәтле, өммәтле, тибелгән, сибелгән, һавалы, дәвалы, олтан, солтан, тыелган, уелган,ялкынлы, алтынлы сүзләр һ.б.

Шагыйрьләр, язучылар сүзләрнең асылын беләләр. Үзләренең сүз көче белән кешегә тәэсир итүләренә басым ясый автор. Шагыйрь – сүзнең колы, ди. Шул ук вакытта, шагыйрь әмер бирсә, "офыккача җәелгән сүз гаскәре, дәррәү кузгалып, тыгыз сафларга басачак"-дип кисәтә.

Авторны хикмәти сорау борчый. Уйдан алда сүз туганмы? Әллә уй, алдан туып, сүзгә әйләнгәнме? Борынгы заманда уй беренче булса, хәзер тел байлыгына ирешкән кеше өчен уй белән сүз икесе бер мизгелдә кабына торгандыр... Сүзнең җаны бар икәнен ул кат-кат дәлилли. "Эчке төш-ядрәсендә йөрәге тибәме, нинди өн-авазлар килә сүз упкынынннан?". Сүзне мең тапкыр, йөз мең тапкыр әйтәсең, ишетәсең, ләкин аның асылын, җан тибешен, кан кычкыруын ишетмичә яки аңламыйча калуың бар". "Учыңа салып, кан тибешен тоеп кара: һәр сүзнең кальбендә үз тәфсире, тән-күзәнәгендә бакый дәверләр тамгасы...". Шуңа күрә Сүзгә зур хөрмәт белән карарга чакыра.

Автор Сүзләр ясалышына аерым игътибар итә. Уйланмас җиреңнән уйга батасың. Әлеге сүзләрнең мәгънәсен яңача аңлый башлыйсың. "Табигать күренешләренә шундый атамалар бирелгән ки, кечкенә чакта ишеткәч аптырап каласың,"-дип яза Марсель Галиев. Ул исемнәрнең асылын төшенү өчен гомер үтү, тәҗрибә туплау кирәк, "күңел колагың" булу кирәк. Чыпчык күзе, тилебәрән, күке сабыны, тукранбаш, кәҗә сакалы, ләйсән яңгыр, киек каз юлы, эт кояшы, җәүле буран, канәфер, кашкарый, тамчы гөл, төнбоек һ.б колакка яңача яңгырый башлый.

"Телне тудырган халык кына аваз иңдереп, сүзләрнең җан тибешен, мәгънәви куәтен ача ала. Сүзләрнең гомер озынлыгы дәүләти тел тәхетенең югарылыгыннан тора". Бу фикер белән мин тулысынча килешәм. Дәүләт көчле, телебез дәүләт теле булганда гына, без, яшь буын, телебезне сакларга кирәклеген аңлаганда гына туган телебез мәңге яшәр.

Күзәтүләргә таянып, Марсель Галиев тел, сүз язмышы, тарихы, бүленеше турында искиткеч матур фикерләр җиткерүен күрәбез. Әлеге бүлекләрне уку миңа туган телемне тагын да тирәнрәк аңларга, сөйләмемне дөресләргә, сүзләрнең бөеклеген тоярга ярдәм итте. Туган телемнең башка телләр арасында кыйммәтле таштай ялтырап торуын сиздем. Бу миндә горурлык хисе уятты.

Эшемне М. Галиев сүзләре белән тәмамлыйсы килә: "Өлкән буын телне салмак олыгайтып яшәтсә, яшь буын телне санлап яшәртә". Телебезне санлап, яклап, яратып яшик.

## Җирдә нигез тамыр кирәк, хәтта җансыз ташка да...

(Марсель Галиевнең тормыш юлы һәм иҗаты буенча квест)

*Ширеева Алсу Сәгыйть кызы, Салахова Гөлназ Ризатдин кызы,*

*Азнакай шәһәре 4нче лицееның туган тел укытучылары*

Федераль дәүләт белем бирү стандарты нигезендә төп белем бирү программасы уку планы һәм дәрестән тыш эшчәнлек аша гамәлгә ашырылырга тиеш. Дәрестән тыш эшчәнлек ул-укучыларның ял итү ихтыяҗларын канәгатьләндерү, аларның үзидарәгә һәм иҗтимагый-файдалы эшчәнлеккә катнашуы өчен дәрестән тыш вакытта оештырыла торган эшчәнлек. Яңа белем бирү стандартлары педагоглардан эшчәнлекле юнәлеш куллануны таләп итә, чөнки эшчәнлек барышында балалар материалны яхшырак үзләштерә. Кагыйдә буларак, укучылар, дәрестән тыш

эшчәнлекне мәҗбүр итү дип санап, мондый төр мөстәкыйль эшкә битараф карыйлар. Квест оештырганда исә, тискәре кәеф тулысынча юкка чыга. Укучыларга командада үзара бәйләнештә торырга туры килә, ә бу-коммуникатив күнекмәләрне үстерү дә, уйнаучыларны бергә туплауның яхшы ысулы да.

**Квестны үткәрү планы.**

**Максат:** Марсель Галиев турында алган белемнәр нигезендә укучыларның иҗади, интеллектуаль сәләтләрен үстерү өчен шартлар тудыру.

**Бурычлар:**

- командада эшли белү күнекмәсен формалаштыру;
- үзара ярдәмләшү, берләшү атмосферасын булдыру;
- гомуми эш өчен җаваплылык тәрбияләү.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

- куелган бурычларны хәл итүнең стандарт булмаган ысулларын кулланып, практикада белемнәрне куллану тәҗрибәсен булдыру;
- аралашуның вербаль һәм вербаль булмаган ысулларын куллану;
- тирә-юньдәгеләр белән продуктив хезмәттәшлек төзи белү;
- эшчәнлекнең нәтиҗәләрен дөрес бәяләү;
- үзара ярдәмләшү, толерантлык, эшне үтәүгә шәхси җаваплылык, яшьтәшләре белән уртак тел табып аралашу осталыгын үстерү.

**Әзерлек эше:**

1. Сценарийны эшләргә.
2. Һәр этап өчен биремнәр булган тарату материалы булдырырга.
3. Кирәкле реквизит (биремнәр салынган конвертлар) әзерләргә.
4. Модераторларны билгеләргә һәм бурычлары белән таныштырырга.

Уен чылбыр буенча төзелгән: бер биремне чишеп, катнашучылар алдагысын алалар һәм маршрут тәмамланганчы шулай дәвам итәләр.

Квест ахырына укучылар Марсель Галиевнең «Рух» әсәреннән тирән мәгънәле юлларын җыярга тиеш. Моны беренче булып эшләгән команда җиңүче була. Һәр этапның исеме халык мәкале белән аталган һәм ул бирем эчтәлеге белән туры килә. Уен үтә торган кабинетлар тематика буенча әзерләнә. Һәр этапта биремнәрнең үтәлешен күзәтеп торучы модераторлар бар. Команда дөрес җавап бирмәсә, башка этапларны үткәннән соң әлеге биремгә кире кайтырга мөмкинлек бирелә.

**Алып баручы:** Хәерле көн. Бүген без туган телебезне, мәдәниятебезне саклап калуда, аны үстерүдә армый-талмый хезмәт итүче күренекле шәхесләребезнең берсе-якташыбыз Марсель Галиевкә багышланган квест-уенга җыелдык. Ул-кабатланмас киңкырлы иҗаты белән татар әдәбияты үсешенә зур өлеш керткән олпат язучы. Аның әсәрләрендә милләтебез, телебез, рухи-мәдәни мирасыбыз язмышы өчен тирәнтен уйланулар чагылыш таба.

Үзенә генә хас язу алымы, сүз байлыгы, гаҗәеп чагыштырулар иҗатын югары сәнгать гамәленә күтәрә. Уен барышында бу сүзләргә тагын бер кат инанырбыз. Максатыгыз: Марсель Галиевнең «Рух» исемле әсәреннән бик тә мәгънәле юлларын җыю. Бу биремне беренче башкарган команда җиңүче булып санала.

Уенны башлыйбыз. Маршрут буенча төгәл баруыгыз сорала.

**1 нче этап. «Күп укысаң, күп белерсең»**

*Марсель Галиевнең тормыш юлына багышланган сорауларга «әйе», «юк» дип җавап бирегез.*

| | | |
|---|---|---|
| 1 | 1946 нчы елның 8 октябрендә Азнакай районы Балтач авылында туган | әйе |
| 2 | Башлангыч белемне Азнакайның 1нче мәктәбендә ала | юк |
| 3 | Мәктәпне тәмамлагач, армиягә киткәнче 1ел колхозда эшли | юк |
| 4 | 1969 нчы елда Казан дәүләт университетының филология факультетына укырга керә. | юк |
| 5 | Беренче шигырьләре «Беренче карлыгачлар» (1972) исемле күмәк җыентыкта басыла | әйе |
| 6 | 1974 нче елдан 1979 нчы елга кадәр Татарстан Язучылар берлегенең матур әдәбиятны пропагандалау бюросында эшли | әйе |
| 7 | М.Галиевнең «Ул чакта» дип исемләнгән беренче проза китабы 1980 нче елда басыла. | әйе |
| 8 | 1982-1984 елларда М.Галиев Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институтында белем ала | әйе |
| 9 | М.Галиев шулай ук юмористик хикәяләр дә иҗат итә | әйе |
| 10 | Кайбер шигырьләре көйгә салынган һәм халкыбызның яраткан җырларына әверелгән. | әйе |
| 11 | «Ак рәсем», «Шүрәле һәм җил», «Җиңәсем килде» исемле җыентыклары өлкән яшьтәге укучылар өчен | юк |
| 12 | 2006 нчы елда Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була | әйе |

**2 нче этап. «Белемле кеше югалмас»**

*«Нигез» әсәренең геройларын тану.*

1) Сары чәчле, зәңгәр күзле «сугыштан исән калып, өянке төбенә кайтып утыра алсам, үлсәм дә үкенмәс идем» дип нәзер әйтүче солдат. (Байтирәк)

2) Печән өмәсе булган көнне генә үзенең полячкасын исенә төшерүче; елына бер йомшап, мәзәк хәлдә кайтучы агач аяклы солдат, кыр сакчысы (Нәүширван)

3)Тугыз апасы куенында бик иркә үскән, кап-кара чәчле, нәзек сөякле малай (Фирзан)

4) Көлгәндә аның уң күзе ачылыбрак кала, ә сулы бөтенләй йомылып бетә; чик буенда дошман пулясыннан егерме яшендә һәлак була (Зәбир)

5)Уң колагы тырпайган, сулы бөтенләй ятып торучы; чәче тап-такыр итеп пәке белән кырылган башлы, "Бүремаңгай" кушаматлы малай (Тәнзил)

6)Фронтка киткәч, немецларга әсирлеккә эләгә һәм аннан качканнан соң, поляк партизаннары белән сугышуын дәвам итә. Авылга 10 елдан соң гына әйләнеп кайта. (Хикмәтулла)

7) Аның калын толымы бил турысына кадәр сузылып төшкән. Башына сап-сары чәчәкләрдән тәкыя үреп кигән. Авыл кызлары арасыннан ул бер үзе генә көпә-көндез чәчәк букеты тотып урам уртасыннан үтә ала (Гөлсирин)

8) Сугыш уены оештырырга ярата, хәрби фуражка киеп, чалбары галифега охшасын өчен кесәсенә дөңгечләп чүпрәк тутырып йөри (Корычбай)

9) "Нати" тракторын йөртүче, урак өстендә "Коммунар" комбайнын тарттыручы, авыр күн итек, пинжәк, башына беретка киеп йөрүче кыз (Мәдинә)

**3 нче этап. «Сөйләп күрсәткәнче, эшләп күрсәт»** Ребус чишү




.

**4 нче этап**. **«Эзләгән табар, ташка кадак кагар»**


5. Нокталар урынына тиешле сүз һәм сүзтезмәләрне куеп, әсәрдән өзекне сәнгатьле укыгыз.

Ә мин һаман әле иске урамнарны, ... өйләрне юксынам. Малай чакта үзем ачып кергән ... да хәтердән җуелмаган. Зур шәһәрләрдә, чит-ят илләрдә патшалар яшәгән, корольләр салдырган затлы сарайларны карап йөргәндә дә мин ... ябылган гади авыл өйләрен юксынып күз алдына китерә идем.Тик ул өйнең инде эченә сыеп керә алмыйсың, ... дә килеп карый алмыйсың. Арыш саламы ябылган “...” өй бала чакның бөек әкияте булып хәтер утравына күчкән. Кешеләр генәме, сулар да бит ... кире кайта. Диңгезгә барып җиткән ... , парга әйләнеп, болыт хасил итәләр дә яңгыр булып, туган якка кайтып явалар. Табигатьнең ... арасындагы мәңгелек әйләнеше.

*Сүз һәм сүзтезмәләр: чишмә сулары, капка тавышлары, арыш саламы, салам түбәле, туган ягына, тәрәзәсеннән, алтын түбәле, туган ягына, чишмә сулары, ашкыну һәм сагыну.*

**5 нче этап. “Бергә эшләсәң, авыр эш тә җиңел”**

Кроссворд.




Өстән аска.

1.Тәнзилләрнең кәҗәсе. 2. Зәбирнең кушаматы.3.Челтер чишмә янында тау өстендәге тигезлеккә төшеп кунучы моторсыз самолет.4. Өянкегә кунган кош.

5. Әсәрдә төп символик образ.

Уңнан сулга таба.

6.Кәҗәнең бәтиен югалтканнан соң тапкан дусты. 7.Әсәрдә бирелгән вәгъдәңә тугры калу, көтү символын белдерүче предмет исеме. 8. Аның кушаматы “Актәпи”. 9. Сугыш вакытында авылга кайсы яклардан кешеләр килеп урнаша? 10. Кышын бу чишмә янында ат суялар. Аның төбендә төрле төстәге чуерташлар ята.

**6 нчы этап. «Тырышкан табар, ташка кадак кагар»**

*Пазл җыегыз.*



**Алып баручы:** Командаларны уенда актив катнашулары белән котлыйм. Җиңүче команданы аерым билгеләп үтәм. Укучылар, сез М.Галиевнең «Рух» исемле әсәреннән бик тә мәгънәле юлларын җыйдыгыз.

«*Кешене хайванат дөньясыннан аерып торган өч хикмәт бар: Тел, Моң, Хәтер.*

*Тел – милләтнең җанын сугарып торучы чишмә.*

*Моң – милләтнең үз-үзенә юаныч бирү, үсендерү дәрте.*

*Хәтер – үткән зурлыклар иңенә басып, киләчәккә омтылу офыгы.*

*Өч тармак, өч тамыр, өч кодрәт бергәлеге… Шушы өч бергәлек табигый-тәңгәл үсештә, дин яктысы белән дә сугарылып торса гына…*

*Рухың сау була»,* – ди Марсель Галиев

## Марсель Галиевның "Көлә беләсеңме?" җыентыгындагы хикәяләрендә троплар

*Яруллин Булат, 7 нче сыйныф,«Азнакай шәһәре 7 нче урта гомуми белем мәктәбе»*

*Җитәкче:Шакирова Гөлназ Малик кызы туган тел (татар теле) һәм әдәбияты укытучысы*

Фәнни-эзләнү эшемдә мин татар шагыйре, язучы, Г. Тукай исемендәге Татарстан дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык язучысы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Марсель Галиевның хикәяләрендә троплар-чагыштыру, метафораларның кулланылышын карап үтәргә уйлыйм. Эшемнең **төп максаты-** Марсель Галиевның хикәяләрендә чагыштыру, метафораларның кулланылышын системалы рәвештә өйрәнү.

Максатка ирешү өчен түбәндәге **бурычлар** куелды:

1) Марсель Галиевның хикәяләре белән танышу;

2) хикәяләрдә кулланылган тел-сурәтләү чараларын ачыклау;

3) метафора һәм чагыштыруларның куллану дәрәҗәсен билгеләү.

**Эшнең методологик базасы**. Югарыдагы бурычларны чишү өчен Д.Ф. Заһидуллина, Ә. М. Закирҗанов, Т. Ш. Гыйләҗев, Н. М. Йосыпова, М. Галиев хезмәтләренә таянып эш ителде.

Марсель Галиев татар әдәбиятында үзенчәлекле урынны алып тора. Аның әсәрләре, кагыйдә буларак, интеллектуаль укучыны күздә тотып языла һәм ассоциатив чагыштыруларга, яңача көтелмәгән образлы тәгъбирләргә бай булуы белән аерылып тора.

Белгәнебезчә, матур әдәбиятның төп коралы-сүз. Язучы аны уйлап тапмый; ясамый, нигездә, билгеле бер телдә сөйләшүчеләр өчен уртак булган тел хәзинәсеннән ала. Ләкин бу сүзне әдип ничек итеп куллана? Нинди мәгънәдә куллана? Аны ничек итеп, кая урнаштыра?

### 2.1. Троплар турында кыскача мәгълүмат.

**Троплар-**әйберләр, предметлар, күренешләр арасындагы бәйләнешләр ярдәмендә күчерелмә мәгънә аңлату.

Тропларга чагыштыру, метафора, метонимия, эпитет, аллегория, гипербола, литота, сынландыру, персонификация, ирония, сарказм, юмор керә.

Фәнни-эзләнү эшемдә мин татар шагыйре, язучы М Галиевның хикәяләрендә троплар- чагыштыру, метафораларның кулланылышын карап үттем.

**Чагыштыру**-нинди дә булса күренешне аңа охшаш ягы булган икенче күренеш белән чагыштырып сыйфатлау- охшату.

Күрсәткечләре:

- -дай/дәй, -рак/-рәк, -ча/-чә аффикслары;
- кебек, төсле, шикелле бәйлекләре;
- бәйлек ролендә килгән сүзләр.

**Метафора**-яшерен чагыштыру. Мондый сурәттә кебек, шикелле, төсле, -дәй кебек ярдәмче сүзләр, кушымчалар төшеп кала, кайчак чагыштырыла торган күренешләрнең берсе генә әйтелә.

**2.2. Марсель Галиев хикәяләрендә троплар-чагыштыру, метафораларның кулланылышы.**

Тропларны тикшерү өчен Марсель Галиевның 10 хикәясен укыдым. Әсәрләрдә чагыштыруга 32, метафорага 78 мисал таптым һәм әдипнең хикәяләренең ни дәрәҗәдә сүзгә бай булуына ышандым.

Ә хәзер ***чагыштыруларга*** мисаллар китерәм:

“Кәефең шәпме?” хикәясендә:

- чәйнәп төкергән кебек;
- җеп белән тартылган шикелле;
- олыларча басып;
- татар белән башкорт кебек;
- пәрәвез җебе кебек;
- корбанын тапкан бөркет кебек;

“Очланмаган кибән” хикәясендә:

- йомранныкы кебек;
- йомырка сарысы кебек;
- үгез койрыгы кебек;
- бәллүр ваза кебек;

“Ие шул” хикәясендә:

- тычкан агуы эчкән кебек;

“Капка төбендә” хикәясендә:

- ике тычкан борынга-борын килеп иснәшкән кебек;

“Көлә беләсеңме?” хикәясендә:

- беренче тапкыр ишеткәндәге кебек;

“Күкеле сәгать” хикәясендә:

- үз өендәге кебек иркенлек;
- солдатларча кигереп куйды;

“Теләк” хикәясендә:

- уттай урак өстендә;
- каймак кебек җиргә;
- сабый күз яше кебек;

“Кем ул интеллигент? хикәясендә:

- апарага башын тыккан бозау кебек;
- чәчәк таҗына килеп кунган язгы күбәләк шикелле;
- йөз тәңкәлек акчаны сак кына алган кебек;
- шәрыкча елмаеп;
- парлы мунчадан чыккан кебек;

“Сәбәп” хикәясендә:

- кызылга ташланган күркә кебек;
- кәефе киткәндәй;
- японнарча итагатьлек;
- юып алган кебек;

“Арыслан йокысы” хикәясендә:

- дирижерның нота дәфтәрен ачып куюы шикелле;

- өзелгән кәлтә койрыгы сыман;
- пәрәвез кебек мыегы;
- көне буе уйнап арыган сабый шикелле;

***Метафораларның кулланылышына мисаллар:***

"Кәефең шәпме?" хикәясендә:

- нефть белән мумие бертуганнар,
- кызлары чибәрлек ягыннан бәреп ега,
- яттан сибә башлый,
- Алланың сакалына ябышып торасыз,
- ирләр төркеменә килә дә тотына сибәргә,
- бәхет нурлары иңә,
- тавышы сыеклана,
- бер-ике адым калуга бөтенләй сүнә;

"Очланмаган кибән" хикәясендә:

- Күрше агайларның һәр сүзен мыегына чорнап утырды,
- үткен күзле авылдашлар,
- моторның йомшак дерелдәве йөрәккә сары май булып ята,
- Наил үгезне мөгезеннән алырга булды,
- чекерәеп янган кояшка йөзе белән борылды,
- фронтондагы бизәкләре сандугач кебек сайрап тора,
- кишер баш,
- йөзенә төмсә күләгә җәелде,
- камырга әйләнә идең,
- очлый алмагансың кибәнне;

"Ие шул"хикәясендә:

- убыр утында пешкән аш,
- Чаллыда ишә генә акчаны,
- колхоз байлыгы өстендә атланып утырды,
- озын акчаны көрәпме-көри,
- итәк астында балта йөртәсең;

"Капка төбендә"хикәясендә:

- калай тавыш,
- ут өстенә ут җибәргәли,
- телләргә йозак салыр,
- чабата кашлы Сәмигулла,
- Сәмигулланың коңгырт тавышы,
- яргаланган ач туфрак;

"Күкеле сәгать" хикәясендә:

- гөрелдәтеп аваз салды,
- сәгать аксаклап йөри,
- кабинетта тирбәлгән әчкелтем силос исе,
- сәгатьнең арт чүмеченә кыстырып,
- күке рәхмәтле аваз салды;

"Теләк" хикәясендә:

- күз кырыен гына төшереп алды,
- җиде тавышка шыгырдатып торып утырды,
- синең шөрепләр бушаган бит.

"Кем ул интеллигент?" хикәясендә:

- бөердән чыккан калын бәрхет тавыш,

- сүзләрең бер-берсенә төелмичә йомрыланып,
- һәрберсе автоном көчкә ия булып таралсын,
- пауза - сүзсез сүз,
- бөек торгынлык,
- рәхәт кытыклау йөгертә,
- күз карашлары уңа башлаган чагы,
- тавышны кую,
- көзгеләргә тынычлык калдырмыйча,
- утыз ике тешеңне аңкауга кадәр чишендереп;

"Сәбәп" хикәясендә:

- күзенә кар яктылары төшкән өн,
- телдән калды,
- шәмәхә-бәрхет тавыш;

"Арыслан йокысы" хикәясендә:

- йокы ишелеп төште,
- тынлыкның соңгы мизгелләрен санаган,
- чатнап ярылган кыргый тавыш,
- бүлмә тынлыгын үтмәс пычак белән суеп җибәрделәр,
- гырлауның тамыры нык,
- дулкыннар тәгәри.
- авазлар Девон тирәнлекләренә кадәр төшә дә, тау-ташларны каерып алып, коточкыч гарасат куптара, кыялар убыла, афәтле тетрәү арасыннан чутылдап затлы кош сайраулары ишетелеп китә,
- уналты яшьлек акселерат диванда таралып ята,
- сабый гырлавы борынлап килә,
- "урман кисү" тәмамланып килә иде,
- сүзләр күкрәккә төелеп торучан,
- кистереп чыбыркы чыжылдады,
- авазлар юашланып, моңлы пентатоникага күчте,
- йокысын алмас өчен.

М Галиев хикәяләре белән танышып чыкканнан соң, мин шундый фикергә килдем:

- авторның теле бай, троплар һәм стилистик фигуралар оста кулланылган;
- чагыштыруларга караганда метафораларны аеруча күп кулланган, шулар ярдәмендә укучыга җиткерергә теләгән фикерләрен үтемлерәк итүгә ирешкән.


ДИПЛОМ











Эчтәлек

Абдрахимова Р. **“М.Галиев-безнең якташыбыз”…………………………...........………4-5**
Алекян А.. **М.Галиевның “Рух” китабында сүз сәнгатенең бирелеше.........................................5-9**
Вадигуллина Р.М., Шакирова А.Р. **М.Галиевның “Догалы еллар” әсәренә анализ...................9-11**
Габдуллина Д. **М.Галиев иҗатында фәлсәфи уйланулар. Сүз көче........................................11-12**
Гайнуллина С. **М.Галиев иҗатында туган як темасы..........................................................12-14**
Галиева А.Р. **"Укучыларның сәнгатьле сөйләменә ничек ирешергә?"..................................** 14-15
Гарифуллина Я., Дема К. **“Хыялымда,качып кына, Туган як, сиңа кайтам “......................** 15-16
Гатиятуллина А.**”Чатыр тау – зәңгәр пирамида. М.Галиев иҗатында туган як темасы һәм аны ачуда кулланылган кайбер алымнар”.........................................................................................** 16-20
Җиһангиров Р. **М.Галиевның балалар өчен язган әсәрләрендә әхлак темасының бирелеше.......................................................................................................................20-21**
Загитова З. И, Закирова Ф. М. **«Бәхетле очрак» уены....................................................21-23**
Зарипова З. **М.Галиевның “Нигез” повестенда фразеологизмнар**.......................................... 24-26
Ибатова С.Р.,Сахбиева Р.Р. **“М.Галиев иҗатын өйрәнгәндә диаманта алымын куллану”...**26-28
Ибраһимова Л. **Ат язмышы-халык язмышы........................................................................** 28-32
Илһамова Э. **Шигъърият һәм моң.......................................................................................** 32-33
Исмагилова К. **“Әй туган җир”. М.Галиев иҗатында туган як темасы...............................** 33-37
Кашапова Ф.Ф. **Бәйләнешле сөйләм үстерү БиС технологиясе элементларын кулланып, сыйныфтан тыш уку дәресе “Туган як тәхете - Чатыр тау” .................................................** 38-48
Махиянова Р.М. **Сыйныфтан тыш чара. М.Галиев иҗатында туган як темасы.................** 45-48
Мостафина Р. **М.Галиев шигырьләрендә Муйнак образы.....................................................** 48-50
Мөхетдинова Р.Ф. **Әдәбият дәресләрендә предметара бәйләнешләр принцибын тормышка ашыру..................................................................................................................................** 50-54
Рахманова Д. **М. Галиев иҗатында туган як темасы...........................................................** 54-56
Рахманова Н. **Учымда-тургай шәүләсе................................................................................** 56-61
Сабирова Х.Г. **“Үз тәхетен эзлим һәрбер сүзгә”...................................................................** 61-64
Садриева А.Г. **М.Галиевның тормыш юлы. Ддәрестән тыш чара.......................................** 64-72
Сиразиева З. **М.Галиев иҗатында “ туган як темасы.........................................................**72-74
Усманова Л. **М.Галиевның “Нигез”повестенда мифологик образлар...................................**75-76
Фазлыева Г.Н. **М.Галиевның “Рух” китабында парлы сүзләр..............................................** 76-78
Хәйретдинова Ф.М. **“Туган җирем тургай булып, сыйган күңел читлегенә”........................** 78-82
Хәкимов А., Авзалов А. **М.Галиев – Чатыр тавының биеклеген һәм бөеклеген дөньяга танытучы...............................................................................................................................** 82-85
Шакирова Д. С. **М.Галиев иҗатына багышланган әдәби кичә...........................................** 85- 88
Шарипов А. **“М.Галиев иҗатында чагыштырулар”..............................................................** 88-91
Шәрәфиева А. **“Сүз пирамидаларга кадәр туган, Сүз – пирамидалардан соң да калачак...”...........................................................................................................................**91-94
Ширеева А.С., Салахова Г.Р. **“Җирдә нигез тамыр кирәк, хәтта җансыз ташка да...”..........** 94-98
Яруллин Б. **Марсель Галиевның “Көлә беләсеңме?” җыентыгындагы хикәяләрендә троплар...........................................................................................................................** 98-101